ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2023 елның 4 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «чыгым йөкләмәләренә» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чыгым йөкләмәләренә һәм гражданнарга социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (җирле администрация) тарафыннан ачыкланган, 2024 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән чыгым йөкләмәләренә» сүзләрен өстәргә;

2) 2 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә;

3) 3 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә;

4) 4 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә;

5) 6 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 1-ТРЗ

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяда «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3 статьяда:

а) 3 өлештә «үзара эшләве тәртибен» сүзләрен «үзара эшләвенең Федераль законның 17^3 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның 17^3 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган тәртипләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән аларның дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, башка оешмалар белән үзара эшләвендә, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган рәвешләрдә ярдәм күрсәтү;»;

түбәндәге эчтәлекле 2^1 – 2^3 пунктлар өстәргә:

«2^1) Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешманы Федераль законның 17^2 статьясындагы 2 пункты нигезендә расланган тәртиптә билгеләү;

2^2) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегенең тотрыклы эшләвен тәэмин итү, аны гамәлгә ашыру һәм аңа ярдәм итү инфраструктурасын булдыру максатларында, финанс, матди һәм кадрлар белән тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук Федераль законның 17^4 статьясында каралган башка рәвешләрдә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәгенә ярдәм күрсәтү;

2^3) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, Федераль законның 17^4 статьясындагы 2 пунктында каралган рәвешләрне исәпкә алып, ярдәм итү чаралары исемлеген билгеләү;»;

в) 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 5^1 пункт өстәргә:

«5^1) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен белешмәләр тапшыру;»;

4) 4 статьяда:

а) 2 пунктта «үзара эшләве тәртибен» сүзләрен «үзара эшләвенең Федераль законның 17^3 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның 17^3 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган тәртипләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән аларның дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, башка оешмалар белән үзара эшләвендә, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга оештыру, мәгълүмати, методик һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга, дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган рәвешләрдә ярдәм күрсәтү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 4 – 6 пунктлар өстәргә:

«4) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге координацион һәм киңәшмә органнарын булдыру;

5) ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен белешмәләр тапшыру;

6) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, Федераль законның 17^4 статьясындагы 2 пунктында каралган рәвешләрне исәпкә алып, ярдәм итү чаралары исемлеген билгеләү.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 2-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

өченче абзацта «республика программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа кырык өченче абзац өстәргә:

«әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру;»;

кырык өченче абзацны кырык дүртенче абзац дип санарга;

б) 2 өлештә «кырык өченче» сүзләрен «кырык дүртенче» сүзләренә алмаштырырга;

2) 50 статьяда:

а) 1 өлештә «Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондын төзү һәм аннан файдалану» сүзләрен «әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасын төзү, аннан файдалану һәм аны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.
3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы өченче – бишенче абзацлары һәм «б» пунктчасы 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 3-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясендә элек булган һәм 23 яшькә җиткән затлар милеккә уңайлы торак урыны сатып алу өчен яисә заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча торак урыны сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр түләү алу хокукына ия.».

2 статья

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында»;

2) преамбулада «ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгели» сүзләрен «ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) торак урынына хокукын гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяның 4 өлешендә «3^1 өлешендә» сүзләрен «3^1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2^1 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «4 өлешендә» сүзләрен «4 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле 3^1 статья өстәргә:

«3^1 статья. **Милеккә уңайлы торак урыны сатып алу өчен яисә заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен түләү бирү рәвешендә торак урынына хокукның өстәмә гарантияләре**

1. Федераль законның 8 статьясындагы 9 пунктында күрсәтелгән һәм әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән затлар, Федераль законның 8^1 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән шартларның барысы да булганда, милеккә уңайлы торак урыны сатып алу өчен яисә заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча торак урыны сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр түләү (алга таба – түләү) алу хокукына ия.
2. Вәкаләтле орган торак урыннарын түләү исәбенә сатып алуны контрольдә тота, ул шул исәптән түләүне алучы тарафыннан сатып алына торган торак урынының билгеләнгән санитария кагыйдәләренә һәм нормаларына, техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүе турында, әлеге торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану һәм (яисә) әлеге торак урыны урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында мәгълүмат булу яисә булмау хакында ведомствоара гарызнамәләр җибәрү һәм алу юлы белән гамәлгә ашырыла.
3. Түләүне бирү, шул исәптән түләүне күчерү өчен кирәкле документларны тикшерү, түләүне күчерү һәм түләү исәбенә торак урыннары сатып алуны контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Федераль законның 8^1 статьясындагы 8 пункты нигезендә башкарыла.
4. Түләүне бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту хакында карар вәкаләтле орган төзегән комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә Федераль законның 8^1 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән шартларның барысын да исәпкә алып кабул ителә. Комиссия эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.
5. Түләүне алуга хокук торак урыны сатып алу өчен исемле документ – сертификат белән раслана, аның рәвеше, аны чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләре Федераль законның 8^1 статьясындагы 11 пункты нигезендә раслана.
6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга сертификат бирү комиссиянең түләүне бирү турындагы карары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.»;

6) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5^2 һәм 5^3 өлешләр өстәргә:

«5^2. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе төзелгән зат тәкъдиме белән иң күбе ике елга кыскартылырга мөмкин, моның өчен күрсәтелгән зат тарафыннан әлеге шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскарту турында вәкаләтле органга гариза бирелгән датага Федераль законның 8 статьясындагы 6^2 пунктында күрсәтелгән шартларның барысы да булырга тиеш.

5^3. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогын кыскарту турында гаризага өстәп бирелә торган документлар исемлеге, күрсәтелгән гаризаны тапшыру һәм карау тәртибе, мондый шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскарту турында яисә мондый шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскартудан баш тарту хакында карар кабул итү турындагы мәгълүматны җибәрү тәртибе (шул исәптән күпфункцияле дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәге йә «Бердәм дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша) Федераль законның 8 статьясындагы 6^3 пункты нигезендә раслана.»;

7) 5^1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5^1 статья. **«Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында ятим балаларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат урнаштыру**

1. «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында түбәндәге мәгълүмат урнаштырылырга тиеш:

1) әлеге Закон нигезендә ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында;

2) түләү бирү турында, шул исәптән сертификатның теркәү номеры, вәкаләтле органның сертификат бирү турындагы карары, сертификатны бирү датасы һәм түләү исәбенә сатып алынган торак урынын сату-алу шартнамәсен төзү датасы, түләүнең күләме, сатып алынган торак урынының адресы, түләү алучыны исемлектән чыгару датасы хакында.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру һәм алу «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.».

3 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 5^2 һәм 5^3 өлешләре нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләренә кагыла.
3. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5^1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезләмәләре «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану өлешендә 2026 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 4-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2^1 статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2^1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле 10^{11} һәм 10^{12} пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«10^{11}) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик затны билгеләү;

10^{12}) территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган карарны гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 71 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән килешүне төзү очракларын, килешүнең эчтәлеген, аны төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;».

2 статья

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), «дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә» сүзләреннән соң «йә, торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү хакындагы килешүдә каралган булса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат милкенә» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 5-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе **Гатин** Шәүкәт Фатыйх улына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе Минзәлә районара тикшерү бүлеге җитәкчесе **Исмәгыйлев** Рамил Хәертдин улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны **Хәйруллин** Тимур Илгизәр улына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы **Туктаров** Мөнир Хәбибулла улына, хезмәт ветераны **Шакирова** Фирая Каюм кызына, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе лицензия-рөхсәт бирү эше үзәге корал әйләнешен контрольдә тоту бүлегенең аерым йөкләмәләр буенча өлкән инспекторы, полиция капитаны **Закорин** Никита Михайловичка, **«Татэнерго» акционер җәмгыяте коллективына**, Фәйзи Галиев исемендәге авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе **Хәкимҗанов** Илнур Илдар улына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе **Хисмәтова** Эльвира Винер кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

Актив гражданлык позициясе, иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «Уңыш» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Казан шәһәр Думасы депутаты **Вәлиев** Альфред Рәкыйб улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы урынбасары **Блюмхен** Гөлнара Гарәфетдин кызы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Камалетдинова** Венера Рәис кызы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Чарлы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Муллахмәтова** Лилия Зөфәр кызы, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары һәм территориаль органнар белән эшләүне оештыру бүлеге башлыгы **Нигъмәтуллина** Гөлфия Җәүдәт кызы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Садретдинова** Лилия Әнфәс кызы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесенең эш башкару һәм кадрлар бүлеге баш белгече **Чудовичева** Римма Рәшит кызы; күпьеллык намуслы хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Казан шәһәр Думасы аппараты хезмәткәрләре: Мэрның һәм Казан шәһәр Думасының эшчәнлеген тәэмин итү идарәсенең мэр эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы **Сабируллова** Алсу Илдар кызы, Халыкара һәм муниципальара элемтәләр идарәсенең халыкара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы **Сабитова** Сания Илгиз кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «Рөстәм Яхин исемендәге 3 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директорының укыту-тәрбия эше буенча урынбасары **Абдуллина** Гөлнара Шәфигулла кызына, Башкортостан Республикасының Уфа «Нур» дәүләт татар театры дәүләт бюджет мәдәният һәм сәнгать учреждениесе директоры **Габидуллин** Фирзәт Фәрит улына, Татарстан Республикасының «Республика яшүсмерләр китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе инновация-методика бүлеге мөдире **Гатауллина** Рәйлә Тәлгать кызына, «Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Балаларны һәм яшүсмерләрне иҗади үстерү ресурс үзәге мөдире **Нейдерова** Ирина Николаевнага, «КОРСТОН-КАЗАН» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең бәйрәмнәрне оештыру бүлеге баш режиссеры **Сафиуллин** Линар Галимулла улына, Казан шәһәренең «14 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең махсус фортепиано укытучысы **Софронова** Людмила Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ 2023 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

tatarstan.ru

КЕРЕШ

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Вәкаләтле вәкил) эшчәнлеге турында әлеге еллык доклад «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 нчы маддәсе нигезендә әзерләнгән һәм Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Югары суды рәисенә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

Докладны әзерләгәндә мөрәҗәгать итүчеләрнең Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләренә, «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматларына, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» дәүләт мәгълүмат системасы кире элемтә платформасы аша килгән хәбәрләргә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары мәгълүматларына, шулай ук җәмәгатьчелек ярдәмчеләре тәкъдим иткән, кеше хокуклары бозылу турында хокук яклау оешмаларыннан килгән яки массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә басылган, ГЛОНАСС +112 бердәм дәүләт мәгълүмат системасына җибәрелгән мәгълүматларга, республика ведомствоара комиссияләре материаллары һәм башка чыганакларга анализ ясалды.

Докладта 2023 ел өчен Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең статистик мәгълүматлары китерелә. Шул ук вакытта докладта гражданнарның социаль, икътисадый һәм мәдәни хокукларын яклау, хәрбиләрнең һәм аларның гаиләләренең хокукларын яклау, мәҗбүри тоту урыннарында гражданнарның хокукларын яклау, уңайлы әйләнә-тирә мохиткә гражданнарның хокукларын яклауга кагылышлы кайбер проблемалы мәсьәләләр, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту турында мәгълүмат, иҗтимагый хакимият органнары һәм гражданлык җәмгыяте институтлары, төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек, законнарны камилләштерү эшчәнлегендә Вәкаләтле вәкилнең катнашуы турындагы мәгълүматлар чагылыш тапты.

Шуңа бәйле рәвештә доклад структурасы тиешле бүлекләрне үз эченә ала, ә аның нәтиҗәсендә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый оешмаларга кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны көчәйтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген карарга тәкъдим ителә. Әлеге тәкъдимнәр хокук яклау эшчәнлеген камилләштерергә мөмкинлек бирер, дип өметләнәбез.

1 НЧЕ БҮЛЕК. МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРНЕҢ МАСШТАБЛАРЫ, ДИНАМИКАСЫ ҺӘМ СТРУКТУРАСЫ

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә (алга таба – Вәкаләтле вәкил) ел дәвамында килгән мөрәҗәгатьләрне (гаризалар, шикаятьләр, тәкъдимнәр) Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының «Халык контроле», социаль челтәрләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында басылган яки «ГЛОНАСС +112» Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрелгән мәгълүматларны анализлау Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендәге вәзгыятьне бәяләүнең төп инструментларының берсе булып тора.

2023 елда республика халкы Вәкаләтле вәкил адресына 5 750 тапкыр мөрәҗәгать иткән. Язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны 4 129 тәшкил итә, шуларның 517се – почта элемтәсе, 640ы – электрон почта, 715е – интернет-кабул итү, 235е – турыдан-туры тапшыру, 407се – телефоннан шалтырату, 548е – Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы, 17се – фельдъегер элемтәсе, 93е – Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документлар әйләнеше аша алынган.

2023 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында барлык статуслардан кайтарылган мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып 104 667 мөрәҗәгать бастырылган, шулардан 84 013 мөрәҗәгать (80%) хәл ителгән, 14 492се буенча эшләр планлаштырылган, 4 719 мөрәҗәгать буенча «дәлилле баш тарту» статусы бирелгән, 1 443е – эштә.

Гражданнардан килгән комментарийларның гомуми саны 3 172 054кә җиткән, теләктәшлек итүчеләр саны – 1 710 373.

Хисап чорында система кулланучылары («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» кире элемтә платформасы аша килгән хәбәрләрне исәпкә алып) иң актив рәвештә түбәндәге юнәлешләр буенча хәбәрләр җибәрделәр: «Төзекләндерү һәм инфраструктура» юнәлеше буенча – 39 102, «Юллар» – 30 139, «Торак-коммуналь хуҗалык» – 7 639, «Каты коммуналь калдыклар» – 3 993, «Транспорт» – 3 150, «Сәламәтлек саклау» – 3045, «Сәүдә» – 2 252, «Өлешчә мобилизация» – 1 819, «Экология» – 1 720, «Атамалардагы һәм язулардагы хаталар» юнәлеше буенча – 1 508 хәбәр.

Гражданнарның иң күп мөрәҗәгатьләре – Казан (45 064), Яр Чаллы (10 953), шулай ук Әлмәт (4 406), Бөгелмә (2 642), Түбән Кама (2 776), Яшел Үзән (1 820), Лаеш (1 240), Лениногорск (1 239) һәм Алабуга (1 226) муниципаль районнарыннан килде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк белән идарә итү үзәге проектын гамәлгә ашыру буенча «Проект офисы турында» 28.04.2021 елгы 289 нчы карары нигезендә «Татарстан Республикасында төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча Проект офисы эшчәнлеген тәэмин итү кысаларында, «Россия Федерациясенең муниципаль хезмәтләре (функцияләре) бердәм дәүләт порталы» базасында эшләүче кире элемтә платформасы аша гражданнарның төрле мәсьәләләр буенча килгән мөрәҗәгатьләре кабул ителә.

Әлеге мөрәҗәгатьләрне вакытында карауны тикшерү Проект офисы җитәкчесенә – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә йөкләнде.

2023 елда кире элемтә платформасы аша гражданнардан 60 167 хәбәр килгән.

2023 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан барлыгы 76 кабул итү үткәрелгән, шул исәптән 47 шәхси һәм 29 уртак тематик, алар барышында 629 граждан кабул ителгән.

Хисап чорында Татарстан Республикасы Прокуратурасы җитәкчелеге белән (28.03.2023 – 32 мөрәҗәгать), 21.06.2023 – 19, 30.11.2023 – 7), Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе (17.04.2023 – 9, 27.11.2023 – 7), Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (06.10.2023 – 3), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (27.06.2023 – 8), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе рәисе Е.И. Кузьмичева белән – «Ливадия» шифаханәсендә (24.08.2023 – 5), Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты Ә.М. Хәмитов белән (09.11.2023 – 11), «Татарстан Республикасы дәүләт юридик бюросы» (14.02.2023 – 6, 11.04.2023 – 12, 05.05.2023 – 11, 30.05.2023 – 14, 15.08.2023 – 10, 15.09.2023 – 1, 19.12.2023 – 10); Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (30.05.2023 – 3), Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты (16.10.2023 – 1), Хәрби комиссариат, Казан гарнизоны Хәрби прокуратурасы вәкилләре, Татарстан Республикасы Премьер-министры ярдәмчесе белән (24.10.2023 – 4), Казан гарнизоны Хәрби прокурорының өлкән ярдәмчесе (24.10.2023 – 6) белән гражданнарны бергәләп тематик кабул итүләр үткәрелде.

2023 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә оештырыла торган «1 нче төзәтү үзәге», «2 нче төзәтү колониясе», «3 нче төзәтү колониясе», «5 нче төзәтү колониясе» федераль казна учреждениеләрендә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «19 нчы Төзәтү колониясе»ндә җәзаны үтәүчеләр өчен Хокукый ярдәм көннәрендә катнашты, аның кысаларында 130 хөкем ителгән кеше кызыксындырган мәсьәләләр буенча консультацияләр алды.

Хокукый ярдәм көннәре нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатьләрнең бер өлеше контрольгә алынды, ә килгән шикаятьләр турында мәгълүмат Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм компетенция буенча Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларына һәм ведомстволарына карарлар кабул итү өчен җибәрелде.

Шулай ук Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчелеге, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең «16 нчы медицина-санитар часте», Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы идарәсе, Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре катнашында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе видеоконференцэлемтә системасын кулланып, «4 нче Төзәтү колониясе», «8 нче Төзәтү колониясе», «10 нчы Төзәтү колониясе», «3 нче Тикшерү изоляторы», «4 нче Тикшерү изоляторы», «5 нче Тикшерү изоляторы», «17 нче Торак пункт колониясе» медицина частьларына тоташып, хөкем ителгәннәрне 3 дистанцион кабул итү уздырылды, алар кысаларында 16 хөкем ителгән кеше шәхси мәсьәләләр буенча консультация ала алды.

Татарстан Республикасы Адвокатлар һәм Нотариаль палаталары белән төзелгән хезмәттәшлек турында килешүләр ярдәмендә халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү максатыннан, әлеге ведомстволар белгечләре тарафыннан 2023 елда ай саен Вәкаләтле вәкил Аппаратында гражданнарны кабул итү үткәрелде. Ел дәвамында барлыгы 24 гражданны кабул итү үткәрелде.

Гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләре белән эшләү Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең төп юнәлешләренең берсе булып тора. Вәкаләтле вәкил Аппаратына көн саен килә торган хатларны анализлау дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар тарафыннан комплекслы хәл итү һәм актив игътибар таләп итүче системалы проблемаларны билгеләргә мөмкинлек бирә.

Проблемалы участокларны ачыклау һәм гражданнар белән актив хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатларында Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан системалы рәвештә телефоннан «кайнар элемтәләр» үткәрелә.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил Аппаратында кызыксынган министрлыклар, ведомстволар, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары катнашында 6 телефон «кайнар элемтәсе» үткәрелде, алар кысаларында 336 шалтырату кабул ителде.

2023 елның февраленнән коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалау белән бәйле чикләү чаралары йомшартылганнан соң, «Россия пенсионерлары берлеге» ҖЧҖнең Татарстан Республикасы буенча бүлеге белән берлектә халыкка Хокукый ярдәм көннәрен үткәрү практикасы яңартылды. Әлеге чаралар көндезге форматта үткәрелә, Казан шәһәре районнарында күпсанлы гражданнарны колачлый. Халыкка Хокукый ярдәм күрсәтү көннәре Вәкаләтле вәкилнең актив эшчәнлегенең бик актуаль һәм кирәкле формалары буларак танылды.

2023 елда барлыгы 8 шундый Хокукый ярдәм көне оештырылды, аның кысаларында 144 гражданга бәхәсле юридик мәсьәләләрне хәл итү буенча консультацияләр бирелде.

Килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләгәндә, Вәкаләтле вәкил гражданнарның законда каралган шикаятьләренә җавап бирүнең төрле инструментларын куллана: тикшерүләр үткәрү, запрослар җибәрү, судларга үтенечләр, тәкъдимнәр һ.б.

2023 елда Вәкаләтле вәкил өченче зат яки кызыксынган зат буларак гражданнарның 9 дәгъвасы буенча җәлеп ителде, аларның хакимият органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм башка учреждениеләргә таләпләрен хуплады.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил гражданнарның хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге һәм «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының кулланучылар үзара хезмәттәшлеген координацияләү бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан 765 тикшерү чарасы үткәрелде:

– мәгариф өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау максатларында –18;

– сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау максатларында – 9;

– ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын яклау максатларында – 9;

– сак астында тотылган һәм ирегеннән мәхрүм ителгән кешеләрнең хокукларын яклау максатыннан – 34;

– ТР «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы гражданнары мөрәҗәгатьләрендә күрсәтелгән объектлар буенча. Нәтиҗәдә җаваплы башкаручыларга 9 меңнән артык шикаятьнең 682е эшкә кайтарылган.

2023 елда дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары һәм оешмалары адресына хокукларны һәм ирекләрне торгызу буенча мөмкин булган һәм кирәкле чараларга карата тәкъдимнәр һәм Вәкаләтле Вәкилнең тәкъдимнәре һәм кисәтүләре җибәрелде. Ел дәвамында гражданнарның хокукларын торгызу максатыннан барлыгы 55 шундый тәкъдим һәм кисәтү җибәрелде.

Моннан тыш, 2023 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан, «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 нче маддәсе 3 нче пунктына ярашлы рәвештә, дисциплинар эш кузгату турында 2 үтенеч җибәрелде.
(А. мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи затларына карата, аларның гамәлләрендә балигъ булмаган А. һәм аның законлы вәкиле хокукларын бозу күзәтелгән;
Ш. мөрәҗәгате буенча, балигъ булмаган Ш.ның белем алуга хокукын бозуга юл куйган вазыйфаи затларга карата).

2018 елда Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән хезмәттәшлек турында төзелгән килешү кысаларында, 2023 елда, «ГЛОНАСС +112» ЕГИС системасында эш дәвам итте.

Вәкаләтле вәкилнең хисап чорында эшкә кабул ителгән мәгълүмат хәбәрләре саны – 1 621 тәшкил итә.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренең төп өлеше:

– торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү (сыйфатсыз хезмәтләр күрсәтү, идарәче оешмаларның эшчәнлеге, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүнең өзелүе яки гомумән су белән тәэмин итүнең булмавы, гомуми милекне тоту һ. б.);

– медицина ярдәме күрсәтмәү (госпитализациядән баш тарту, дарулар булмау, табибларга язылу мөмкинлеге булмау, ашыгыч медицина ярдәме хезмәте эше);

– гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны яклау мәсьәләләре, шулай ук балаларның өлкән яшьтәге ата-аналарны карау бурычын үтәмәве (гаилә әгъзаларына карата физик һәм психологик көч куллану, балаларны, өлкәннәрне куркыныч астында калдыру);

– социаль тормыш эшчәнлеге (реабилитацияләүнең техник чараларын бирү турында үтенечләр; гражданнарның зәгыйфь категориясе хокукларын яклау, аларны социаль тәэмин итү; авыр тормыш хәлендә булган гражданнарга ярдәм итү);

– җәмәгать әһәмиятендәге проблемалар (юл хәрәкәте иминлеге, территорияне төзекләндерү һәм җәмәгать урыннарын чисталыкта һәм тәртиптә тоту) белән бәйләнгән.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан эшкә кабул ителгән мәгълүматның иң күбе Татарстан Республикасының Казан, Чаллы, Бөгелмә, Түбән Кама, Яшел Үзән һәм Әлмәт районнарыннан килде.

Хокук мөнәсәбәтләренең һәм тормыш эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә гражданнарның хокукларын яклау белән турыдан-туры бәйле булган мөрәҗәгатьләрне алгач, Вәкаләтле вәкил шунда ук килеп туган мөрәҗәгать бирүчеләрнең проблемаларын хәл итү буенча чаралар күрә.

Хисап чорында гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрендә Вәкаләтле вәкил адресына килгән сораулар саны 4 334 булды.

2023 елда гражданнарның иң күп мөрәҗәгатьләре «Социаль, икътисадый һәм мәдәни хокукларны һәм ирекләрне яклау» тематик блогы мәсьәләләре буенча килде – 1760 мәсьәлә.

Шулардан категорияләр буенча:

• «Торак хокукы» – 570 сорау.

2023 елда гражданнар торак-коммуналь хуҗалыкның торышы һәм үсеше проблемалары, шул исәптән идарәче һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның эшчәнлеге, алар тарафыннан күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты, капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрү, күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләүне исәпләү тәртибен бозу һәм тарифларны билгеләү тәртибенең ачык булмавы турында хәбәр иттеләр. Аерым алганда, Казан (250дән артык мөрәҗәгать), Чаллы (22), Түбән Кама (18), Бөгелмә (11), Әлмәт (10), Сарман (7) муниципаль районнары территориясендә яшәүче, Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итүче гражданнарның күпчелеге нәкъ менә шушы проблемалар белән очрашкан. Республиканың башка районнарыннан күрсәтелгән проблемалар буенча мөрәҗәгатьләр бер-ике генә булды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге хокуклар категориясенә кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең шактый өлеше торак проблемаларына кагыла. Аерым алганда, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү, шулай ук торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую. Әлеге мәсьәләләр буенча ешрак Казан (70тән артык мөрәҗәгать), Чаллы (7), Буа (6), Чистай (4) районнары халкы мөрәҗәгать итте.

Мисал:

2023 елның февралендә Вәкаләтле вәкил Аппаратына Казанда Маршал Чуйков урамында, 25 нче йортта яшәүчедән, җылыту һәм канализация системалары төзек булмау сәбәпле, ул яшәгән күпфатирлы йортта подвал биналарын системалы рәвештә су басу турында мөрәҗәгать килде.

Ике ел элек МКД подъездларында агымдагы ремонт үткәрелүгә карамастан, мөрәҗәгать текстыннан һәм аңа кушылган фотоматериаллардан хәзерге вакытта баскыч мәйданчыклары канәгатьләнерлек хәлдә түгел, дип күренә. Шикаять бирүче сүзләренчә, моның сәбәбе – подъездда дымлылык, ул күрсәтелгән йортта инженер системалары төзек булмау сәбәпле подвал биналарын системалы рәвештә су басуга бәйле. Шулай ук МКД подъездларында начар ис барлыкка килгән.

Безнең катнашуыбыздан соң әлеге йортта эшләр башкарылды: йортта җылылык һәм электр белән тәэмин итү тулысынча торгызылды, лифтлар эшләтеп җибәрелде, йорт эчендәге инженерлык челтәрләре техник яктан төзек хәлдә, су агу һәм торба тишелү ачыкланмады.

Шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе кисәтүләрен үтәү кысаларында, «Уютный дом» идарәче компаниясе» ҖЧҖ торак йортның 1, 2 нче подъездындагы стеналарның зыян күргән участокларын ремонтлау-яңарту эшләрен башкарган, бу хакта йортта яшәүчеләр тарафыннан имзаланган 29.09.2023 елгы тиешле акт төзелгән.

«Торак-коммуналь хуҗалык» темасы «Халык контроле» системасында бастырылган хәбәрнамәләр саны буенча да өченче урында тора – 7 639 хәбәрнамә.

Аларның иң күбе – Казан (3 553), Чаллы (1 058), Әлмәт (718), Түбән Кама (511), Бөгелмә (370) муниципаль районнары һ. б. буенча килгән.

Вәкаләтле вәкил Аппараты, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, муниципаль берәмлекләр, күзәтчелек органнары, идарәче компанияләрнең уртак эше нәтиҗәсендә мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 90% яки гражданнарның 6 853 хәбәрнамәсе уңай хәл ителгән.

• «Социаль тәэмин итү хокукы» – 506 сорау.

Әлеге хокуклар төркемен тәшкил итүче мөрәҗәгатьләр пенсия белән тәэмин итү, инвалидларны социаль тәэмин итү («Уңайлы мохит» булдыру, кешене инвалид дип тану, реабилитацияләүнең техник чаралары белән тәэмин итү, реабилитацияләү һәм абилитацияләүнең шәхси программасына үзгәрешләр кертү, шифаханә-курорт дәвалауга юллама рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алмау) мәсьәләләренә кагылган.

Гражданнар еш кына Казан (200дән артык мөрәҗәгать), Чаллы (37), Түбән Кама (11), Чистай (10), Алабуга (8), Әлмәт (7) муниципаль районнарыннан һ. б. мөрәҗәгать иткәннәр.

Мисал:

2023 елның 25 августында Вәкаләтле вәкил Аппаратына Казан шәһәрендә яшәүче Н.нан мөстәкыйль сатып алынган техник реабилитация чарасы өчен компенсация түләмәү турында мөрәҗәгать килә.

Мөрәҗәгатьтә гариза бирүче техник тернәкләндерү чарасын үзе сатып алганлыгын күрсәтә: улы Н., инвалид баласы өчен җылытылмаган аслыклы катлаулы ортопедия аяк киеме алган. 2023 елның 16 июнендә гариза бирүчегә техник тернәкләндерү чарасын үзлегеннән сатып алган өчен компенсация түләү буенча кабул ителгән уңай карар турында хәбәр ителә. Әмма, гариза бирүче билгеләгәнчә, техник тернәкләндерү чарасы бирүгә вәкаләтле орган тарафыннан компенсация түләү турында гаризада күрсәтелгән исәп-хисап счетына закон белән билгеләнгән срокларда компенсация түләүгә акча җибәрелмәгән. Социаль иминият фондының территориаль органнарына күп тапкырлар мөрәҗәгать итүләр нәтиҗә бирмәгән.

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 03.03.2000 елгы 95 нче номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 маддәсенең 2 өлешендәге 3 пунктына таянып, шулай ук балигъ булмаган бала хокукларын яклау максатларында мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен карап, җавап чаралары күрүне сорап, Россия Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе адресына хат җибәрелде.

Бүлек мәгълүматлары буенча, 2023 елның 16 июнендә, Н. мөрәҗәгате буенча гариза каралган һәм аның буенча уңай карар чыгарылган.

Әмма, җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре сарыф ителү сәбәпле, үзлегеннән сатып алынган техник тернәкләндерү чарасы өчен компенсация түләү законда билгеләнгән вакытта башкарылмаган.

ТР буенча Пенсия һәм социаль иминият фонды килеп туган хәл турында Россия Социаль фондының Үзәк аппаратына хәбәр итте.

2023 елның 6 сентябрендә тернәкләндерү чараны мөстәкыйль сатып алу чыгымнарын түләү турында боерык чыгарыла. 2023 елның 7 сентябрендә гомуми суммасы 8 026,5 сум булган компенсация Н. гаризасында күрсәтелгән реквизитлар буенча җибәрелгән.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Социаль яклау» юнәлеше буенча 2023 елда, гражданнарның 1029 мөрәҗәгате кергән, шул исәптән «Тормыш иптәше булмаган балаларны тәрбияләүче гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» категорияләре буенча – 583 хәбәрнамә; «Социаль иминият буенча пособие һәм түләүләр» – 135 хәбәрнамә; «Социаль хезмәт күрсәтү», «Федераль бюджет чаралары хисабына тернәкләндерү буенча техник чаралар һәм инвалидларны тернәкләндерү хезмәтләре», «Социаль яклау органнары тарафыннан күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары, реабилитация чаралары», «Ветеран янәшәдә яши» – 19 хәбәрнамә, «Уңайлы мохит» – 258 мөрәҗәгать.

«Социаль яклау» юнәлеше буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында басылган 1 029 мөрәҗәгатьнең 916сы уңай хәл ителгән.

«Халык контроле» мәгълүмат системасында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә мониторинг уздыру вакытында ачыкланган барлык актуаль проблемалар «Халык контроле» ТР Дәүләт мәгълүмат системасының эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия утырышларында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә һәм Вәкаләтле вәкил Аппаратында эш киңәшмәләрендә карала.

2023 елда Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе, Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре, министрлыклар, ведомстволар, Казан һәм Чаллы шәһәрләре, Арча, Кукмара, Мамадыш, Түбән Кама, Әгерҗе, Алабуга, Менделеевск, Зәй, Тукай, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Алексеевск, Лаеш, Балык Бистәсе, Питрәч муниципаль районнары башкарма комитетлары структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм җаваплы башкаручылары катнашында 26 күчмә киңәшмә уздырылды.

• «Хезмәткә хокук» – 61 сорау.

Узган ел белән чагыштырганда, 2023 елда гражданнарның хезмәт хокукларына кагылышлы мәсьәләләр саны 37%ка кимегән. Шул ук вакытта, узган ел гражданнар үз мөрәҗәгатьләрендә эшкә урнашу кыенлыгын, эштән китәргә мәҗбүр булуны һәм хезмәт хакы алмауны күрсәттеләр.

Мисал:

Вәкаләтле вәкил адресына Казанда яшәүче Л.дан эш бирүченең хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат, аерым алганда, эштән азат итү турында мәгълүмат бирмәве мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать килгән, шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүче алга таба эшкә урнашуда кыенлыклар кичергән.

Вәкаләтле вәкил шунда ук ТР буенча Пенсия һәм социаль иминият идарәчесе адресына мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен тикшерүне оештыру һәм компетенция чикләрендә чаралар күрү турында хат җибәрде.

2020 елдан Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 маддәсе нигезендә эш бирүче электрон рәвештә һәр хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында төп мәгълүматны формалаштыра һәм аны Россия Федерациясе Социаль фондының мәгълүмати ресурсларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль исәп-хисап турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итә.

Эш бирүче биргән мәгълүматлар нигезендә, социаль фонд органнары хисап мәгълүматларын теркәлгән кешеләрнең шәхси счетларына, шул исәптән аерым бүлеккә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларга үз вакытында кертәләр.

Хисап мәгълүматларына караганда, гариза бирүче хезмәт эшчәнлеген алып барган җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять Л.ның эштән азат ителүе турында мәгълүматны хата белән тапшырган, шуңа күрә хаталы мәгълүматлар кабул ителмәгән һәм исәпкә алынмаган.

Л.ның хатасыз эштән азат ителүе турында төгәллек кертелгән мәгълүматлар фондның мәгълүмат базасына 2023 елның 6 февралендә килә һәм шәхси хисапка, шул исәптән электрон хезмәт кенәгәсенә кертелә.

• «Сәламәтлекне саклау һәм медицина ярдәме алу хокукы» – 184 сорау.

Аларда гражданнар дару препаратлары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәү, медицина ярдәме күрсәтүнең тиешенчә күрсәтелмәве, табибка язылудагы кыенлыклар һ. б. белән бәйле проблемаларга басым ясады.

Мисал:

2023 елның 4 июлендә Вәкаләтле вәкил адресына Казанда яшәүче Ш. мөрәҗәгать итте. Ул «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе»нең диагностика поликлиникасына табиб-гематологка кабул итүгә язылуда ярдәм итүне сорады.

Ул үз мөрәҗәгатендә бер ел дәвамында табиб-гематологка языла алмавын хәбәр итә.

Вәкил шунда ук «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» оешмасының баш табибына мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен карау һәм мөмкин булган ярдәмне күрсәтү турында хат җибәрде.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе»нең баш табибы Вәкаләтле вәкил хатына җавап итеп, пациентның 31 июльдә табиб-гематологка консультациягә чакырылуы турында хәбәр итә.

«Халык контроле» системасына 3 774 гражданның медицина ярдәме алу проблемаларына бәйле хәбәрләре керде.

2023 елда кире элемтә платформасы аша килгән 43 меңгә якын гражданның шикаятьләре сәламәтлек саклау проблемаларына кагылган, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 72% тәшкил иткән.

Узган ел белән чагыштырганда әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләр саны 26%ка арткан.

Гражданнар мөрәҗәгать иткән сорауларның төп категорияләре: табибка электрон язылу (26 751 хәбәр), электрон медицина документлары (13 361), вакцинация (423) һәм ташламалы дару белән тәэмин итү (124) мәсьәләләре.

2024 елның гыйнварында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының йомгаклау коллегиясендә «Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүдә цифрлы технологияләрне куллану» темасына доклад белән катнашты, аның барышында 2023 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына һәм кире элемтә платформасына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауга игътибар итте.

• «Мәгарифкә хокук һәм мәдәни кыйммәтләргә хокук» – 261 сорау.

Хисап чорында күрсәтелгән мөнәсәбәтләр өлкәсендә гражданнарның иң күп мөрәҗәгатьләре – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар бирү; балаларны, беренче сыйныфка кабул иткәндә якындагы гомуми белем бирү оешмаларына кабул итү; сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту; уку йортларында уку процессын оештыру; белем бирү процессында катнашучылар арасында низаглы хәлләр булу.

Мисал:

Вәкаләтле вәкил Аппаратына Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Кызыл Яр төп гомуми белем бирү мәктәбе»ндә (алга таба – Кызыл Яр мәктәбе) балаларны тиешенчә укыту шартлары булмау һәм санитар-эпидемиологик нормалар бозылу турында гражданка Т. дан шикаять керде.

Мөрәҗәгать итүченең шикаятендә әйтелгән дәлилләрне һәрьяклап өйрәнү максатыннан, Аппарат хезмәткәре, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты вәкилләре белән берлектә, 2023 елның 31 мартында шартларны урынга барып тикшерде.

Урынга барып тикшерү барышында мәктәпнең җайлаштырылган кирпеч бинада урнаштырылуы ачыкланган (сәүдәгәр Михаил Тимофеевич Атлашкинның элеккеге йорты, якынча 1912 елда төзелгән). Мәктәпкә нигез салынганнан бирле бина капиталь ремонтланмаган.

Без игътибар иткән кискен сорауларның берсе – мәктәп укучылары өчен бәдрәф бүлмәсендә тиешенчә булмаган санитар-көнкүреш шартлары.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, укучыларның хокукларын яклау максатыннан, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы адресына мәктәп бинасына капиталь ремонт үткәрүне оештыру, шул исәптән бәдрәф бинасын реконструкцияләү буенча чаралар күрү кирәклеге турында хат җибәрде.

Хатны карау йомгаклары буенча Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты мәктәп бинасына капиталь ремонт проектын эшләүне оештыруы турында хәбәр итте. Гражданка Т. шикаяте контрольдә кала.

2023 елда мәгариф мәсьәләләре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарның 897 хәбәрнамәсе бастырылган, шуларның 697се буенча чаралар күрелгән.

Иң күп мөрәҗәгатьләр – Казан (221), Чаллы (96), Түбән Кама (45), Әлмәт (34), Бөгелмә (32), Питрәч (21) муниципаль районнары һ.б. буенча килгән.

2023 елда кире элемтә платформасы аша мәгариф мәсьәләләре буенча 906 мөрәҗәгать килгән (мәгариф оешмалары хезмәтләре өчен түләү, белем бирү оешмаларына урнашу, белем бирү оешмаларын төзекләндерү, мәгариф оешмаларында туклану һ.б.).

• «Гаиләне, аналарны, аталарны һәм балаларны яклау» – 97 сорау.

Хисап чорында балаларның яшәү урынын билгеләү, аларның сәламәтлеге торышы, бала язмышы өчен борчылу, балалары, оныклары белән аралашу, гаилә әгъзаларына кабаттан яки беренчел документлар алу һәм опека һәм попечительлек органнары хезмәткәрләре эшенә кагылышлы мөрәҗәгатьләр килде.

Мисал:

Вәкаләтле вәкил Аппаратына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиясенең (алга таба – балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия) балигъ булмаган А.ны балигъ булмаганнар өчен вакытлыча тоту үзәгенә 30 тәүлеккә урнаштыру турында судка үтенеч юллау турындагы карары белән килешмәү турында граждан А. дан мөрәҗәгать килде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы хезмәткәрләре, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы сәркатибе белән берлектә Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәренең урынга барып тикшерүе барышында, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия тарафыннан балигъ булмаган А. га карата Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 нчы маддәсе 2 өлеше буенча җинаять эше кузгатудан баш тарту турындагы карарны карау нәтиҗәләре буенча суд алдында балигъ булмаган баланы эчке эшләр органнарының балигъ булмаган хокук бозучылар өчен вакытлыча тоту үзәгенә урнаштыру турында үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә карар кабул ителгән. Шул ук вакытта 120-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләрендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия тарафыннан балигъ булмаганнарны эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар өчен вакытлыча тоту үзәгенә урнаштыру турында судка үтенеч җибәрүе каралмаган.

Без шулай ук А.га карата җинаять эше кузгатудан баш тарту турындагы материалны караганда, А. ның законлы вәкиленә (атасына) эш материаллары белән танышу мөмкинлеге бирелмәгәнлеген ачыкладык.

Бу шартларда Вәкаләтле вәкил А. һәм аның законлы вәкиле (атасы) хокукларын бозган вазыйфаи затларга карата дисциплинар эш кузгату турында үтенеч белән мөрәҗәгать итте.

Хатны карау нәтиҗәләре буенча балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия тарафыннан Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча полиция начальнигы урынбасары исеменә күрсәтмә чыгарылды. Закон таләпләрен бозган һәм хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкармаган өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлеге җитәкчесе боерыгы белән ПДН инспекторына телдән кисәтү игълан ителде.

• «Уңайлы мохиткә хокук һәм җиргә хокук» – 81 сорау.

Бу төркемнең мөрәҗәгатьләренең төп өлеше җирдән файдалану мәсьәләләренә кагылган. Үзләренең гаризаларында гражданнар җир хокукый мөнәсәбәтләренә бәйле бәхәсле хәлләрне чишүне, җир кишәрлекләрен файдалануга бирергә ярдәм итүләрен сорадылар, шулай ук кадастр инженерлары эшчәнлегенә шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Мисал:

2023 елның 12 июлендә Вәкаләтле вәкилгә граждан С. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органының аңа җир участогы бирүдән баш тартуы белән килешмәве турында мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать текстыннан күренгәнчә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе һәм мөрәҗәгать итүченең крестьян-фермер хуҗалыгы арасында 2018 елның 9 гыйнварында 2023 елның 9 гыйнварына кадәр гамәлдә булу срогы белән җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелгән.

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 нче маддәсенең 2 пунктының 9 бүлекчәсе нигезендә граждан 2022 елның 12 гыйнварыннан, ягъни җир кишәрлеген арендалау килешүе гамәлдә булган чорда, Мамадыш районы җирле үзидарә органына муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сату-алуларсыз бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә. Әмма Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органы аны бу баш тартуның сәбәпләрен күрсәтмичә кире кага.

2023 елның 18 июлендә Вәкаләтле вәкил тарафыннан Мамадыш муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе адресына граждан С. мөрәҗәгатен карап, мөрәҗәгать итүчегә һәм безнең адреска Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 нчы маддәсендә каралган таләпләрне исәпкә алып, җир бирүдән баш тарту сәбәпләре турында мәгълүмат бирүне сораган хат җибәрелде.

Мамадыш муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җавабында соралган мәгълүмат булмау сәбәпле, Вәкаләтле вәкил район прокуроры адресына мөрәҗәгатьне карап, кирәк булганда, прокурор реакциясе чараларын кабул итүне сорап хат җибәрде.

Әлеге хатны карау йомгаклары буенча район прокуратурасы тарафыннан Мамадыш муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 нче маддәсе 2 пункты, 39.16 нчы маддәсе 17 пункты таләпләрен бозуы ачыкланды һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына закон бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр кертелде.

Теманың актуальлеге турында шулай ук гражданнарның «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында әлеге тематика буенча басылган мөрәҗәгатьләре дә дәлилли. Әлеге кире элемтә каналы ярдәмендә хисап елында «Экология» юнәлеше буенча гражданнарның 1 720 хәбәрнамәсе басылып чыкты, шуларның иң күбе «Чүплекләр» – 766 хәбәрнамә, «Һава» – 658 хәбәрнамә, «Су» – 183 хәбәрнамә.

Мәгълүмат системасында санкцияләнмәгән чүплекләр проблемасы буенча иң күп мөрәҗәгатьләр – Казан шәһәре (347 хәбәрнамә), Чаллы шәһәре (51), Яшел Үзән (39), Лаеш (38), Тукай (33), Биектау (31) муниципаль районнары һ. б. буенча бастырылган.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына һәм кире элемтә платформасына гражданнардан килгән экология проблемаларына кагылышлы мөрәҗәгатьләрне сыйфатлы һәм оператив үтәү максатыннан, «Татарстан Республикасы төбәк белән идарә итү үзәге»нең Проект офисы экологиянең актуаль проблемаларына һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итүгә багышланган утырышын уздырды.

Мисал:

2019 елдан башлап Казан шәһәренең Фурманов урамындагы күпфатирлы авария хәлендәге йортларны сүткәннән соң барлыкка килгән законсыз төзелеш калдыклары чүплекләрен бетерү мәсьәләләре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнардан килгән хәбәрләр үз чишелешен тапмады.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, әлеге чүплекне бетерү һәм төзелеш калдыкларын утильләштерү өчен 4 млн сумга якын акча тапты.

2023 елда популярлыгы һәм әһәмияте буенча икенче урында – «Хәрби хезмәткә чакырганда кеше хокукларын яклау, хәрби хезмәткәрләрне яклау» блогы – 912 мәсьәлә, шул исәптән түбәндәге темалар буенча:

– альтернатив гражданлык хезмәте – 17;

– кичектерүләр, чакыру тәртибе, хәрби комиссариатлар эше, чакыру комиссияләре эше – 84;

– хәрби хезмәткәрләрнең вазыйфаи вәкаләтләрен һәм хезмәт бурычларын үтәү; контракт буенча хәрби хезмәтне узу, контрактны озайту, вакытыннан алда хезмәттән азат итү; чакырылыш буенча хезмәтне узу, ант кабул итү, вакытыннан алда эштән азат итү; хәрбиләрнең хокуксыз тәртибе; хезмәтне үтү чорында сәламәтлекне саклау һәм медицина ярдәме алу хокукы – 296;

– хәрби хезмәттән азат ителгән хәрбиләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын социаль яклау – 515.

Әлеге блокка кергән мөрәҗәгатьләр Россия Федерациясе Оборона министрлыгы, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Казан гарнизоны Хәрби прокуроры, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә контрольгә алына һәм оператив тәртиптә карала.

«Җинаять процессында, мәҗбүри тоту урыннарында, административ хокук бозулар буенча эшләрдә, суд эшләрендә кеше хокукларын яклау» блогына кергән мәсьәләләр саны элеккечә күп булып кала – 839, шул исәптән тоткарланганнарның, шикләнелүчеләрнең, гаепләнүчеләрнең хокукларына кагылышлы – 151; зыян күрүчеләрнең хокуклары – 163; җинаять-башкару системасында хөкем ителгәннәрнең хокуклары – 410; административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча эш алып барганда хокуклар – 5; суд карарларына шикаять биргәндә хокуклар – 43.

Хисап чорында җинаять эшләрен кузгатуның нигезсезлегенә шикаятьләр (мөрәҗәгатьләр, гаризалар); җинаять суд эшләрен алып бару срокларының озынлыгына; тикшерү гамәлләренең законлылыгына; җинаять эшләре буенча хөкем карарларының законлылыгына, нигезлелегенә һәм гаделлегенә кагылышлы шикаятьләр (мөрәҗәгатьләр, гаризалар) килү дәвам итә.

Суд тарафыннан ирегеннән мәхрүм итү турында карар кабул ителгән, җәмгыятькә куркыныч гамәлләр кылган затларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә кагылышлы һәр мөрәҗәгать игътибар белән карала, шул исәптән урынга чыгып та.

Мәсәлән, 2023 елда Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан турыдан-туры һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә, 6 төзәтү учреждениесенә, 2 тикшерү изоляторына, 2 төзәтү үзәгенә һәм җинаять-башкару системасының төзәтү үзәге режимында эшләүче 7 участокка бару максаты белән 16 эш сәфәре оештырылды.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре турыдан-туры, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә тоткыннарны тоту шартларын тикшерү максатларында, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең 4 нче номерлы «Юдино», 7 нче номерлы «Гагарин», 16 нчы номерлы «Япеев», 11 нче номерлы «Восход» полиция бүлекләренә, шулай ук Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсенә бардылар.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты һәм Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын үтәүне тикшерү буенча расланган график кысаларында 14 учреждение тикшерелде: Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач, Биектау, Кукмара, Саба, Нурлат, Чирмешән, Аксубай Чистай, Әгерҗе, Алабуга, Яшел Үзән, Мамадыш, Балык Бистәсе һәм Менделеевск муниципаль районнары буенча бүлекләре.

Мисал:

Вәкаләтле вәкил Аппаратына Мари Эл Республикасында КП-7 ФКУ каршындагы төзәтү үзәгендә җәзасын үтәүче граждан А.ның якын туганнары белән аралаша алмау сәбәпле, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төзәтү учреждениесенә күчерүдә ярдәм итү турында мөрәҗәгате килә.

Безнең мөрәҗәгать нәтиҗәләре буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте директоры хөкем ителгән кешене якын туганының яшәү урыны буенча якын учреждениегә күчерү турында уңай карар кабул итте.

«Финанс һәм хуҗалык эшчәнлеге өлкәсендә кеше хокукларын яклау» блогындагы сораулар – 266.

Бу блокта салым салу, акча системасы һәм акча әйләнеше, иминиятләштерү, төзекләндерү һәм инфраструктура, элемтә күрсәтү хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, төзелеш, халыкка хезмәт күрсәтү, каты коммуналь калдыклар белән эш итүгә бәйле темалар күтәрелә.

2023 елда «Төзекләндерү һәм инфраструктура» юнәлеше буенча гражданнарның 39 102 мөрәҗәгате басылып чыкты.

Иң күп мөрәҗәгатьләр: Казан шәһәре буенча – 17 247, Чаллы шәһәре буенча – 5 255, Әлмәт шәһәре буенча – 1 772, Бөгелмә шәһәре буенча – 1 217, Түбән Кама шәһәре буенча – 979, Яшел Үзән шәһәре буенча – 579, Лениногорск шәһәре буенча – 544, Алабуга муниципаль районы буенча – 384.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 2023 елда министрлыклар, ведомстволар һәм муниципаль берәмлекләр белән территорияләрне төзекләндерү һәм инфраструктураны үстерү мәсьәләләре буенча уртак эш нәтиҗәсендә гражданнарның 81% яки 22 687 мөрәҗәгате уңай хәл ителгән.

«Гражданлык һәм сәяси хокуклар һәм ирекләр» блогы сораулары – 153.

Әлеге хокуклар төркемен тәшкил итүче мөрәҗәгатьләрнең күбесе дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү хокукын бозу мәсьәләсе буенча килгән. Бу проблемалар белән еш кына Казан шәһәрендә яшәүче гражданнар очраша, алар вазыйфаи затларның шәхси кабул ителүенә язылып булмау, мөрәҗәгатьләрне карау сроклары һәм аларны карау нәтиҗәләре белән килешмәү, хакимият органнарыннан алынган җавапларның сыйфаты белән килешмәү турында хәбәр итә.

«Законлы көченә кергән суд актларын үтәгәндә кеше хокукларын яклау» блогында сораулар саны кими – 144.

Бу блокта суд приставлары хезмәте эшчәнлегенә, суд карарларын үтәмәүгә, гаилә әгъзаларының алимент йөкләмәләренә кагылышлы мәсьәләләр бар.

Мисал:

2023 елның 31 мартында Вәкаләтле вәкил адресына Питрәч районында яшәүче гражданка Г., 2000 елда туган кызы Ш.ны дару препараты белән тәэмин итү турындагы суд карарын үтәү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгатьнең эчтәлегеннән һәм кушымтадагы документлардан күренгәнчә, Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов район суды кызны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына «Рисдиплам» препараты белән тәэмин итүне оештыруны йөкләве турында карар чыгарган.

Борчылу белдереп, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Баш суд приставы адресына, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе хезмәткәрләре гамәлләренең законлылыгы турында шикаятьтә язылган дәлилләрне тикшерүне оештыруны сорап хат җибәрде.

Вәкаләтле вәкилнең хатына җавап итеп, без Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә әлеге дару препаратын сатып алуга республика бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирелгәнлеге турында мәгълүмат алдык.

2023 елның 3 апрелендә дару препаратына рецепт язылган, һәм 4 апрельдә препарат кулланылышка әзерләнгән һәм Г.га бирелгән.

Башка сораулар буенча 260 мөрәҗәгать килгән.

Гражданнардан ел саен алынган мәгълүмат күләме республика халкының кискен һәм социаль әһәмиятле проблемаларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Әлеге бүлеккә йомгак ясап, шуны билгеләп үтәргә кирәк, кайбер темалар буенча 2023 ел дәвамында гражданнарның мөрәҗәгатьләре саны үзгәрде. Мәсәлән, быел хәрби хезмәт мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең шактый артуы күзәтелә. Шуңа бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил Аппараты хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары мәсьәләләрен хәл итүдә федераль һәм республика хакимият органнары, муниципаль берәмлекләр һәм иҗтимагый оешмалар белән берлектә төрле чаралар күрергә, ярдәм күрсәтергә омтылды.

Мөрәҗәгатьләрнең башка категорияләренә карата, уртача алганда, аларның актуальлек тенденцияләре саклана.

Куелган бурычларга ярашлы рәвештә, гражданнарның хокукларын яклау буенча эш 2024 елда да дәвам итәчәк.

2 НЧЕ БҮЛЕК. МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯ ШАРТЛАРЫНДА ГРАЖДАННАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Безнең ил өчен бу авыр вакытта, илебезнең һәм халкыбызның киләчәген билгеләүче мөһим тарихи вакыйгалар чорында, Россия Федерациясе Президенты 2023 елның 21 февралендә Федераль Җыенга булган Юлламасында билгеләп үткәнчә, «Безнең бурыч – туганнарын, якыннарын югалткан гаиләләргә ярдәм итү. Махсус хәрби операциядә катнашучы һәр кешенең гаиләсе даими игътибар зонасында булырга, кайгырту һәм хөрмәт белән әйләндереп алынырга тиеш».

Шуңа бәйле рәвештә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, сугыш хәрәкәтләре ветераннарына, локаль конфликтларда катнашучыларга ярдәм итүнең гамәлдәге чараларына өстәп, 2023 елда федераль дәрәҗәдә, шул исәптән торак, медицина, салым, транспорт ташламалары, кредит каникулларына хокук һәм башкалар буенча бирелгән ярдәм чараларын киңәйтү өстендә эш дәвам итте. Аларның исемлеге гел арта.

Федераль дәрәҗәдә кабул ителгән ярдәм чараларының киң исемлеге белән беррәттән, Татарстан Республикасында хисап елында махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләләргә өстәмә ярдәм чараларын, шул исәптән финанс ярдәмен, социаль хезмәт күрсәтү, мәгариф һәм мәдәни-ял оешмалары һәм салым салу өлкәсендәге ташламаларны һәм преференцияләрне билгеләү буенча эш башкарылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 07.11.2023 елгы 1427 нче карары белән хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның аерым категорияләренең социаль яклану дәрәҗәсен арттыру максатыннан, хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның аерым категорияләре арасыннан гражданның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына бер тапкыр бирелә торган 20 000 сум күләмендә акчалата түләү билгеләнде.

Гражданнарга йорт хуҗалыгы участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алу чыгымнарын түләүгә адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 11.03.2023 елгы 231 нче карары белән чикләр эчендә газ үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидия бирелә.

Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булган 26.10.2023 елгы 738 нче Указы нигезендә, 2023 елның 31 августыннан соң Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән хәрбиләрнең аерым категорияләренә социаль ярдәм чарасы буларак, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Хәрби комиссариаты белән берлектә, Казан шәһәре хәрби хезмәткә контракт буенча алу пункты тапшырган исемлекләр нигезендә 305 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләнде.

Муниципаль дәрәҗәдә дә өстәмә ярдәм чаралары билгеләнде.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм күрсәтүдән тыш, республикада аларның гаиләләренә дә адреслы ярдәм оештырылган.

Республикада оештырылган «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәтенең республика штабы булышлыгы белән, анда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар, ирекледәр, бизнес һәм сәяси партияләр вәкилләре керде, мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләренә адреслы ярдәм җайга салынды. Татарстанның барлык муниципаль берәмлекләрендә муниципаль хакимият органнары белән берлектә мобилизацияләнгән кешеләр гаиләләренең социаль портретларын төзү буенча эш алып барылды. Һәр гаилә белән шәхси элемтә урнаштырылган.

Махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәгәндә һәлак булган хәрбиләрнең гаиләләрен социаль яклау практикасы кертелә. Комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә «гаилә ярдәмчесе» билгеләнә, ул һәлак булган кешенең гаиләсе белән хезмәттәшлек итә, дәүләт хакимияте органнары белән берлектә барлык мөһим мәсьәләләрне хәл итүдә булышлык күрсәтү максатыннан мөрәҗәгать итү өчен кирәкле органнар, учреждениеләр һәм оешмалар турында хәбәр итә.

«Барысы да үзебезнеке» марафонын дәвам итеп, һәм «Үзебезнекеләр турында кайгырту» республика программасын тормышка ашыру кысаларында, 2023 елның ноябрендә Татарстан Республикасында «Үзебезнекеләр турында кайгырту» мәгълүмати ресурсы эшли башлады, ә telegramда чат-бот эшли башлады, анда гражданнар аңлау өчен махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә республикада гамәлдә булган ярдәм чаралары турында мәгълүмат тупланды һәм системалаштырылды.

Әлеге мәгълүмат ресурслары ярдәм чаралары алучылардан кире элемтәне гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә.

2024 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында әлеге юнәлеш буенча өстәмә рәвештә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча яңа категорияләр кертелә.

Үз чиратында, гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрен эшкәртү максатында, 117 «кайнар элемтә» телефоны операторларын, дәүләт хакимиятенең җаваплы органнарын, муниципаль берәмлекләрне һәм «Ватанны саклаучылар» дәүләт фонды филиалын җәлеп итеп, «Халык контроле»н куллану планлаштырыла.

Күптонналы гуманитар ярдәм махсус операция зонасына Татарстан Республикасыннан баштан ук килде. Республикабызның битараф булмаган кешеләре җыйган җиһазларны, медикаментларны, киемнәрне һәм азык-төлекне хәрби бүлекчәләр соравы буенча тапшыру максатыннан, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре махсус хәрби операциягә чиктәш зонага өч тапкыр барды. Вәкаләтле вәкил Аппараты коллективы кирәкле әйберләрне җыюда да катнашты.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына федераль дәрәҗәдә, шулай ук Татарстан Республикасында оештырылган яклау системасы шартларында, Вәкаләтле вәкилнең бурычы, узган елда аны тормышка ашыруда булышлык күрсәтү иде.

Вәкаләтле вәкилнең «Ватан сугышчылары гаиләләре комитеты»ның төбәк вәкиллеге белән тыгыз хезмәттәшлеге җайга салынган. Татарстан Республикасының Арча, Питрәч, Кукмара муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә хәрби хезмәткәрләрнең туганнары һәм якыннары белән очрашулар үткәрелде, аларның нәтиҗәләре буенча махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итүнең кабул ителгән социаль-икътисадый чаралары турында агарту эше оештырылды. Урында, муниципаль районда ярдәм таләп итә торган мәсьәләләрне хәл итү вариантлары тикшерелде, ә кирәкле очракларда профильле министрлыклар һәм ведомстволар кушылды.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән уртак тәкъдимнәр эшләү максатыннан, 2023 елның июлендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм «Ватанны саклаучылар» дәүләт фонды филиалы арасында килешү имзаланды.

Килешүгә ярашлы рәвештә, Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппарат хезмәткәрләре 2023 елда Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан хәрби госпитале базасында, «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының төбәк фи-

лиалы тарафыннан, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе, «Татарстан Республикасы дәүләт юридик бюросы» вәкилләре катнашында оештырылган уртак кабул итүләрдә катнаштылар, аның кысаларында махсус хәрби операциядә катнашучы 82 кеше ярдәм сорап мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкил, ике тапкыр, хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның туганнарын «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының төбәк филиалы җитәкчесе белән бергә кабул итүдә катнашты.

2023 елның икенче яртысында, Вәкаләтле вәкил катнашында, мобилизацияләнгән гражданнарның туганнарының, аларның тормышлары һәм сәламәтлекләре өчен борчылып, республика җитәкчелегенә һәм хакимият органнарына юлланган күмәк мөрәҗәгатьләре уңаеннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Казан хәрби гарнизоны Хәрби прокуратурасы вәкилләре белән берлектә, 1231 нче, 1234 нче полкларда хәрби хезмәт үтүче хәрбиләрнең туганнарын һәм якыннарын кабул итүләр үткәрелде.

Гомумән алганда, Вәкаләтле вәкил адресына хисап елында хәрби хезмәткәрләрдән, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнардан һәм аларның туганнарыннан 2 818 мөрәҗәгать һәм хәбәр килгән, шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының кире элемтә платформасы аша – 1 895, Татарстан Республикасында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат элемтә системасы аша – 11, турыдан-туры Вәкаләтле вәкил Аппаратына – 912.

Вәкаләтле вәкилгә килгән сораулар арасында бу тема иkенче иде.

Хисап елында без хәрби хезмәткәрләргә кирәкле күләмдә акчалата түләүләр, яраланган өчен түләүләр, хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегәндә бер тапкыр бирелә торган түләүләр мәсьәләләрен хәл итү эшенә кушылдык. Әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр саны – 310.

Бу мәсьәләләрне хисап елында «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Бердәм исәп-хисап үзәге» федераль казна учреждениесе, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм аның финанс органнары белән бергәләп эшләү нәтиҗәсендә хәл итәргә мөмкин булды.

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары хәрбиләрнең яраланганнан соң хәрби-табиб комиссиясен узуда ярдәм күрсәтү һәм аларга тиешле медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итәләр.

Әлеге категориядәге барлык мөрәҗәгатьләрне без Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Казан гарнизоны Хәрби прокуратурасы белән берлектә карадык. Булышуны сорап, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать иттек.

2023 елның ноябрендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты Ә.М. Хәмитов белән берлектә аерым тематик кабул итү уздырылды, аның барышында хәрбиләрнең төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән өч туганы кабул ителде.

Төп сораулар арасында хәрбиләрнең туганнарының аларны эзләүдә ярдәм итү яки әсирлеккә алынган Украина гражданнарына алмашу үтенечләре бар.

Бу өлешендә без Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова белән тыгыз хезмәттәшлек иттек, шулай ук Россия Федерациясе оборона министрлыгына мөрәҗәгатьләребезне җибәрдек. Барлыгы бу тематика буенча 60 мөрәҗәгать җибәрелгән.

Федераль омбудсмен ярдәме белән безнең сигез якташыбызны әсирләр алмашу исемлегенә кертергә һәм туган илләренә кайтарырга мөмкин булды.

Хәбәрсез югалган яки әсирлеккә эләккән хәрбиләрнең гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтү буенча Вәкаләтле вәкил кичекмәстән хәл итүне таләп итүче аерым проблемалы мәсьәләләрне дә ачыклады.

Мәсәлән, 27.05.1998 елгы 76-ФЗ нче «Хәрби хезмәткәрләрнең статусы турында» федераль законның 2 нче маддәсенә ярашлы рәвештә, хәрби хезмәткәр әсирлеккә алынган очракта, шулай ук аның хәбәрсез югалуы очрагында, ул закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган яки үлгән дип игълан ителгәнче, хәрби хезмәткәр статусы саклана.

Күрсәтелгән хәрбиләр өчен матди һәм башка төр тәэмин итү чаралары саклана, алар әсирлеккә алу яки азат итү шартлары тулысынча ачыкланганчы яки аларны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган яки үлгән дип игълан ителгәнче, алар белән бергә яшәүче хатыннарына яки гаиләләренең башка әгъзаларына түләнә (билгә).

Хатынына яки гаиләнең башка әгъзаларына мондый түләүләр кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.07.2000 елгы 524 нче карары белән каралган.

Шул ук вакытта килгән мөрәҗәгатьләрне анализлаудан күренгәнчә, гамәлдә хәрбиләрнең гаилә әгъзалары аларны алуда кыенлыклар белән очрашкан.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 14 июлендәге 524 нче карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә акчалата тәэмин итүләргә тиешле хәрби хезмәткәрнең гаилә әгъзаларына хәбәр итүнең конкрет срокларын, түләүләрне билгеләү срокларын билгеләмәү хәбәрсез югалган статусында булган хәрби хезмәткәрнең гаилә әгъзалары тарафыннан түләүләрне алу срокларын озайтуга китергән.

Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасының 2023 елның июнендә гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитетының «түгәрәк өстәл» утырышында, хәрби хезмәткәрләрнең әсирлектә булу, хәбәрсез югалу факты турында хәрби хезмәткәрнең гаилә әгъзаларына хәбәр итү срокларын, шулай ук акчалата тәэмин ителеш түләүләрен билгеләү срокларын төгәлләштерү өлешендә норматив-хокукый җайга салуны камилләштерүгә ярдәм итү максатларында, Вәкаләтле вәкилләргә тиешле норматив хокукый актны эшләү мәсьәләсен карарга тәкъдим ителде.

Өстәмә рәвештә бу мәсьәлә буенча 2023 елның июлендә Вәкаләтле вәкил Дәүләт Думасының гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе Н.А. Останина һәм федераль омбудсмен Т.Н.Москалькова адресына мөрәҗәгать итте.

Безнең мөрәҗәгать белән бәйле рәвештә федераль омбудсмен Россия Оборона министрлыгының фикерен сорады. Бу мәсьәлә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравында.

Безнең тәкъдимнәр 2023 елның октябрендә Мәскәү шәһәрендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән оештырылган «Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә комплекслы социаль ярдәм күрсәтүнең заманча алымнары» тебәкара инновацион-гамәли конференция нәтиҗәләре буенча кабул ителгән, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2000 елның 14 июлендәге 524 нче карарының 4 нче кушымтага тиешле үзгәрешләр кертүгә кагылышлы резолюциядә да чагылыш тапты.

Вәкаләтле вәкилнең аерым игътибары хәрби хезмәткәрләрне дәвалау һәм медицина реабилитациясе буенча хезмәтләр алу, шул исәптән заманча технологияләр һәм җиһазлар кулланып, югары технологияле тернәкләндерүгә кагылышлы мөрәҗәгатьләргә юнәлтелде. Әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр саны – 132.

Булышлык күрсәтү үтенече белән без, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Баш хәрби-медицина идарәсе начальнигына, ә кичектергесез очракларда турыдан-туры Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгатьләр җибәрдек.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: республикада хәрби бурычларны үтәүче гражданнарыбызны кирәкле медицина ярдәме белән, шул исәптән фән һәм техниканың заманча казанышларына нигезләнгән катлаулы һәм уникаль медицина технологияләрен кулланып тәэмин итү, шулай ук реабилитация чараларын һәм махсуслаштырылган психиатрия ярдәмен вакытында күрсәтү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәме күрсәтү буенча җаваплылык үзәге итеп Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпитале», Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпитале» билгеләнгән.

2023 елның гыйнвар – ноябрь айларында госпитальләрдә махсус хәрби операциядә катнашучы 1023 граждан дәвалану курсы узды.

Хисап елы ахырына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика клиник хастаханәсендә махсус хәрби операция чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрбиләренә медицина ярдәме күрсәтү, дәвалану өчен 200 койка бар.

03.07.2023 елдан башлап беренчел медицина-санитар (амбулатор) һәм махсуслаштырылган психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында 70 медицина-психологик консультация кабинеты ачылды. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстенлекле тәртиптә «медицина психологиясе» профиле буенча медицина ярдәме күрсәтү тәэмин ителә.

Татарстан Республикасында пациентларны медицина реабилитациясе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 1.02.2023 елгы 107 нче «Татарстан Республикасы медицина оешмаларында өлкәннәргә медицина реабилитациясе оештыру турында» боерыгы белән расланган маршрут буенча өч этапта, 19 кан тамырлары үзәгендә, травматология профилендәге 21 бүлекчәдә, 7 ЧКВ-үзәктә, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор М.З. Сигал исемендәге республика клиник онкология диспансеры»нда, гомуми койкалы куәте 435 урынлы 10 медицина оешмасында (медицина реабилитациясе бүлекчәләренең тәүлек әйләнәсе стационарлары шартларында), 14 медицина оешмасында (көндезге стационарлар шартларында) һәм тагын 14 медицина оешмасында (амбулатор шартларда) башкарыла.

01.01.2024 елдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.10.2023 елгы 1323 нче карарына ярашлы рәвештә, социаль-реабилитация бүлекчәләрендә, инвалидларны реабилитацияләү үзәкләрендә социаль хезмәтләр, сугыш хәрәкәтләре инвалидлары белән беррәттән, 2022 елның 24 февраленнән Украина территориясендә, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, шулай ук 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә булышлык итүче оешмалар белән контракт төзегән (башкача хокукый мөнәсәбәтләрдә булган) затларга, бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә алынган яралану, контузия, имгәнү яки авыру нәтиҗәсендә инвалид булганнарга күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2024 елның 1 гыйнварыннан халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы «Идел» «инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәге» (Татарстан Республикасы, Яшел Үзән шәһәре) базасында авыр җәрәхәтләр алган һәм карауга мохтаҗ булган махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен, елына ике тапкыр, өч айлык социаль реабилитация курслары үтү өчен 10 урынлы бүлек ачыла.

Шул ук вакытта, республикада кабул ителгән чараларга карамастан, Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр барлык мәсьәләләрнең дә әле хәл ителмәгәнлеген күрсәтә. Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән хезмәттәшлектә һәр конкрет очракны карап чыгабыз.

Махсус хәрби операциядә катнашканда җитди җәрәхәтләр алган хәрбиләрнең актив тормышын дәвам итүнең мөһим аспекты булып, аларның тормышның барлык өлкәләрендәге ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алу тора. Беренчедән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр урамда түгел, ә яшәү урынында төп кыенлыклар белән очраша ала.

Торак законнары нормаларына ярашлы рәвештә, күпфатирлы йортның йорт яны территориясендә инвалидлар өчен парковка урыннары оештыру һәм күпфатирлы йортта пандус урнаштыру мәсьәләләре, күпфатирлы йортта бина милекчеләренең гомуми җыелышында каралырга тиеш.

Шуңа бәйле рәвештә гамәлдәге нормаларны нәтиҗәле тормышка ашыру максатыннан җирле үзидарә органнары һәм идарәче оешмаларның актив катнашуы таләп ителә.

Мобилизацияләнгән гражданнарның туганнарының төрле ярдәм күрсәтүгә (азык-төлек һәм дарулар китерү, көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү), шулай ук консультация характерындагы мөрәҗәгатьләре, шул исәптән торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү, кредит каникуллары һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына бушлай туклану бирү һәм башкалар аерым игътибарга лаек булды.

Әлеге категориядәге мөрәҗәгатьләр оператив тәртиптә профильле министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре һәм муниципаль берәмлекләр башлыклары белән үзара хезмәттәшлектә хәл ителде.

Ватандашларыбыз махсус хәрби операциядә катнашкан шартларда, Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хәрбиләр һәм аларның гаиләләре белән эшләүнең барлык мәсьәләләренә һәм формаларына җәлеп ителде, мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү чаралары комплексын гамәлгә ашыруда ярдәм итте, ул федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә кабул ителде, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтүдә катнашты.

3 НЧЕ БҮЛЕК. ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ КЕШЕНЕҢ СОЦИАЛЬ, ИКЪТИСАДЫЙ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ХОКУКЛАРЫН САКЛАУ БУЕНЧА ЭШЧӘНЛЕГЕ

3.1. ХЕЗМӘТ ХОКУКЛАРЫ

Россия гаиләләренең иминлеге, тормыш сыйфаты, димәк, демографик вазгыять тә социаль өлкәдәге хәлләргә турыдан-туры бәйле.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023–2030 елларга Татарстан Республикасында керемнәре ярлылык чигеннән түбән булган халык өлешен киметү буенча төбәк программасы расланды, аның максатлары – халыкның керемнәре тотрыклы үсеш темпларын һәм пенсия белән тәэмин итү дәрәҗәсен инфляциядән түбән булмаган дәрәҗәдә тәэмин итү, 2030 елга Татарстан Республикасының 2017 ел күрсәткече белән чагыштырганда ике тапкырга ярлылык дәрәҗәсен киметү.

Ярлылык дәрәҗәсенең кимүенә халыкның иң зәгыйфь төркемнәренә юнәлдерелгән адреслы социаль программаларны гамәлгә ашыру, шулай ук хезмәт хакы һәм пенсияләр үсеше йогынты ясый.

Халыкка дәүләт социаль ярдәменең эзлекле гамәлгә ашырыла торган программасы балалары булган, авыр тормышта булган һәм дәүләт ягыннан социаль яклауга мохтаҗ гаиләләргә социаль яклау чаралары бирү системасының иң мөһим өлешләренең берсе булып тора.

Дәүләт социаль ярдәмен алучылар арасында керемнәре түбән булу белән бәйле тормыш проблемаларын үзләре хәл итә алмаган гражданнар шактый зур өлешне тәшкил итә. Бу – беренче чиратта, инвалид балалары булган гаиләләр, тулы булмаган һәм күп балалы гаиләләр.

2023 елда республикада 5 303 социаль контракт төзелгән (10,9 мең кеше), шуларның 93 проценты 4,9 мең гражданның хезмәт мәшгульлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Социаль контрактлар белән беррәттән, республикада аз тәэмин ителгән гражданнарга турыдан-туры социаль ярдәм чаралары гамәлдә. Социаль ярдәм чаралары системасы 6 федераль һәм 55 төбәк чарасын үз эченә ала. Бу – 1,18 миллион ярдәм алучы, шул исәптән 0,85 миллион – төбәк социаль түләүләрен алучылар.

Социаль контрактларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә гражданнарның 60,5 проценты кереме яшәү минимумы күләменнән артып китә, 82,2 процентының җан башына уртача кереме арта.

Билгеле, халыкның керем дәрәҗәсен күтәргәндә ярлылыкны җиңү, күпчелек гражданнар өчен эш хакыннан тора.

Статистик мәгълүматлар буенча, предприятие һәм оешма хезмәткәрләренә, шул исәптән кече эшмәкәрлек субъектларына исәпләнгән уртача хезмәт хакы 2023 елның гыйнвар – октябрь айларында 59 525,1 сум тәшкил иткән һәм 2022 елның тиешле чоры белән чагыштырганда 18,4% ка арткан. Реаль хезмәт хакы (товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә куллану бәяләре индексын исәпкә алып исәпләнгән,) 2023 елның гыйнвар – октябрь айларында 2022 елның тиешле чорына карата 113,2% тәшкил итә.

Планлаштырылган минималь хезмәт хакын арттыруга тагын бер минималь хезмәт хакы индексациясе өстәмә 10% ка үткәрелгән. Нәтиҗәдә, 2024 елның 1 гыйнварына минималь хезмәт хакы 19 242 сум тәшкил итте. (2023 елның 1 гыйнварына ул 16 242 сум тәшкил итте, 2022 елның 1 гыйнварына – 13 890 сум, 2021 елның 1 гыйнварына – 12 792 сум).

Шул ук вакытта бюджеттан тыш сектор оешмаларында һәм юридик зат булмыйча эшкуарлык эшчәнлеген алып баручы шәхси эшмәкәрләрдә минималь хезмәт хакы күләмен тәэмин итү максатыннан, даими рәвештә Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасында Эш бирүчеләр берләшмәсе координацион советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында айлык эш хакының минималь күләме турында килешүләр төзелә.

2024 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 27 декабрендәге килешү белән минималь хезмәт хакы аена 22 020 сум күләмендә билгеләнгән.

Хезмәт базарындагы хәл үз чиратында икътисадый процессларның чагылышы булып тора.

Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча, 2023 елның июль – сентябрь айларында Татарстан Республикасының 15 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк булган эшче көчләре саны уртача 2 068,8 мең кеше тәшкил иткән.

2024 елга Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә җан башына яшәү минимумы күләме – 13 135 сум (2023 елда – 12 219 сум), эшкә яраклы халык өчен 14 317 сум (2023 елда – 13 319 сум) тәшкил итте.

Республиканың хезмәт базарындагы хәл хезмәткәрләргә ихтыяҗның артуы һәм мәшгульлекнең югары дәрәҗәсе (62,1%), эшче көч тәкъдим итүнең түбән дәрәҗәсе белән характерлана, моның турында гомуми (2%) һәм теркәлгән эшсезлекнең түбән дәрәҗәсе (0,21%) шаһитлык бирә.

Хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты 2023 елның 1 декабренә 1 урынга 0,1 кеше тәшкил итә.

Хезмәт өлкәсендә хәл яхшыруын күрсәтүче рәсми статистика, Вәкаләтле вәкилдән эшкә урнаштыруны сорап мөрәҗәгать итүләр саны кимү белән туры килә. Хисап елында бу тема буенча мөрәҗәгатьләр бик аз иде.

Шул ук вакытта нәтиҗәле хезмәт базары үсү һәм минималь хезмәт хакы арту эш хакын түләмәү очраклары арту яки аны минималь күләмнән азрак түләү белән үрелеп барырга тиеш түгел.

Әлеге мәсьәләнең социаль әһәмиятен исәпкә алып, 2023 елның июлендә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы инициативасы белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре белән хезмәткә түләүнең минималь күләмен үтәүне тәэмин итү мәсьәләләре, шулай ук хезмәтне саклау турында законнар буенча видеоконференцияләр режимында берничә киңәшмәдә катнашты.

Киңәшмәләр барышында, тулы булмаган мәшгульлек дәрәҗәсе югары булу белән бергә, Кукмара, Зәй, Яшел Үзән, Түбән Кама, Нурлат, Чистай, Мамадыш, Теләче, Саба, Әлки, Балык Бистәсе, Әлмәт, Буа, Әтнә, Яңа Чишмә, Спас, Алексеевск, Аксубай, Биектау, Балтач, Бөгелмә муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә хезмәт хакын минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк түләүче оешмаларның артуы билгеләнә. (Федераль салым хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең 1 квартал мәгълүматлары буенча).

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматына ярашлы рәвештә, минималь хезмәт хакы күләмен саклау, шулай ук хезмәтне саклау турында законнарны үтәү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре белән киңәшмәләр йөкләмәләрен үтәү максатыннан муниципаль берәмлекләр 2023 елның I һәм II кварталлары өчен салым хезмәте исемлекләрен карадылар.

Яңа Чишмә муниципаль районының тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча территориаль ведомствоара комиссиясе тәкъдимнәрен үтәмәү сәбәпле, йөкләмәләр нәтиҗәләре буенча ике шәхси эшмәкәргә карата материаллар прокуратурага җибәрелде.

2023 елның 6 аенда производствода бәхетсезлек очракларына юл куйган оешма вәкилләре һәм җитәкчеләре белән хезмәтне саклау буенча координацион советларның чираттан тыш утырышларында, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Түбән Кама муниципаль районнарында үлем белән тәмамланган һәм производствода авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очракларының сәбәпләре җентекләп анализланды, (предприятиеләрдә) хезмәтне саклау буенча инструкцияләрне яңадан карау буенча чаралар исемлеге эшләнә, хезмәтне саклау һәм технологик җиһазларны эксплуатацияләү буенча чираттан тыш инструктажлар үткәрелә, шулай ук хезмәтне саклау таләпләрен белү буенча чираттан тыш тикшерү үткәрелә.

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе мәгълүматына ярашлы рәвештә, 2023 елның өченче кварталында минималь хезмәт хакы күләменнән түбән хезмәт хакын 639 оешма түләгән. Узган беренче квартал белән чагыштырганда мондый оешмалар саны 31,4 процентка (292) кимегән.

Үз чиратында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республиканың һәр муниципаль берәмлегендә эшләп килүче тормыш дәрәҗәсен күтәрү буенча ведомствоара территориаль комиссия эшен анализлау күрсәткәнчә, күпчелек очракта хезмәткәр тулысынча эшләп бетергән айда хезмәт хакын законда билгеләнгән күләмнән түбәнрәк түләү, тулы булмаган эш вакыты режимын куллану яки хезмәткәрне тулы булмаган ставкага кабул итү булып тора. Мондый оешмаларның минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк хезмәт хакы түләүчеләр арасында өлеше 73,6% тәшкил итә.

Шул ук вакытта 221 оешмада 560 хезмәткәрнең хезмәт хакы минималь хезмәт хакы турындагы законны бозып, минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк түләнә. Территориаль комиссияләр тәкъдимнәрен үтәп, 203 эш бирүче 476 хезмәткәрнең хезмәт хакын минималь хезмәт хакы дәрәҗәсенә кадәр җиткергән. 2023 елның 11 аенда өстәмә түләүләр суммасы 1549,1 тәшкил итте.

Шуңа бәйле рәвештә, эшчеләрнең хезмәт хокукларын торгызу яки киметүне булдырмау максатыннан, муниципаль районнарда яшәү дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча территориаль ведомствоара комиссияләргә даими нигездә хезмәт хакын минималь хезмәт хакыннан һәм минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк түләүче эш бирүчеләрне утырышларда тыңлау эшен дәвам итәргә, башкарылмаган очракта материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә кирәк, дип саныйбыз.

Күзәтчелек органнарының статистика мәгълүматлары 2023 елда прокурорлар тарафыннан ачыкланган иң характерлы хокук бозулар вакытында түләнмәгән һәм тулы булмаган хезмәт хакы булганлыгын күрсәтә. 2023 елның 11 аенда прокурорлар тарафыннан хезмәт хакы өлкәсендә 3 869 хокук бозу ачыкланган, 338 протест белдерелгән, 978 дәгъва җибәрелгән, 937 тәкъдим кертелгән, 732 вазыйфадагы зат дисциплинар җаваплылыкка тартылган, 213 вазыйфадагы зат административ җаваплылыкка тартылган, 22 кеше кисәтелгән, Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 37 маддәсе буенча 10 материал җибәрелгән, 11 җинаять эше кузгатылган.

Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматлары буенча, 2023 елда хезмәткәрләргә тоткарланган хезмәт хакы күләме узган елның 1 декабренә, ел башы белән чагыштырганда 26% ка кимегән. Шул ук вакытта бурыч суммасы 101 миллион сумга якын тәшкил иткән (01.12.2022 елга 140 млн сум тәшкил иткән).

2023 елның 11 аенда хисап даталарында (һәр айның беренче көне) бурычлы оешмаларның саны 34тән 74кә кадәр тәшкил иткән (шул ук мәгълүматлар буенча 2022 елда 61дән 45кә кадәр, 2021 елда 70тән 112гә кадәр, 2020 елда 81дән 159га кадәр). Шул ук вакытта, хезмәт хакы буенча бурычлары булган хезмәткәрләр саны һәм аның күләме 1 388 дән 2 976 га кадәр һәм 93,5 дән 161,7 млн сумга кадәр (2022 елда 1 977 дән 2 798 гә кадәр һәм 139,6 дан 266,8 млн сумга кадәр, 2021 елда 2 556 дан 4 613 гә кадәр һәм 218,9 млн сумнан 350,2 млн сум, 2020 елда 2 983-4 712 һәм 226,8 млн сумнан 305,0 млн сумга кадәр). Шулай итеп, 2023 елның аерым айларында бурычлар күләме буенча хәл узган ел белән чагыштырганда хәтта начарайган да. Шул ук вакытта суммасы һәм хезмәт хакын вакытында алмаган хезмәткәрләр саны буенча үткән елларга караганда кимүгә таба баруын билгеләми булмый.

Хисап елында Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләрдә гражданнар эштән азат ителүгә мәҗбүр ителүгә, хезмәт килешүен өзгәндә закон бозуларга зарланалар, медицина күрсәтмәләре булганда эштән азат итү, эштән читләштерү белән килешмәүләрен белдерәләр, шулай ук үз вазыйфаларына яңадан торгызуда ярдәм итүләрен сорыйлар.

Әлеге категориядәге мөрәҗәгатьләрне без прокуратура органнары һәм Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе белән тыгыз хезмәттәшлектә карадык.

Контроль-күзәтчелек органнарына мондый мөрәҗәгатьләрне тикшерү үтенече белән мөрәҗәгать итү белән беррәттән, Вәкаләтле вәкил хокук бозуларга юл куйган оешма җитәкчеләренә, хокук бозуларны оператив рәвештә бетерү максатыннан, шул исәптән мөрәҗәгать итү шартларын тикшерү юлы белән үз позициясен белдерде.

Хисап елында «Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе» берлеге, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзы (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан Республикасы оешмасы) Үзәк комитеты вәкилләре, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре белән берлектә, Вәкаләтле вәкилгә хезмәт хокуклары бозылу турында хәбәр иткән кешеләрнең шикаятьләрен урыннарга чыгып тикшерүләр уздырылды.

Әйтик, Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе вәкиле белән берлектә, гражданка К. мөрәҗәгате нигезендә АО проект институтына бару нәтиҗәләре буенча, 2023 елның октябрендә АО проект институты эшчәнлегендә хезмәт законнарын бозу мәсьәләсе буенча җәмгыять җитәкчесенә, конфликтлы ситуацияләрне кисәтү һәм хезмәт бәхәсләре килеп чыгуы нәтиҗәсендә, хезмәткәрнең эш урынын оештыру һәм гариза бирүчене яңадан укытуга (квалификация күтәрү курсларына) җибәрү буенча тәкъдимнәр җибәрелде.

Халыкның мәшгульлеге һәм үзвакытында һәм тулы хезмәт хакын түләүне тәэмин итү белән беррәттән, гражданнарның хезмәт хокукларының аерылгысыз элементы булып, куркынычсыз хезмәт шартларына хокукны тәэмин итү һәм хезмәт шартларына санитар-гигиена таләпләрен үтәү тора. Хезмәтне саклау өлкәсендәге хәлнең мөһим индикаторы булып, җитештерүдә булган бәхетсезлек очраклары саны тора.

2023 елда, әлеге мәсьәләнең социаль әһәмиятен исәпкә алып, төзелеш тармагында хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча эшче төркемгә керүче Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы оештырган ведомствоара эшче төркеменең өч утырышында катнашты.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2023 елда республикада 2022 елның шул ук чоры белән чагыштырганда производствода имгәнүләрнең кимү тенденциясе күзәтелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2019–2023 елларда җитештерүдә зыян күрүчеләр саны 14%ка кимегән.

Иң күп зыян күрүчеләр – йөк ташу һәм сак предприятиеләрендә теркәлгән (24 кеше, шул исәптән 10 үлем белән тәмамланган очрак); эшкәртү производстволарында (22 кеше, шул исәптән 5 үлем белән тәмамланган очрак); төзелештә (21 кеше, шул исәптән 4 үлем белән тәмамланган очрак); файдалы казылмалар чыгаруда (18 кеше); сәүдәдә – (5 кеше).

Травматизм үсеше 4 тапкыр шәхси сак хезмәте предприятиеләрендә (1дән 4 кешегә кадәр), 3 тапкыр элемтә предприятиеләрендә (0дән 3 кешегә кадәр), 2,3 тапкыр төзелеш предприятиеләрендә (9дан 21 кешегә кадәр) һәм файдалы казылмалар чыгару буенча (8дән 18 кешегә кадәр) теркәлә.

Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматлары буенча, җитештерүдә 131 төркемле бәхетсезлек очрагы, шулай ук Татарстан Республикасында теркәлгән предприятиеләрдә авыр һәм үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очрагы булган (2022 елда – 119), шулардан төркемле бәхетсезлек очраклары – 7 (2022 – 11), авыр нәтиҗә белән – 95 (89), үлем белән тәмамланганы – 29 (2022 – 19).

Әгерҗе, Азнакай, Арча, Чүпрәле, Алабуга, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Менделеевск, Минзәлә, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Тукай муниципаль районнарында травматизм дәрәҗәсе кимеде.

Травматизмның Әлмәт районында 2,2 тапкыр (9дан 20 бәхетсезлек очрагына кадәр), Буа муниципаль районында һәм Чаллы шәһәрендә 2 тапкыр артуы борчылу тудыра.

Республикада җитештерүдә үлемгә китергән бәхетсезлек очракларының кимүе административ йогынты чаралары яки чаралар күрү белән генә бәйле түгел, дип саныйбыз. Моңа 2023 елның 1 мартыннан гамәлгә кергән Россия Федерациясе Хезмәт кодексына кертелгән үзгәрешләр дә, шулай ук нигезендә хезмәткәрләр сәламәтлегенә зыян китерүләрне киметү, куркынычларны кисәтү яткан, хезмәтне саклау өлкәсендә яңа кагыйдәләрне тәртипкә салу өлешендә хезмәтне саклау өлкәсенә кагылган кайбер норматив һәм хокукый актлар да булышлык итте.

Шул ук вакытта эш урыннарында куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү максатыннан, урыннарда хезмәтне саклау буенча координацион советларга, һәр очракны, адреслы чаралар күреп, эш бирүчеләр катнашында предметлы карарга кирәк.

Үз чиратында, Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыкларына Татарстан Республикасы төзелеш мәйданчыкларында хезмәтне саклау нормаларын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә һәм төзелеш мәйданчыкларында производство имгәнүләрен контрольдә тотуны һәм профилактикалауны арттыру буенча тиешле чаралар үткәрүне оештырырга.

3.2. СОЦИАЛЬ ТӘЭМИН ИТҮГӘ ХОКУК

Татарстан Республикасында социаль сәясәтнең төп бурычы – җәмгыятьнең социаль иминлеген тәэмин итү һәм барлык категория гражданнарның социаль мөмкинлекләре тигезлеген тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

Россия Федерациясе Конституциясенең 7 нче маддәсендә Россия социаль дәүләт дип игълан ителә, аның сәясәте кешенең лаеклы тормышын һәм ирекле үсешен тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлдерелгән. Дәүләт тарафыннан кешеләрнең хезмәте һәм сәламәтлеге саклана, минималь хезмәт хакының гарантияләнгән күләме билгеләнә, гаилә, ана, ата һәм балаларны, инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнарны яклау тәэмин ителә, социаль хезмәтләр системасы үсеш ала, дәүләт пенсияләре, пособиеләр һәм социаль яклауның башка гарантияләре билгеләнә.

2023 елда әлеге өлкәдә кеше хокуклары гарантияләрен арттыру буенча законлы чаралар күрелде. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләрендә төп өстенлек – балалы

гаиләләргә, авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга адреслы ярдәм күрсәтү булып кала.

Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 2 маенда дөнья күргән Пр-753 нче йөкләмәләре исемлегенең 1 пунктындагы «в» өлешен үтәү кысаларында, мондый гаиләләрнең ярлылык куркынычын киметү максатыннан балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларының бербөтен системасын булдыру буенча 2023 елның 1 гыйнварыннан балага 17 яшькә кадәр ай саен түләүне билгеләүгә һәм гамәлгә ашыруга бердәм алым кертелде. Тиешле үзгәрешләр «Балалары булган гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 19.05.1995 елгы 81-ФЗ федераль законга кертелде, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 16.12.2022 елгы 2330 нчы карары белән бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособие билгеләү һәм түләү тәртибе эшләнде һәм расланды. Бу түләү 7 гамәлдәге ярдәм чарасын берләштерә, яклауга мохтаҗ гаиләләргә бала туганнан алып аның 17 яше тулганчыга кадәр бердәм шартларда бюджеттан ярдәм алырга мөмкинлек бирә.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең 2023 елның 1 декабренә булган мәгълүматлары буенча, бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособиене Татарстан Республикасында 107 426 кеше, шул исәптән 199 711 бала ала.

2023 елның 1 февраленнән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 30.01.2023 елгы 119 нчы карары нигезендә 2022 елда чын инфляция дәрәҗәсе буенча инвалидларга, ветераннарга, балалы гаиләләргә һәм башка категория гражданнарга айлык акчалата түләүләр 1,119га индексацияләнде.

2023 елда социаль хезмәтләр күләме 1 469, 74 сум тәшкил итте, шул исәптән:

– медицина ярдәме стандартлары нигезендә дару препаратларына рецептлар буенча медицина кулланылышы өчен кирәкле дару препаратлары, медицина эшләнмәләренә рецептлар буенча медицина эшләнмәләре, шулай ук инвалид балалар өчен махсус дәвалау азыгы продуктлары белән тәэмин итү – 1132,03 сум;

– медицина күрсәтмәләре булганда, төп авыруларны профилактикалау максатларында башкарыла торган шифаханә-курорт дәвалануына, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән шифаханә-курорт оешмаларына юллама бирү – 175,12 сум;

– шәһәр яны тимер юл транспортында, шулай ук шәһәр ара транспортында дәвалану урынына бушлай бару-кайту – 162,59 сум.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2023 елда социаль ярдәм чараларын алучылар саны 1,001 миллион кеше тәшкил иткән, шуларның 694 866сы – төбәк социаль түләүләрен алучылар.

Проблемалы урыннарны ачыклау һәм гражданнар белән актив хезмәттәшлек итү максатларында, Вәкаләтле вәкил тарафыннан бала карау буенча ялда булган хатын-кызларда барлыкка килә торган актуаль мәсьәләләргә, инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр, өлкән яшьтәге кешеләр хокукларын үтәү мәсьәләләренә багышланган тематик телефон «кайнар элемтәләре» системалы рәвештә үткәрелә, алар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы вәкилләрен җәлеп итеп үткәрелә.

2023 елда пенсия белән тәэмин итү һәм халыкны социаль яклау мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкилгә гражданнардан 506 мөрәҗәгать килгән. Мөрәҗәгатьләр инвалидлыкны билгеләү, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләрне оештыру, техник реабилитация чаралары алу, сәламәтлеге чикле кешеләргә тоткарлыксыз мохит тудыру, пенсияләрне кабат исәпләү, пенсиягә вакытыннан алда чыгу мәсьәләләренә кагылды.

Вәкаләтле вәкилнең аерым игътибары, традицион рәвештә, эшкә сәләтсез гражданнарны, аерым алганда, инвалид балаларны караучыларга компенсация түләү мәсьәләләренә бирелә.

Дәүләт тарафыннан социаль ярдәм әлеге категория гражданнарның тормышын күпкә җиңеләйтә, авыр хәлдәге инвалид балалары булган гаиләләргә шәхси һәм гаилә үсешенә ярдәм итәргә һәм гаиләнең барлык әгъзаларының хокукларын якларга ярдәм итә.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе булышлыгы белән 2022 елның июнендә Вәкаләтле вәкилгә Казан шәһәрендә яшәүче гражданка О. мөрәҗәгате килде, чөнки вәкаләтле орган аңа 18 яшькә кадәрге инвалид баланы (балачактан I төркем инвалид) караучы эшкә яраксыз зат буларак айлык түләүне билгеләүдән баш тарткан, сәбәбе – мөрәҗәгать итүченең эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турында мәгълүмат булу.

Бу документларны тикшергәч, мөрәҗәгать итүчегә айлык түләү билгеләү өчен кирәкле шартларның берсе – эшләмәве раслануы ачыкланды. Салым органы мәгълүматына караганда, мөрәҗәгать итүче 2021 елда ук шәхси эшмәкәр буларак исәптән төшерелгән.

Хәлне төзәтү максатыннан, без Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе адресына Вәкаләтле вәкилнең позициясен бәян итеп, мөрәҗәгать юлладык, мөрәҗәгать итүчене шәхси эшмәкәр буларак исәптән төшерү һәм хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырмау фактын ассызыкладык.

Нәтиҗәдә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге җитәкчелеге карары белән мөрәҗәгать итүчегә ай саен түләү билгеләнде.

Социаль һәм матди яктан иң зәгыйфь категория буларак инвалидлар хокукларын яклауга аерым игътибар бирәбез. Инвалидларның ярдәм күрсәтү яки хокукларын торгызу турындагы һәр үтенече буенча тулы чаралар күрелә.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең 2023 елның 1 декабренә булган мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасында тулы социаль хезмәт күрсәтүләргә хокуклы инвалидлар һәм инвалид балалар саны 95 468 кеше тәшкил итә, шуларның 39 635 – 3 төркем инвалидлар, 30 365 – 2 төркем инвалидлар, 13 923 – 1 төркем инвалидлар, 11 545 – инвалид балалар.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге мәгълүматларына караганда, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин итү буенча 23 898 хезмәт алучы исәптә тора, шул исәптән 3 339 – инвалид балалар.

2023 елда 51 550 гариза буенча 16 199 инвалид 824 728 895,7 сумлык 4 461 221 әйбер күләмендә техник реабилитация чаралары белән тәэмин ителгән. Хисап елында Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә 7 724 182 данә техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү өчен 75 806 гариза белән 18 379 инвалид мөрәҗәгать иткән. 373 795 043, 28 сумлык 3 654 809 әйбер белән 35 887 гариза буенча 12 384 инвалид тәэмин ителгән.

Техник реабилитация чаралары һәм протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин итү өчен, 18 декабрьгә булган мәгълүматларга караганда, коляскалар, таяну таяклары, аяк протезлары, ишетү аппаратлары, йөрү таяклары, башка эшләнмәләр белән тәэмин итү өчен 1 110,7 миллион сумлык 126 дәүләт контракты төзелгән.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан инвалидларны техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү өлкәсендә кабул ителгән чараларга карамастан, мохтаҗ затларны шәхси реабилитация программалары нигезендә техник реабилитация чаралары белән тиешенчә (вакытында) тәэмин итмәү мәсьәләләре элеккечә актуаль булып кала.

Шул ук вакытта инвалидларның аерым категорияләренең тормыш сыйфаты һәм сәламәтлек торышы тулысынча диярлек техник реабилитация чаралары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле, шуңа бәйле рәвештә аларны тәэмин итү вакыты аерым әһәмияткә ия.

Инвалидларны техник реабилитация чаралары белән вакытында тәэмин итмәү мәсьәләләре буенча хисап елында Вәкаләтле вәкилгә 27 мөрәҗәгать килде.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге белән хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре үз чишелешен таба.

Шул ук вакытта безнең тарафтан Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил адресына килә торган мәгълүматка анализ ясалуы күрсәткәнчә, инвалидларга техник реабилитация чаралары бирү срокларын үтәмәү, контрактның башлангыч максималь бәясен формалаштыру өчен җитәрлек күләмдә коммерция тәкъдимнәре булмаганлыктан кирәкле сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен ачык сатулар үткәрү срокларын озайту сәбәпле килеп чыга.

Шуңа бәйле рәвештә инвалидларга техник реабилитация чаралары бирү срокларын үтәү максатыннан, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә, реабилитация чаралары китерүгә дәүләт контрактлары төзү эшен оештыруны камилләштерергә һәм техник реабилитация чаралары өчен кирәкле сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен ачык аукционнарны вакытында үткәрергә киңәш итәбез.

2023 ел дәвамында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына медицина-социаль экспертиза учреждениеләре эшенә турыдан-туры шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр. Аерым алганда, гражданнар медицина-социаль экспертиза органнарының инвалидлык билгеләүдән баш тарту яки инвалидлык төркемен үзгәртү турындагы карарлары белән килешмәүләрен белдерде.

2023 елда тикшерү вакытында баланың авыру үзенчәлекләренә бәйле ихтыяҗлары исәпкә алынмаган очракка игътибар бирдек. Шуңа күрә табибларның медицина-социаль экспертиза буенча эксперт составы реабилитация һәм абилитациянең яңа индивидуаль программасын эшләгәндә реабилитация чаралары исемлегенә кирәкле реабилитация чарасын кертмәгән.

Мәсәлән, 2023 елның май аенда Казан шәһәрендә яшәүче гражданка М. үзенең балигъ булмаган баласы мәнфәгатьләрендә, инвалидлар өчен функциональ-эстетик кием комплектын, баласының көндәлек тормышын җиңеләйтү максатыннан индивидуаль реабилитация һәм абилитация программасына кертүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте.

Әлеге мөрәҗәгать буенча барлык дәлилләрне өйрәнеп, Вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертиза Баш бюросы» ФКУ җитәкчесенә мөрәҗәгать итеп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар республика клиник хастаханәсенең табиб-неврологы-реабилитологы тарафыннан балага техник реабилитация чаралары билгеләү буенча куелган тәкъдимнәргә, шулай ук медицина оешмасының медицина реабилитациясе яки абилитация чаралары буенча медицина-социаль экспертизасы юлламасында, кирәкле буларак, инвалидлар өчен функциональ-эстетик кием комплекты да кертелүенә игътибар итүне сорап мөрәҗәгать итте.

Безнең булышлык белән мөрәҗәгать бирүченең баласына инвалидларны реабилитацияләү һәм абилитацияләүнең яңа индивидуаль программасы эшләнде, ул инвалидлар өчен функциональ-эстетик кием комплектын да күздә тота.

Инвалид дип танылган затларның хокукларын тормышка ашыру максатыннан, «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертиза Баш бюросы» учреждениесе Россия Хезмәт министрлыгының 26.06.2023 елгы 545н боерыгы белән расланган медицина-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан бирелә торган, инвалид баланы тернәкләндерү һәм абилитацияләү, инвалидны тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең индивидуаль программаларын, индивидуаль тернәкләндерү программасын яки тернәкләндерүнең индивидуаль программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә аларны индивидуаль эшләүне тәэмин итәргә тиеш, дип саныйбыз.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил инвалидларның уңайлы мохиткә хокукларын бозуга бәйле аерым шикаятьләр буенча чаралар күрде.

Мәсәлән, 2023 елның сентябрендә Казанда яшәүче гражданка Л., әлеге учреждениедә уңайлы мохит оештырылмау сәбәпле, Яшел Үзән шәһәрендә урнашкан «Дельфин» шифаханәсе эшчәнлегенә шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шифаханә-курорт дәвалануына юллама аның әтисенә, 2 төркем инвалидка, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан бирелгән.

Күрсәтелгән санаторийга барып, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре:

– шифаханә бинасына керү юлында пандуслар булмавын;

– инвалид коляскасында йөрүче гражданнарның учреждениенең барлык бүлекчәләренә, номерларына, җиһазландырылган санузелларга керүен тәэмин итүче киңәйтелгән ишек уемнары булмавын;

– махсус култыкчалар булмавын ачыклады.

Моннан тыш, бер дәрәҗәдәге коридорлар баскычлар белән тоташтырылган, шунлыктан инвалидның бу араны үтү мөмкинлеге булмаган. Моннан тыш, функциональ бүлмәләр ишекләренең ишек төбе бар, ә лифт юк.

Бу уңайдан Вәкаләтле вәкил санаторий-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешманы оештыручы адресына әлеге санаторийда инвалидларга һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә тоткарлыксыз керү һәм хәрәкәт итү өчен тоткарлыксыз мохит шартлары булдыру буенча чаралар күрү турында, шулай ук Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә санатор дәвалау юлламалары биргәндә физик үзенчәлекләрне, шулай ук санаторийларда аларның хәрәкәтләнүе өчен булдырылган шартларны исәпкә алу турында тәкъдимнәр җибәрде.

Әлеге мәсьәләләрнең мөһимлеген билгеләп, Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан «Интернет» челтәрендә дәвалану һәм ял итү оешмалары тарафыннан халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына карата гражданнарның бәяләмәләре мониторингы үткәрелде.

Бәяләмәләрне анализлау нәтиҗәләре буенча, шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларның эшчәнлеге белән танышу, тоткарлыксыз мохит өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, 2022 елның октябрендә профильле ведомство вәкилләре һәм «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан оешмасы белән берлектә шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче кайбер оешмаларга, шул исәптән: Чаллы шәһәренең «Радуга шифаханәсе» ЯАҖ, «Чаллы» клиника-шифаханәсе ҖЧҖ, «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ, Чаллы шәһәренең «Саулык» сәламәтләндерү комплексы, Казан шәһәре «КМПО шифаханә-профилакторие» ҖЧҖ барулар оештырылды, алар белән Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге 2023 елда гражданнарның ташламалы категориясен шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар белән тәэмин итү буенча дәүләт контрактлары төзегән иде.

Әлеге оешмалар белән танышу барышында ишетү һәм күрү сәләте бозылган, терәк-хәрәкәт аппараты чикләнгән һәм таяк белән хәрәкәт итүче затлар өчен уңайлы мохит өлешчә оештырылуы һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 30.12.2020 елгы 904/пр боерыгы белән расланган «СП 59.13330.2020. Кагыйдәләр җыентыгындагы һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен биналар һәм корылмалар булу мөмкинлеген күздә тоткан СНиП 35-01-2001 кагыйдәләре»нә туры килмәве ачыкланды.

Үз чиратында, санаторийларда санаторий-курорт хезмәтләре, яшәү, медицина һәм башка хезмәтләр күрсәткәндә инвалидларның ихтыяҗларын санга сукмау «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ федераль закон нигезләмәләрен бозуга китерә, әлеге законга ярашлы рәвештә оешмалар, аларның нинди оештыру-хокукый формада булуына карамастан, инвалидларга (шул исәптән коляскалар һәм юл күрсәтүче этләр кулланган инвалидларга) тоткарлыксыз керү өчен шартлар тудырырга тиеш.

Урынга чыгып тикшерүләр барышында ачыкланган хокук бозулар нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмалар: Чаллы шәһәренең «Радуга шифаханәсе» ЯАҖ, «Чаллы» клиника-шифаханәсе ҖЧҖ, Чаллы шәһәр округының «Саулык» сәламәтләндерү комплексы, «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ һәм Казан шәһәренең «КМПО санаторий-профилакторие» оешмалары адресына әлеге оешмаларда гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп, тоткарлыксыз мохитне гамәлгә ашыруда ярдәм итүне сорап, кимчелекләрне күрсәтеп хатлар җибәрде.

Шул ук вакытта, гражданнарның ташламалы категорияләренә шифаханә-курорт дәвалануына юлламаларны тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан 2023 елда гражданнарны шифаханә-курорт дәвалау буенча хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасында шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмалар белән төзелгән дәүләт контрактлары нигезендә күрсәтелә, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешма җитәкчеләрен дәүләт контрактлары нигезләмәләрендә каралган җаваплылыкка тарту мәсьәләсен карарга тәкъдим ителде.

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге мәгълүматларына караганда, Вәкаләтле вәкилнең тәкъдимнәре исәпкә алынган, контрактлар шартларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) җаваплы затларны җаваплылыкка тарту буенча эш оештырылган.

Республика территориясендә гражданнарга шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга барып танышу нәтиҗәләре, шулай ук 2023 елның декабрендә Россия Федерациясе Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегендә производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарның ташламалы категорияләрен шифаханә-курорт дәвалау белән тәэмин итү һәм зыян күрүчеләрне реабилитацияләү мәсьәләләре буенча «түгәрәк өстәл» утырышында фикер алышу предметы булды.

Шуңа бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә гражданнарның аерым ташламалы категорияләренә шифаханә-курорт дәвалануын күрсәтү буенча дәүләт контрактлары төзегәндә, һәр очракта, гамәлдәге закон нигезендә, терәк-хәрәкәт аппаратында чикләүләр булган һәм таяк белән йөргән күрмәүче һәм ишетмәүче кешеләр өчен шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларны тоткарлыксыз мохит дәрәҗәсе буенча тикшерергә кирәк, дип саныйбыз.

Үз чиратында, шифаханәләрдә санаторий-курорт хезмәтләре, яшәү, медицина һәм башка хезмәтләр күрсәтүче оешмалар җитәкчеләренә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 30.12.2020 елгы 904/пр боерыгы белән расланган «СП 59.13330.2020. Кагыйдәләр җыентыгындагы һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен биналар һәм корылмалар булу мөмкинлеген күздә тоткан СНиП 35-01-2001 кагыйдәләре»н истә тотып, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24.11.1995 елгы 181-ФЗ федераль закон нигезләмәләренең таләпләрен тәэмин итәргә кирәк.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясенә, үз эшчәнлеген оештырган вакытта халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен шифаханә-курорт өлкәсе объектларында тоткарлыксыз мохит тудыру мәсьәләләренә игътибар итәргә тәкъдим итәбез.

Инвалидларның уңайлы мохиткә хокукларын бозуга бәйле гражданнарның проблемаларын хәл итүдә «Халык контроле»Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтә.

2023 елда «Уңайлы мохит» категориясендә 258 мөрәҗәгать басылып чыкты, шуларның 164е хәл ителгән инде. Иң күп хәбәрнамәләр: Казан шәһәре буенча – 186, Чаллы шәһәре буенча – 32, Бөгелмә районы буенча – 14, Әлмәт һәм Түбән Кама районнары буенча – 5әр.

Бу юнәлештә күпчелек очракта республика муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларының уңай эше билгеләнә.

Мондый мисалларның берсе буларак, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының Дуслык урамындагы күпфатирлы йорт подъездында Вәкаләтле вәкилнең пандус урнаштыру турындагы тәкъдимен оператив тәртиптә башкарган эшен билгеләп үтәргә кирәк, шуның нәтиҗәсендә бу йортта яшәүче, коляскада хәрәкәт итүче инвалидның урамга чит кеше ярдәменнән башка чыгу мөмкинлеге барлыкка килде.

Икенче мисал булып 2023 елның июнендә Казан шәһәренең Альберт Камалеев проспектындагы «Ат спорты комплексы» җәмәгать транспорты тукталышы һәм «Зәңгәр күкләр» торак комплексы янында күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен тактиль җир өстендәге күрсәткечләр булмау турында Д.ның мөрәҗәгате хезмәт итә.

«СП 59.13330.2020. Кагыйдәләр җыентыгы. Халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен биналар һәм корылмалар булу мөмкинлеге. СНиП 35-01-2001» төзелеш нормалары һәм кагыйдәләренең 5.1.10 пунктына ярашлы рәвештә, күрү сәләте бозылган инвалидлар өчен аларның югары куркыныч зоналарга (аерым торган баганаларга, терәкләргә һәм башка киртәләргә, баскычларга, җәяүлеләр сукмакларына һ.б.) якынлашуы турындагы мәгълүматны тактиль-контрастлы җир өсте күрсәткечләре урнаштыру яки шундый характеристикалы җәяүлеләр юлы өслегенең фактурасын үзгәртү белән тәэмин итәргә кирәк.

Әмма Казан шәһәренең Альберт Камалеев проспектындагы «Ат спорты комплексы» җәмәгать транспорты тукталыш пункты һәм «Зәңгәр күкләр» торак комплексы янындагы тротуарларны һәм тукталыш павильоннарын төзекләндерү буенча төзелеш эшләре әлеге нормаларны исәпкә алмыйча башкарылды.

Безнең инициатива буенча Казан шәһәре Совет районы прокуратурасы тарафыннан тикшерү үткәрелде, нәтиҗәдә Совет районы хакимият башлыгы адресына ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр кертелде.

Күрү сәләте бозылган кешеләр өчен тактиль плитәләр урнаштыру мәсьәләсе шулай ук 2022 елның ноябрендә безнең адреска гражданин А. мөрәҗәгать итү өчен сәбәп булды, ул Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте җаваплы башкаручыларының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына 2021 елның июнендә бастырылган үз мөрәҗәгатенә җаваплары белән килешмәвен белдерде.

Җирле үзидарә органнарының җаваплы башкаручылары комментарийларыннан күренгәнчә, мөрәҗәгать итүченең хәбәрнамәләренә финанслау булмауга сылтама белән «дәлилле кире кагу» статусы бирелгән.

Бу мөрәҗәгатьләр 2 елдан артык хәл ителмәгән.

Җирле үзидарә органнарының уңай мохитне тәэмин итү буенча озак вакыт чаралар күрмәве сәбәпле, Казан шәһәре прокуратурасы тикшерүе дәгъваларның нигезле булуын раслады һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте башлыгы адресына, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр кертте.

Тагын бер мисал – 2023 елның апрелендә Чаллы шәһәрендә яшәүче гражданка А.ның 1 төркем инвалид мәнфәгатьләрен кайгыртып күпфатирлы йорт подъездында пандус урнаштыру кирәклеген хәбәр иткән мөрәҗәгате. Мөрәҗәгать итүгә тәкъдим ителгән материаллардан күренгәнчә, муниципаль комиссия тарафыннан инвалид яшәгән йорттагы күпфатирлы йортта инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып, торакны һәм гомуми милекне инвалид өчен өлешчә яраклаштыру турында карар чыгарылган.

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 09.07.2016 елгы 649 нчы карары белән расланган күпфатирлы йортта инвалидлар өчен торак урыннар һәм гомуми милек шартларын тәэмин итү кагыйдәләренең 18 пункты нигезендә, комиссия эшенең нәтиҗәсе булып, инвалид яшәгән күпфатирлы йортта аның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне җайлаштыру мөмкинлеге булу-булмау турындагы карар тора. Тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан инвалид яшәгән күпфатирлы йортта инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне җайлаштыруның өлешчә мөмкинлеге турында нәтиҗә чыгару һәм аларның инвалид өчен уңайлылык шартларын тәэмин итү кагыйдәләрдә каралмаган.

Күпфатирлы йортта инвалидны гомуми милек шартлары белән тәэмин итү һәм кагыйдәләр таләпләрендәге кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрү максатыннан, күпфатирлы йорт подъездында инвалид коляскасын менгезү һәм төшерү өчен техник ярдәмче җайланма урнашыру мөмкинлеген карауны сорап, Чаллы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенә мөрәҗәгать иттек.

Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тәкъдим иткән мәгълүматка караганда, 1 төркем инвалид яшәгән күпфатирлы йорт подъездында пандус урнаштырылган.

Өлкән яшьтәге кешеләргә социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре дә әһәмиятен югалтмый. Социаль һәм психологик яктан якланмау, ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның зәгыйфьлеге аларга үз проблемаларын үзләре хәл итәргә мөмкинлек бирми, алар еш кына проблема алдында берүзләре кала.

Күтәрелгән теманың актуальлеге 2023 елда «ГЛОНАСС-112» ЕГИС аша килгән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү кирәклеге турында битараф булмаган гражданнар хәбәрләре белән раслана. Мондый хәбәрләрне күзәтү күрсәткәнчә, ярдәмгә һәм социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ өлкән яшьтәге кешеләр еш кына төрле психик тайпылышлардан интегә.

Мондый хәбәрләрнең иң күбе Казан һәм Чаллы шәһәрләреннән, Түбән Кама һәм Бөгелмә муниципаль районнарыннан килде.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 2023 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең 09.02.2023 елгы 82/182 нче уртак боерыгын үтәү максатыннан, республикада өлкән яшьтәге гражданнарны ярдәмсез калдыру һәм тиешле кайгыртусыз калдыру фактларын профилактикалау максатларында, ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар йорт, фатирларында булу оештырылды.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2023 елның 11 аенда Татарстан Республикасында халыкның уртача гомер озынлыгы 75,38 ел тәшкил иткәнен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына гражданнарның яшь цензын иртәрәк яшькә төшерү мөмкинлеген карарга, ә йорт (фатир) буйлап йөргәндә өлкән яшьтәге гражданнарның сәламәтлек торышына, шулай ук аларның яшьләренә кагылышлы психик тайпылышларына игътибар итәргә тәкъдим итәбез.

Үз чиратында, социаль яклау һәм социаль тәэмин итү линиясе буенча район халкын тәэмин итү органнарының эшчәнлеген оештырганда башкарма комитетлар җитәкчеләренең социаль мәсьәләләргә кураторлык итүче урынбасарларына, йорт, фатирлар буйлап йөргәндә йорт хуҗалыклары составында теркәлгән башка затлары булмаган, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарны тикшерү нәтиҗәләренә аерым игътибар бирергә, ихтыяҗ бар икән, яклауга мохтаҗ гражданнарны адреслы яклау чарасы кабул итәргә кирәк.

3.3. СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУГА ҺӘМ МЕДИЦИНА ЯРДӘМЕНӘ ХОКУК

Сәламәтлек саклау – халыкка медицина ярдәме күрсәтүгә һәм аңа ярдәм итүгә, шулай ук авыруларны профилактикалау һәм җәмәгать сәламәтлеген яхшырту буенча чаралар үткәрүгә юнәлдерелгән дәүләт эшчәнлегенең аерым өлкәсе.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау үсешенең стратегик юнәлешләре арасында халыкка амбулатор ярдәм күрсәтүне камилләштерү, квалификацияле медицина ярдәмен алу мөмкинлеген арттыру аерым урын алып тора. 2023 елда «Сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасында 145 сәламәтлек саклау объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау буенча эшләр башкарылды, шуларның 28се төзелде, 117се капиталь ремонтланды.

«Перинаталь үзәге булган Түбән Кама балалар хастаханәсе» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесендә сәламәтлек саклау объектларының берсен – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен стоматология кабинетын ачу тантанасында Вәкаләтле вәкилнең Түбән Кама муниципаль районындагы җәмәгатьчелек ярдәмчесе катнашты. Әлеге стоматология кабинетының эшләве җәмәгатьчелек ярдәмчесенең «Татнефть» ААҖ генераль директорына кирәкле җиһазлар һәм аппаратура сатып алуга акча бүлеп бирү мөмкинлеген карау үтенече белән мөрәҗәгать итүе нәтиҗәсендә мөмкин булды. Бу республикада мәҗбүри медицина иминияте программасы кысаларында дәваланырга мөмкин булган икенче кабинет.

Һичшиксез, сәламәтлек саклауның беренчел звеносы – сәламәтлек саклау системасында иң зур звено, поликлиникаларга, амбулаторияләргә, фельдшер-акушерлык пунктларына мөрәҗәгать итү – гражданнарда медицина хезмәтенең иң кирәкле өлеше, нәкъ менә ул бөтен сәламәтлек саклауның «йөзе» булып тора.

Россия Президенты В.В. Путин 2023 елның 21 февралендә Федераль Җыенга Юлламасында «сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү программасының нәтиҗәлелегенең аеруча мөһимлегенә һәм аның төп критериена» игътибар итте.

Гражданнарга сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруда, яклауда һәм торгызуда ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Федераль сәламәтлек саклау хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, шулай ук турыдан-туры медицина оешмалары белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла торган, Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең мөһим юнәлешләренең берсе булып тора.

Гражданнарның сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын үтәүне тәэмин итү буенча хокук яклау практикасы гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караганда, «Сәламәтлек саклау» юнәлеше буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрне модерацияләү, шулай ук «Инцидент Менеджмент» системасы аша социаль челтәрләрне реаль вакыт режимында мониторинглау аша көндәлек режимда гамәлгә ашырылды.

2023 елда сәламәтлек саклау һәм медицина мәсьәләләре буенча «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре (функцияләре) бердәм порталының кире элемтә платформасы аша 60 167 хәбәр килгән, шуларның 42 953е сәламәтлек саклау өлкәсендәге мәсьәләләр буенча хәбәрләр, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 72 процентын тәшкил итә, «Халык контроле» мәгълүмат системасына – 3774, «Инцидент Менеджмент» системасына 3 447 хәбәр килгән.

Медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә килгән мәгълүматны анализлау шуны күрсәтә: медицина ярдәменең югары дәрәҗәдә булуын һәм сыйфатын тәэмин итү буенча күрелгән чараларга карамастан, гражданнарның сыйфатлы медицина ярдәменә хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр актуальлеген югалтмый.

Кызганычка, узган елгы докладларда күтәрелгән проблемалы мәсьәләләр 2023 елда да актуаль булып калды. Бу – медицина белгечләре җитмәү, дарулар белән тәэмин итү өзеклекләре, чиратлар һәм медицина учреждениеләрендә пациентларны кабул итүне тиешенчә оештырмау. Гомумән, болар гражданнарның Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итү мәсьәләләре исемлеге башында тора.

2023 елда Вәкаләтле вәкил адресына күрсәтелгән мөнәсәбәтләр өлкәсендә 184 мөрәҗәгать килгән.

Узган елда Вәкаләтле вәкил республиканың муниципаль берәмлекләрендә бала тудыру бүлекләрен ябуга аерым игътибар бирде.

2023 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкил адресына гражданка К.дан «Лаеш үзәк район хастаханәсе»се бала тудыру бүлеген ябу турында мөрәҗәгать килде.

Мөрәҗәгатьне карау кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать юлланды. Безнең хатка җавап итеп, ана һәм сабыйлар үлемен профилактикалау һәм киметү максатыннан акушерлык урыннарын үзгәртеп кору үткәрелә, елына 100дән азрак бала туган тудыру бүлеге кыскартыла, дигән хат килде.

Шул ук вакытта Лаеш муниципаль районы халык саны арту буенча лидерларның берсе булып тора. Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы рәсми сайтыннан алынган мәгълүматларга караганда, узган ел башына Лаеш муниципаль районында халык саны 67 057 кеше тәшкил иткән, бу 2022 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 6%ка күбрәк. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, Лаеш муниципаль районы (республиканың бала тудыру бүлекләре ябылган башка районнары арасында), бала тудыручылар саны арту буенча бердәнбер район булып тора. 2023 елның 9 аенда бала тудыру бүлегендә 98 бала туган, бу 2022 ел белән чагыштырганда 69%ка күбрәк.

Кызганычка, бу мөрәҗәгатьләр бер генә түгел. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2023 елда 9 бала тудыру йорты (бүлеге) ябылган: болар – «Биектау район хастаханәсе»ндә, «Теләче район хастаханәсе»ндә, «Аксубай район хастаханәсе»ндә, «Әтнә район хастаханәсе»ндә, Әлки районының «Базарлы Матак район хастаханәсе»ндә, «Балтач район хастаханәсе»ндә, Чүпрәле, Тәтеш, Лаеш хастаханәләрендә.

Республиканың аерым районнарында бала тудыру бүлеге ябылу сәбәпле, хәзерге вакытта хатын-кызлар йөклелек чорында, күрсәтелгән муниципаль районнардан йөклелек, бала табу һәм бала табудан соңгы чорда хатын-кызларга медицина ярдәме күрсәтүне маршрутлаштыру схемасына ярашлы рәвештә муниципальара үзәкләргә бала табуга җибәрелә.

Шул ук вакытта бала тудыру урынының яшәү урыныннан ерак булуы әлеге муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләрдә нигезле борчылу тудыра.

Үз чиратында, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасының теге яки бу муниципаль районында бала тудыру йортларын (бүлекләрен) ябу турында карар кабул иткәндә әлеге муниципаль район халкының фикерен, халык саны арту динамикасын, шул исәптән муниципаль берәмлекләрдә туучылар санының тотрыклы һәм сизелерлек арту нәтиҗәсен исәпкә алырга кирәк, дип саный.

Гражданнарның медицина ярдәменә хокукларын яклау өлкәсендә тагын бер актуаль проблема – медицина ярдәменә ия булу һәм табибларга язылу уңайлылыгы мәсьәләләре. Һичшиксез, табибларга язылу халык өчен сыйфатлы медицина ярдәме белән тәэмин итүдә төп роль уйный.

2023 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Табибка язылу мөмкинлеге» категориясе буенча мөрәҗәгатьләр 2022 ел белән чагыштырганда 3,2 тапкыр арткан. Әлеге категория буенча гражданнардан 2024 хәбәр килгән (2022 елда – 635).

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы буларак Вәкаләтле вәкилгә халыкның кабул итүне озак көтү турындагы мәгълүматка бәйле хәбәрләр аерым контрольгә алынды. Гражданнарның мәгълүмат системасына кергән шикаятьне тиешенчә карамау турындагы дәгъвалары нигезләнгән очракта, шикаятьне эшкә кире кайтару һәм кирәкле гамәлләр башкару буенча җаваплы башкаручыларга киңәшләр бирү рәвешендә җавап чаралары күрелә.

Әйтик, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына 2023 елның ноябрендә Казан шәһәрендә яшәүче гражданка Д.дан «20 нче шәһәр поликлиникасы»нда табибка язылу мөмкин булмавы турында хәбәр килде. Мөрәҗәгать итүченә аның шикаяте 2023 елның 28 ноябрендә медицина оешмасына карауга тапшырылуы турында хәбәр ителде. Нәтиҗәдә мөрәҗәгать итүченә табибка кабул итүгә язылу турында хәбәр ителә. Әмма билгеләнгән вакытта поликлиникага килгәч, аңа кабул итүгә язылмаганлыгы турында хәбәр итәләр. Әлеге мәгълүмат Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры адресына җибәрелде. Вәкаләтле вәкил катнашыннан соң гражданка Д. профильле белгечкә кабул итүгә язылды.

Табибларга кабул итү өчен язылу мөмкинлеге булмавының тагын бер мисалы булып, 2023 елның ноябрендә гражданка А.дан килгән, аның балигъ булмаган баласын «Перинаталь үзәге булган Әлмәт шәһәр балалар хастаханәсе»нә диспансерлаштыру өчен яздыру мөмкинлеге булмавы турындагы мөрәҗәгать хезмәт итә. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча республика Сәламәтлек саклау министрлыгының җаваплы башкаручысы шикаять бирүчегә поликлиникадан шалтыратуны көтү турында җавап җибәргән. Әмма медицина учреждениесеннән шалтыратмаганнар. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры адресына мәгълүмат җибәрелде. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мөрәҗәгатьне карагач, мөрәҗәгать итүченең баласы профильле белгечләргә язылды.

Кызганычка, мондый хәбәрләр сирәк түгел. Табибларга кабул итүгә язылып булмау мәсьәләсе буенча гражданнардан иң күп хәбәрләр: Казан шәһәре буенча – 407 («7 нче шәһәр клиник хастаханәсе», «8 нче шәһәр поликлиникасы», «18 нче шәһәр поликлиникасы», «20 нче шәһәр поликлиникасы», «21 нче шәһәр поликлиникасы»), Чаллы шәһәре буенча – 202 («Л.Н.Ганиева исемендәге 4 нче поликлиника», «6 нчы шәһәр поликлиникасы», «5 нче шәһәр хастаханәсе»), Түбән Кама муниципаль районы буенча – 182 («Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе», «Перинаталь үзәге булган Түбән Кама балалар хастаханәсе»), Әлмәт муниципаль районы буенча – 60 («Әлмәт үзәк район хастаханәсе», «Перинаталь үзәге булган Әлмәт шәһәр балалар хастаханәсе»), Яшел Үзән муниципаль районы буенча – 33 («Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе»), Питрәч муниципаль районы буенча – 32 («Питрәч үзәк район хастаханәсе»).

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, табибларга язылу булмау мәсьәләсе буенча гражданнарның шикаятьләре артуның бер сәбәбе медицина белгечләре җитмәү, бу, һичшиксез, халыкка медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын һәм уңайлылыгын киметүгә тәэсир итә.

Медицина персоналы җитмәү мәсьәләләре, шулай ук Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итү предметы булып тора.

Тулаем алганда, Татарстанда 2024 елның 1 гыйнварына медицина учреждениеләренең табибларга ихтыяҗы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 1435 кеше тәшкил иткән, урта медицина персоналы – 1341 кеше. Беренче чиратта сәламәтлек саклауның беренчел звеносы табиблары: терапевтлар (64 кеше), участок табиб-терапевтлары (156), гомуми практика табиблары (124), табиб-педиатрлар (159 кеше), участок табиб-педиатрлары (120) җитми.

Медицина кадрлары белән вәзгыятьне үзгәртү өчен уңай чаралар күрелүгә карамастан, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда табибларның хезмәт хакын – 12,5%ка, урта медицина персоналын – 9%ка, кече медицина персоналын 6%ка арттыру, белгечлек программалары буенча укытуга 385 юнәлеш һәм ординатура программалары буенча 302 юнәлеш бүлеп бирү, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә «Земский доктор», «Земский фельдшер» программалары буенча медицина хезмәткәрләре өчен социаль ярдәм чаралары кертү, безнең республикага эшкә килгән табибларга торак шартларын яхшырту өчен грантлар бирүгә карамастан, сәламәтлек саклауда кадрлар проблемалары кала.

Мәсәлән, 2023 елның сентябрендә Биектау муниципаль районында яшәүче гражданка Г. «Биектау үзәк район хастаханәсе» каршындагы Биектау табиб амбулаториясен табиб-педиатрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьнең эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге медицина учреждениесендә бердәнбер табиб-педиатр кабул итә, шуңа бәйле рәвештә гражданнар әлеге табибка кабул итүгә язылуда кыенлыклар кичерә. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына килеп туган хәлне хәл итү буенча чаралар күрүне сорап хат җибәрде.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, Биектау табиблар амбулаториясендә табиб-педиатрларның штат саны 3 штат берәмлеген тәшкил иткән. Табиб-педиатрларның декрет ялына китүе сәбәпле, амбулаториягә бер участок табибы-педиатры һәм 0,75 ставкага эшләүче бер табиб хезмәт күрсәтә. Хатны карау нәтиҗәләре буенча мәсьәлә уңай хәл ителде, «Биектау үзәк район хастаханәсе» штатына тагын бер табиб-педиатр кабул ителде.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталының кире элемтә платформасы аша килгән хәбәрләрне анализлау, медицина хезмәткәрләренең кискен кытлыгы Чаллы шәһәрендә дә күзәтелгәнен күрсәтте. Чаллы шәһәренең сәламәтлек саклау идарәсе мәгълүматлары буенча, Чаллы шәһәренең дәвалау-профилактика учреждениеләрендә табиблар белән тәэмин ителеш – 60%, уртача медицина персоналы белән 77% тәшкил итә.

Килеп туган хәлдә, Вәкаләтле вәкил медицина ярдәме күрсәтүнең уңайлылыгын арттыру, медицина кадрлары белән тәэмин ителеш мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен медицина оешмалары җитәкчеләрен чакырып, Чаллы шәһәрендә күчмә эшче киңәшмә оештыруны кирәк дип тапты. Киңәшмә барышында «Л.Н.Ганиева исемендәге 4 нче шәһәр поликлиникасы»нда табиб-терапевтлар һәм гомуми практика табибларының кадрлар дефициты билгеләнде. 2023 елда барлыгы 101,75 табиб штаты берәмлеге бар, шуларның 53е табиблар белән тулы, бу комплектлауның 52%ын тәшкил итә. Барлыгы 12 табиб-терапевт һәм 2 гомуми практика табибы эшли, бу участок терапевтлары белән комплектлануның 38%ын тәшкил итә. «Кама балалар медицина үзәге» перинаталь үзәк, хатын-кызлар консультациясе, балалар поликлиникасы, балалар хастаханәсе, репродуктив сәламәтлекне саклау консультатив-диагностик поликлиникасы һәм башкалар кебек структур бүлекчәләре булган «Кама балалар медицина үзәге»ндә кадрлар белән уртача тәэмин ителеш – 56%.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан 2023 елның ноябрендә Чаллы шәһәрендә яшәүче граждан адресына ашыгыч медицина ярдәме бригадасының килүен озак көтү турында белдергән мөрәҗәгате буенча бирелгән мәгълүматка караганда, министрлык фикеренчә, беренче чиратта медицина кадрлары һәм ашыгыч ярдәм хезмәте шоферлары җитмәү сәбәпле, «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе» буенча комплектлану Чаллы шәһәрендә табиблар – 68%, урта медицина хезмәткәрләре – 94%, машина йөртүчеләр буенча 56% тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына квалификацияле һәм вакытында медицина ярдәме күрсәтү өчен ведомство карамагындагы медицина учреждениеләрендә кадрлар белән тәэмин ителешне анализлау һәм вакытында кадрлар мониторингы үткәрү максатка ярашлы булып тора. Шулай ук белгечләрне эзләү һәм эшкә кабул итү буенча эш алып барырга, шул исәптән мәшгульлек хезмәте органнары белән закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә, шулай ук мәгълүматны медицина оешмаларының рәсми сайтларында һәм «Россия эше» порталында урнаштырырга кирәк. Үз чиратында, муниципаль хакимият органнарына медицина кадрлары дефицитын киметүгә һәм табиблар һәм урта медицина хезмәткәрләре белән тулылануны арттыруга юнәлдерелгән медицина хезмәткәрләренә социаль ярдәм чараларын беркетү мәсьәләсен карау максатка ярашлы булыр иде.

Хисап елы дәвамында Вәкаләтле вәкил тарафыннан «Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү» сервисы мәгълүматларын анализлау нигезендә «Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү» сервисында уртачадан түбән бәя алган «Сәламәтлек саклау» юнәлеше буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнарның иң күп мөрәҗәгатьләре һәм теләктәшлек килгән республика медицина учреждениеләре арасында туры килүләр күзәтелде.

Мониторинг күрсәткәнчә, респондентларның күпчелеге чиратта озак көтүдән канәгать булмаган – 70 542 бәя, бу гомуми санның 18 процентын тәшкил иткән, «Табиб мөнәсәбәте» критерие буенча 57 835 бәя (гомуми санның 14 проценты), «Регистратура, шәфкать туташлары мөнәсәбәте» критерие буенча – 17 707 (яки гомуми санның 4 проценты), 6 603 (яки гомуми санның 2 проценты) учреждениеләрдәге санитар шартлардан канәгать түгел.

«Халыкка хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү» анализы нигезендә, халыкның медицина ярдәме белән канәгать булмавының сәбәпләрен ачыклау, шулай ук гражданнарның сәламәтлекне саклауга конституциячел хокукын тәэмин итү һәм гамәлгә ашыру максатларында, Вәкаләтле вәкил тарафыннан иң аз балл җыйган (3,9 баллдан кимрәк) Татарстан Республикасы медицина учреждениеләрендә күчмә эш киңәшмәләре оештырылды.

Мәсәлән, 2023 елның 10 ноябреннән 18 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан 4 медицина учреждениесенә: «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе»нә, «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе»нә, «21 нче шәһәр поликлиникасы»на, «20 нче шәһәр поликлиникасы»на барулар оештырылды, шулай ук Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты мәйданчыгында «21 нче шәһәр поликлиникасы», «20 нче шәһәр поликлиникасы», «2 нче шәһәр хастаханәсе», «3 нче шәһәр поликлиникасы», «Л. Н. Ганиева исемендәге 4 нче шәһәр поликлиникасы», «5 нче шәһәр хастаханәсе», «6 нчы шәһәр поликлиникасы», «7 нче шәһәр поликлиникасы», «2 нче балалар шәһәр поликлиникасы», «3 нче балалар шәһәр поликлиникасы», «Ф.Г. Әхмәрова исемендәге 4 нче балалар шәһәр поликлиникасы», «5 нче балалар шәһәр поликлиникасы», «6 нчы балалар шәһәр поликлиникасы», «Кама балалар медицина үзәге» медицина учреждениеләре җитәкчеләре белән гомуми эш киңәшмәсе үткәрелде.

Киңәшмәләр барышында Вәкаләтле вәкил халык белән эшне кире элемтә режимында оештыруга, «Сәламәтлек саклау» юнәлеше буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына, «ГЛОНАСС+112» ЕГИС системасына кергән хәбәрләрне карау, социаль челтәрләрдә бәяләмәләр һәм «Табибка язылу» сервисы, «Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү» сервисы кысаларында хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләүгә аерым игътибар бирде.

Мәсәлән, тәүлек әйләнәсе эшләүче травматология пункты поликлиникасына, «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе»нең стационар һәм түләүле хезмәтләр бүлегенә бару барышында: медицина учреждениесенә килүчеләр өчен уңайлы санузел, гигиена чаралары булмау, гражданнар өчен медицина анализлары нәтиҗәләрен кәгазьдә алу мөмкинлеге булмау, медицина персоналы һәм теркәү хезмәткәрләре тарафыннан пациентларга карата этика һәм деонтология нормаларын үтәмәү билгеләп үтелде.

2023 елның 20 ноябрендә «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» учреждениесенә барганда, медицина персоналы булмау сәбәпле, стационарның терапия бүлегендә (физиотерапия) пациентлар кабул ителмәве ачыкланды. Стационарның педиатрия бүлегенең балалар бүлмәсендә спорт, танып белү һәм логик уеннар өчен инвентарь юк. Поликлиника коридорында һәм санузелда идән плиткасын ремонтлау һәм гигиена чаралары белән тәэмин итү зарурлыгы бар.

2023 елның 21 ноябрендә Казан шәһәренең «21 нче шәһәр поликлиникасы»нда булганда Вәкаләтле вәкилнең игътибары белгечләр кабинетларында чират булуга юнәлтелде.

Медицина учреждениеләренә бару нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы медицина учреждениеләренең вәкаләтле җитәкчеләренә һәм Сәламәтлек саклау министрлыгына югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү буенча тулы чаралар күрү турында тәкъдимнәр бирелде. Бу йөкләмәләрнең үтәлеше Вәкаләтле вәкил контролендә.

2023 елда Вәкаләтле Вәкилнең хокук яклау практикасында сыйфатсыз медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча ГЛОНАСС +112 ЕГИС системасы аша килгән хәбәрләргә аерым игътибар бирелде.

Күрсәтелгән мөнәсәбәтләр өлкәсендә ГЛОНАСС +112 ЕГИС системасы аша килгән һәм Вәкаләтле вәкил тарафыннан 2023 елда эшкә кабул ителгән мәгълүмат хәбәрләре саны, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 136 хәбәргә артты. ГЛОНАСС +112 ЕГИС хәбәрләренең шактый өлеше ашыгыч медицина ярдәме станцияләре эшенә, медицина хезмәткәрләренең этика һәм деонтология нормаларын бозуларына, медицина учреждениеләре медицина хезмәткәрләренең медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ гражданнарны хастаханәгә салудан баш тартуына, диагностика үткәрүгә, авыру диагнозын (торышын) һәм аннан соңгы дәвалауга төгәллек кертүгә һәм стационарда тәүлек әйләнәсе медицина күзәтүен таләп итүгә, медицина ярдәмен (хезмәтен) тиешенчә күрсәтмәү, медицина хезмәткәрләренең бушлай дару препаратларына рецептлар язудан баш тартуына кагылды.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан медицина оешмалары адресына гражданнар мөрәҗәгать иткән мәсьәләләрне хәл итү буенча кичекмәстән чаралар күрүне сорап хатлар җибәрелде.

Вәкаләтле вәкилгә ЕГИС ГЛОНАСС +112 аша килгән хәбәрләрне анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрына сәламәтлек саклауның беренчел звеносы эшен камилләштерү кирәклеге турында тәкъдимнәр белән хат җибәрелде. Без, шулай ук Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары адресына ГЛОНАСС +112 ЕГИС хәбәрләрен караганда ачыкланган системалы проблемалар турында мәгълүмати хат җибәрдек.

Гражданнар өчен сыйфатлы квалификацияле медицина ярдәме алу хокукын яклау мәсьәләләре дә мөһим.

Мәсәлән, 2023 елның сентябрендә узган шәхси кабул итү кысаларында Казан шәһәрендә яшәүче гражданка С. анасы мәнфәгатьләрен яклап, пациентларны кабул итү алгоритмын бозып кына калмаган, ә анасына тиешле медицина ярдәме күрсәтмәгән «10 нчы шәһәр поликлиникасы»ның табиб-урологы гамәлләренә шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы вәкилләре белән берлектә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, алдан язылганча, пациентларны кабул итү тәртибен үтәмәү өлешендә, шулай ук «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 21.11.2011 елгы 323-ФЗ федераль закон нормаларында канун бозулар ачыкланды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча табиб-урологка дисциплинар характердагы чаралар кулланылды.

Түбәндәге мисал – 2023 елның маенда Башкортстан Республикасында яшәүче Х.ның Казан шәһәренең «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе» медицина хезмәткәрләре тарафыннан анасына кирәкле медицина ярдәме күрсәтелмәве һәм кабат чакыруга чыгудан баш тартуы турында мөрәҗәгате.

Безнең мөрәҗәгать нәтиҗәләре буенча әлеге медицина учреждениесе җитәкчелеге тарафыннан хезмәт тикшерүе һәм табиблар комиссиясе утырышы үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча күчмә бригадага кабат чакыруны үтәүгә хәбәр тапшырмаган гаепле кеше дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Әлеге тематика буенча шикаятьләр хисап елында ТР «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына да килде.

Мәсәлән, 2023 елның ноябрендә Казан шәһәреннән гражданка А. «Казан эндокринология диспансеры» адресына медицина диагностикасын тиешенчә үткәрмәү һәм дәвалау билгеләү өлешендә кызына медицина хезмәтләре күрсәтүнең сыйфаты турында шикаять белән мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры адресына эшнең барлык шартларын ачыклауга юнәлдерелгән чаралар күрә, шулай ук дәвалауны төзәтү өчен табиб-белгечкә язылып, ярдәм күрсәтү өчен хат җибәрде. Безнең мөрәҗәгать нәтиҗәләре буенча гариза бирүченең баласы кабул итүгә һәм ультратавыш тикшерүенә язылды.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренә, сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау һәм медицина оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар комплексын эшләп, медицина ярдәмен оештырудан канәгать булмаган хәлләргә игътибар итәргә кирәк. Медицина ярдәменең сыйфатын күтәрү, аның тиешле стандартларына ирешү сәламәтлек саклау идарәсе органнары эшчәнлегендә барлык дәрәҗәләрдә даими өстенлекле юнәлешләр булырга тиеш.

Арзан һәм сыйфатлы медицина ярдәме алу мәсьәләләре белән беррәттән, гражданнарның ташламалы категорияләрен дару препаратлары белән тәэмин итүгә бәйле проблема да кискенлеген югалтмый. Халыкны дару белән тәэмин итүне камилләштерү сәламәтлек саклау системасын үстерүнең мөһим юнәлешләренең берсе булып тора.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2023 елда гражданнарның ташламалы категорияләрен медицина продукциясе белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан 2 068,9 млн сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 5 488 000 мең сум акча бүлеп бирелгән. Татарстан Республикасында дару препаратлары белән тәэмин ителгән гражданнарның ташламалы категорияләре саны 258 508 кеше тәшкил итте.

Шунысы куанычлы, 2023 елның ноябрендә «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 елларның план чорына федераль бюджет турында» 27.11.2023 елгы 540-ФЗ федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, өч ел эчендә 1 триллионнан артык акча дарулар белән тәэмин итүгә тотылачак, шул исәптән кискен йөрәк-кан тамырлары авырулары булган кешеләргә, шулай ук каты авырулы балаларга.

2023 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил берничә тапкыр гражданнарның яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары белән тәэмин ителмәү турындагы мөрәҗәгатьләрен алды.

Тикшерү өчен мондый мөрәҗәгатьләр медицина учреждениеләренә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелә, ә аларны карау барышы мөрәҗәгать иткән гражданны кирәкле дару препаратлары белән тәэмин итү турында мәгълүмат алганчы контрольдә тотыла.

Мәсәлән, 2023 елның августында Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында яшәүче граждан Ш. үзенең хатыны, I төркем инвалиды мәнфәгатьләрендә, «Холина Альфосцерат» дару препараты белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьнең эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүченең хатынына медицина күрсәтмәләре буенча «Холина Альфосцерат» дару препараты билгеләнгән, ул яшәү өчен кирәкле һәм иң мөһим дару препаратлары исемлегенә керә. Әмма «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» медицина хезмәткәрләре тарафыннан әлеге ташламалы дару препараты белән тәэмин итү рецепты язылмаган.

Мөрәҗәгатьне карау кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы адресына мөрәҗәгать итүченең дару белән тәэмин ителешкә хокукларын яклау максатында чаралар күрү кирәклеге турында хат җибәрелде. Гариза бирүченең хатыны Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгате нәтиҗәләре буенча кирәкле дару препараты белән тәэмин ителде.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына да дару белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча шактый күп хәбәрләр килде, анда гражданнар хроник авыруларны дәвалау өчен дару препаратлары белән вакытында тәэмин ителмәүләре, яшәү өчен кирәкле дару препаратлары белән тәэмин итүдә кыенлыклар, бәяләр арту сәбәпле аларның даруханә челтәрләрендә булмавы турында хәбәр иттеләр.

Хисап елында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына дару препаратлары белән вакытында тәэмин ителмәү, даруханә челтәрләрендә аларның булмавы турында 65 хәбәр килгән.

Аерым алганда, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына 2022 елның декабрендә Зәй муниципаль районыннан гражданка С.дан аңа кирәкле ташламалы дару препараты булмавы турында хәбәр килде. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, әлеге мөрәҗәгатьне эшкә алгач, тәэминатчы мәгълүматы буенча, «Таттехмедфарм» ДУП складына кирәкле препаратны илтеп җиткерү 2022 елның 31 декабренә планлаштырылган, дип хәбәр итте. Әмма бу билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырылмаган. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы 2023 елның 7 февралендә мөрәҗәгатькә «Хәл ителгән» статусы бирде, ә шикаять бирүче дару препараты белән тәэмин ителмәде.

Хәбәр итү датасына карамастан, әлеге мәсьәлә 2023 елда хәл ителде. Вәкаләтле вәкил, әлеге мөрәҗәгатьне контрольгә алып, мөрәҗәгать итүчене кирәкле дару препараты белән тәэмин итү буенча чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры адресына хат җибәрде. Мөрәҗәгатьне кабат караганнан соң гына гражданка С.ны кирәкле дару препараты белән тәэмин итү мөмкинлеге табылды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, ташламалы дарулар белән тәэмин итүдә җитешсезлек икътисадый нәтиҗәләргә генә түгел (гражданнар кирәкле даруларны үз хисабына алырга мәҗбүр булганда), ә тормыш сыйфатының начарлануына да китерә (пациентлар рецепт алу мөмкинлеген озак көтәргә, даруханәдә дару булу-булмау турында борчылырга мәҗбүр булганда һ.б.), тормыш һәм сәламәтлеккә куркыныч тудыра.

Бу уңайдан Вәкаләтле вәкил, 2024 елда Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләре гражданнарның медицина ярдәме күрсәтү эшен оештырудан канәгать булмаган хәлләргә игътибар итәрләр, дип өметләнә. Гражданнарның сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокукларын яклау буенча эшчәнлек киләчәктә дә дәвам итәчәк

3.4. БЕЛЕМ АЛУГА ХОКУК

Белемгә конституцион хокукны гамәлгә ашыру, белем бирү процессында катнашучыларның законлы мәнфәгатьләрен үтәү, аның матди-техник җиһазлануы, эчтәлеге, сыйфаты стратегик дәүләт бурычы булып тора. Бүгенге көндә мәгариф һәр гражданның шәхси уңыш траекториясен генә түгел, ә илебезнең традицион кыйммәтләрен саклауның төп факторы булып тора.

Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау эшчәнлегендә белемгә хокукны гамәлгә ашыруны тәэмин итү мәсьәләләренә мөһим урын бирү очраклы түгел.

Узган еллардагы кебек үк, балаларның белем алуга хокуклары бозылу турындагы мәгълүматны үз эченә алган һәр мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты һәм муниципаль органнарның мәгариф оешмалары белгечләрен җәлеп итеп, мәгариф оешмасына барып каралды.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил гражданнарның мәгариф өлкәсендәге хокукларын яклау мәсьәләләре буенча максатчан эш алып барды, моңа Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Казан шәһәре башкарма комитетының мәгариф идарәсе вәкилләре дә җәлеп ителде.

Вәкаләтле вәкил дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан белем алу хокукын гамәлгә ашыруның төгәл проблемалары буенча тәкъдимнәр кертү һәм өйрәнү максатларында мәгълүмат җыюны һәм анализлауны гамәлгә ашырды, массакүләм мәгълүмат чараларында мәгариф системасының эше турында мәгълүматны үз эченә алган яңалыклар тасмасы даими күзәтелде.

2023 елда Татарстанда икътисадның инновацион үсеше таләпләренә, җәмгыятьнең һәм илебезнең һәр гражданының заманча ихтыяҗларына туры килгән белем бирүнең уңайлылыгын һәм сыйфатын арттыру буенча эш дәвам итте.

Мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан, «Демография» илкүләм проекты кысаларында республикада балалар бакчаларында өстәмә урыннар булдыру буенча чаралар гамәлгә ашырыла. 2018–2022 елларда 15 030 урын булдырылган, шул исәптән 3 яшькә кадәрге балалар өчен 8 350 урын, шул исәптән 65 балалар бакчасы төзү һәм 71 төркемне эшләүче мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында үзгәртеп кору юлы белән.

Хисап елында республикада 1000 урынлы 4 балалар бакчасы төзелде. Моннан тыш, «Авыл территорияләрен комплеклы үстерү» федераль программасы кысаларында Мамадыш муниципаль районында 120 мәктәпкәчә урынга исәпләнгән, Биектау муниципаль районының Коркачык авылында 20 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә төркемнәр белән ике мәктәп төзелде. Татарстан Республикасы бюджеты хисабына Әлки муниципаль районының Түбән Колчура авылында 25 урынлы, Балтач муниципаль районының Алан авылында 15 урынлы балалар бакчасы булган ике мәктәп төзелде.

Республика җитәкчелеге тарафыннан балаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин итү буенча кабул ителгән системалы чаралар ярдәмендә мәктәпкәчә учреждениеләрдә урыннар җитмәү проблемасы практик рәвештә хәл ителгән.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, балалар бакчаларында урыннар белән тәэмин ителеш 100% тәшкил итә.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил билгеләп үткәнчә, мәктәпкәчә белем бирү мөмкинлеген саклап калу өчен 2024 елда мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен төзүне, аеруча күп кеше яши торган урыннарда төзүне дәвам итү зарур.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: узган ел белән чагыштырганда, 2023 елда балаларның мәктәпкәчә белем алу хокукын бозу турында мөрәҗәгатьләр саны шактый кимеде. Ата-аналар (законлы вәкилләр) күбесенчә Вәкаләтле вәкилдән балаларны мәктәпкәчә учреждениеләрдә урыннар белән тәэмин итүдә ярдәм итүне сорыйлар. Бу мәсьәлә яңа микрорайоннарда яшәүчеләр өчен аеруча актуаль.

Үз чиратында, һәр килгән мөрәҗәгать буенча, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәр конкрет балага карата адреслы эш алып бару һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына кабул итүнең компромисслы вариантларын эзләү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итте.

Мәктәпкәчә белем бирүнең уңайлылыгы мәсьәләләре белән беррәттән, сыйфатлы гомуми белем алу мәсьәләләре дә актуальлеген саклап калды.

Төбәк мәгариф системасында 1410 мәктәп (1319 гомуми белем бирү мәктәбе һәм мәктәп-интернат, физик мөмкинлекләре чикле балалар өчен 53 мәктәп һәм мәктәп-интернат, ике санатор мәктәп-интернат, 10 кичке мәктәп, 23 дәүләтнеке булмаган мәктәп, Мәдәният һәм Спорт министрлыклары карамагында булган ике гомуми белем бирү мәктәбе, бер девиант тәртипле балалар мәктәбе) эшли, аларда 486 меңнән күбрәк бала белем ала.

2023 елда 9 674 урынлы 11 мәктәп һәм 300 урынлы бер өстәмә корпус төзелде.

Хәзерге мәгариф системасы барлык категория укучылар өчен, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен тигез шартлар булдыруны таләп итә.

Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) сәламәтлекләре чикле балаларның белемгә хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләре аерым игътибар белән каралды.

Кызганычка каршы, хокук яклау практикасы сәламәтлеге чикле балаларның гомуми белем бирү оешмаларында укыту һәм тәрбияләүне оештыру проблемалары белән очрашуын дәвам итүен күрсәтә.

2023 елның февралендә безнең адреска Чаллы шәһәрендә яшәүче гражданка, аның улы һәм мәгариф процессында катнашучылар арасында килеп туган конфликтлы хәл турында мөрәҗәгать итте. Гариза бирүченең улы – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле бала. 2022–2023 уку елында ул Чаллы шәһәре «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 35 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең беренче сыйныфына кабул ителде. Уку башланганнан соң кыска вакыт эчендә сыйныф җитәкчесе аны әзерлеге түбән, «йомшак» укучы дип тасвирлый. Тасвирламада шулай ук баланың социаль яктан яраклашмавы, сыйныфта укуга әзер булмавы әйтелә.

Психологик-медицина-педагогик комиссия нәтиҗәсе буенча, гариза бирүченең улын укыту махсус шартлар тудыруны, шул исәптән гомуми тьюторлык озата баруын гамәлгә ашыруны таләп итә.

Шул ук вакытта урынга чыгып тикшерү барышында без, балага тьютор да, психологик-педагогик консилиум да оештырылмаганлыгын ачыкладык.

Вәкаләтле вәкил Чаллы шәһәре башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы адресына шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм психологик-медик-педагогик комиссия тәкъдимнәренә туры китереп, сәламәтлеге чикле

балаларны укыту һәм тәрбияләү эшен оештыру кирәклеге, мәгариф оешмаларында катнашучылар арасында конфликтлы хәлләргә юл куймау буенча системалы чаралар күрү, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән эшне көчәйтү турында тәкъдимнәр җибәрде.

Хатны карау нәтиҗәләре буенча мәктәп хакимияте сәламәтлеге чикле баланың гомуми белем бирү мәктәбендә укуын тәэмин итү өчен махсус шартлар булдыру буенча чаралар күрде, сәламәтлеге чикле баланың хокукларын бозуга юл куйган гаепле кешеләр дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Һичшиксез, ассистент (ярдәмче) һәм (яки) тьютор хезмәте тәкъдим итү сәламәтлеге чикле балалар белем алсын өчен мөһим махсус шартларның берсе булып тора.

Психологик-медицина-педагогик комиссия нәтиҗәсенә ярашлы рәвештә, республиканың гомуми белем бирү оешмаларында 560 бала тьюторлык ярдәменә мохтаҗ. Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, республика мәктәпләрендә тьюторларның штат берәмлекләре саны 188,89 берәмлек тәшкил итә.

Шунысы куанычлы: әлеге мәсьәләне хәл итү максатыннан республика җитәкчелеге тарафыннан 2023 елда Казан шәһәренә педагог-психологлар, укытучы-логопедлар һәм тьюторлар хезмәтенә түләү өчен 42,4 млн сум акча бүлеп бирелде.

Шул ук вакытта хәзерге вакытта 33 гомуми белем бирү оешмасыннан укучыларга булышу өчен, бары тик адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча гына белем бирү эшчәнлеген алып бару өчен, 284 тьютор ставкасы таләп ителә. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы җитәкчелеге адресына мөмкинлекне карау үтенече белән өстәмә хат җибәрелде. Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәлә уңай хәл ителер дип ышана.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил инвалидлар һәм сәламәтлеге чикле кешеләр мәгариф объектларына тоткарлыксыз керә алсын өчен шулай ук чаралар күрде.

Әйтик, 2023 елның октябрендә Вәкаләтле вәкил адресына ата-аналар (законлы вәкилләр) Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге 109 нчы балалар бакчасы» янында инвалидлар һәм аларны озата баручы затлар өчен парковка урыннарын оештыруда ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте: (адресы: Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 20 йорт, корп.1).

Без оештырган урынга чыгып тикшерү барышында балалар бакчасына оператив идарә итү хокукында күпкатлы торак йортның беренче катындагы бина беркетелгәнлеге ачыкланды. Бу учреждениегә үсештә артта калган, үзүзләрен йөртә алмаган балалар килә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) балаларны балалар бакчасына алып килгәч, машиналарны торак йорт парковкасында калдыралар, аннан соң аларны кулларында яки колясакда балалар бакчасына озата баралар. Шлагбаум урнаштырылганнан соң балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) күпфатирлы йорт территориясенә тоткарлыксыз керә алмаган.

Күпфатирлы йорт территориясенә керү мөмкинлеге булмау сәбәпле һәм мәктәпкәчә учреждение янындагы автомобиль юлында тукталыш урыннары булмау сәбәпле, ата-аналар автомобиль юлының йөрү өлешендә, «Туктау тыелган» билгесе гамәлдә булган зонада машиналар куярга мәҗбүр булганнар, бу үз чиратында инвалид балалар катнашында юл-транспорт һәлакәтләренә алшартлар тудырган һәм аларның тормышын һәм сәламәтлеген куркыныч астына куйган.

Инвалидлар һәм аларны озата баручы затлар өчен парковка оештыру максатыннан, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәре башкарма комитеты адресына, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча район комиссиясе утырышында балалар бакчасы урнашкан Зәкиев урамы, 20 нче йортка алып баручы юл хәрәкәтен оештыру схемасын үзгәртү мәсьәләсен карау кирәклеге турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итте.

Безнең тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча, Казан шәһәре Совет районы хакимияте сәламәтлеге чикле балаларны китерүче ата-аналарның автомобильләре өчен парковка урыннарын оештыру буенча чаралар күрде.

Икенче шундый очрак «Сәламәтлекләре чикле балалар өчен 7 нче мәктәп-интернат»та укучы балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) мөрәҗәгатеннән караганда ачыкланды.

Мөрәҗәгать итүчеләр балаларның җәмәгать транспорты тукталышларыннан мәктәпкә кадәр имин хәрәкәт итүен тәэмин итүдә ярдәм итүне сорадылар. 2023 елның ноябрендә мәгариф оешмалары территорияләрен тикшерү барышында без әлеге мәгариф оешмасы янында инвалидлар өчен парковка булмавына игътибар иттек.

Әлеге хәлләрне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына «Сәламәтлекләре чикле балалар өчен 7 нче мәктәп-интернат» бинасы янында парковка оештыру турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итте. (Доклад язылган вакытта тәкъдимнәр карала иде.)

Сәламәтлекләре чикле балалар өчен уңайлы шартлар тудыру кирәклеген билгеләп, аларның белем бирү оешмаларында ике тапкыр бушлай туклануга хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләсенә кагылмыйча ярамый.

Әлеге балаларның ике тапкыр туклануга хокукларын яклау мәсьәләләрен хәл итү өчен кирәкле финанслауны бүлеп бирүгә Вәкаләтле вәкил 2021 елдагы эшчәнлеге хисабы вакытында да игътибарны юнәлткән иде.

2022 елның 1 сентябреннән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» федераль законның 79 нчы маддәсенә үзгәрешләр кертелде, алар белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда яшәмәгән укучыларның федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар хисабына ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын билгели.

Федераль закон шулай ук ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) бушлай ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алыштыру хокукын билгели.

Күрсәтелгән үзгәрешләр, бер яктан, укучыларның каралган категориясен туклану белән тәэмин итү тәртибе турындагы мәсьәләне мәҗбүри хәл итүне гарантияләргә мөмкинлек бирде, икенче яктан, әлеге мәсьәләне конкрет хәл итүгә сак карашны сакларга мөмкинлек бирде.

Шул ук вакытта гражданнарның мөрәҗәгатьләре әлеге хокукны гамәлгә ашырганда проблемалы мәсьәләләр булуын күрсәтә.

Мәсәлән, 2023 елның октябрендә Вәкаләтле вәкил адресына Казанда яшәүче гражданка А.дан кызын ике тапкыр ашату урынына акчалата компенсация бирүдән баш тартулары турында мөрәҗәгать килде.

Мөрәҗәгатькә карап тикшерү барышында без, акчалата компенсация бирүдән баш тарту Казан шәһәре башкарма комитетының «Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын туклану белән тәэмин итү турында»гы 18.01.2022 елгы 110 нчы карарында (алга таба – 110 нчы карар) азык-төлек җыелмасын акчалата компенсация белән алыштыру тәртибен билгеләүче норматив нигезләмәләрнең булмавына бәйле икәнен ачыкладык.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты адресына күрсәтелгән карарга үзгәрешләр кертү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелде.

«Өйдә белем алучы балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) компенсация түләүне гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 14.01.2016 елгы 07-81 нче хаты белән үз позициясен нигезләп, норматив-хокукый актка үзгәрешләр кертү өчен нигезләр булмау сәбәпле, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Вәкаләтле вәкилнең тәкъдимнәрен канәгатьләндермәде. Казанда өйдә укучыларны азык-төлек җыелмасы белән тәэмин итү каралган.

110 нчы карарның гамәлдәге законнар нормаларына туры килмәве турындагы мәсьәлә, түләүсез ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге булмау өлеше, Казан шәһәре прокуратурасының административ дәгъва гаризасы буенча Казанның Вахитов район судында суд бәхәсе предметы булып торды. Казан шәһәре Вахитов район суды административ дәгъва гаризасын канәгатьләндерде.

2023 елның 25 декабрендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан сәламәтлекләре чикле балаларны өйдә ике тапкыр бушлай ашатуны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге биргән «Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын туклану белән тәэмин итү турында» карар кабул ителде.

Бөтен белем бирү процессы, ничек кенә булмасын, балаларның физик һәм психологик куркынычсызлыгы мәсьәләләренә бәйле. Баланың иминлеге хокукы һәр яктан тормышка ашырылырга тиеш.

Мәгариф оешмаларына йөргәндә, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре беренче чиратта мәгариф оешмаларының террорчылыкка каршы иминлегенә игътибар итә.

Балаларның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре шулай ук Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итү предметы булды.

Мәсәлән, 2023 елның августында шәхси кабул итү кысаларында Вәкаләтле вәкил адресына Арча муниципаль районында яшәүче гражданка Х.дан белем бирү оешмасында булган вакытта балаларның иминлеген тәэмин итү турында мөрәҗәгать килде.

Мөрәҗәгать итүченең аңлатмаларыннан күренгәнчә, башлангыч сыйныф балаларын «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының 7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә» (икенче бинада) укыту мәдәният йорты бинасында, икенче катта оештырылган. 2023 елның 1 сентябренә әлеге бинада 1–3 сыйныфларда 120дән артык укучы белем ала. Гариза бирүче укучыларның иминлеген тәэмин итмәүне билгеләп үтте: сак юк, керү белән идарә итүне контрольдә тоту системасы, видеокүзәтү урнаштырылмаган.

Вәкаләтле вәкилнең Арча муниципаль районындагы җәмәгатьчелек ярдәмчесе оештырган күчмә тикшерү барышында гариза бирүченең дәлилләре расланды.

Безнең тикшерүдән соң керү юлына яңа контроль һәм объект белән идарә итү системасы урнаштырылды.

Һөнәри һәм югары белем алу хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләре Вәкаләтле вәкилнең даими игъибарында.

Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген 100 һөнәри белем бирү оешмасы (88 дәүләт һәм 12 шәхси), 45 югары белем бирү оешмасы һәм белем бирү оешмалары филиалларының киң челтәре башкара.

2023 елгы кабул итү кампаниясе нәтиҗәләре буенча бакалавриат, белгечлек һәм магистратура программаларына 49 меңнән артык студент кабул ителгән, шуларның 44 процентыннан артыгы бюджет ассигнованиеләре хисабына, 56 проценты түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында килешүләр буенча.

Бакалавриат, белгечлек һәм магистратура программаларына барлык уку формалары буенча кабул итү өчен 3,5 меңгә якын максатчан урын бүлеп бирелгән. Бу бюджет урыннарының гомуми күләменең 16% тан артыгы.

Татарстан Республикасында югары белем алучы чит ил студентлары саны елдан-ел арта бара. Татарстанның югары белем бирү оешмаларында 130дан артык илдән 22 меңнән күбрәк чит ил студенты белем ала.

Чит ил студентларын адаптацияләү һәм укытуга бәйле проблемалы мәсьәләләрне тикшерү максатыннан, узган елның сентябрендә без Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә «Россиядә чит ил студентлары: хокукый хәл һәм ярдәм институтлары» темасына «түгәрәк өстәл» оештырдык.

Чара Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татьяна Николаевна Москалькова ярдәме белән, Кытай, Иран, Үзбәкстан дипломатик корпуслары вәкилләрен, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләрен, Россиянең 30дан артык төбәгеннән Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, иҗтимагый һәм студент оешмалары вәкилләрен, шулай ук чит ил студентларын чакырып үтте.

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында катнашучылар чит ил студентларын укытуның актуаль мәсьәләләрен билгеләделәр, алар социализацияләү һәм адаптацияләү, тел компетенциясен камилләштерү, хокукый грамоталылыкны арттыру, Россия Федерациясе территориясендә булуның куркынычсыз хокукый шартларын булдыру белән бәйле. Утырышта катнашучылар Татарстан Республикасы югары белем оешмаларында һәм Казан (Идел буе) федераль университетында чит ил укучыларына ярдәм итүнең уңай тәҗрибәсен, Татарстан Республикасында чит ил укучыларының хокукларын тәэмин итү буенча гамәли эшчәнлектә системалылыкны һәм киң ведомствоара хезмәттәшлекне билгеләп үттеләр.

Вәкаләтле вәкил чит илләрнең Россия Федерациясендәге вәкиллекләре белән чит ил студентларының хокукларын үтәү һәм чит ил укучыларының Россия Федерациясе территориясендә булу кагыйдәләрен үтәү максатларында тыгыз хезмәттәшлек кирәклеген билгеләп үтте.

Хисап елында укучыларның хокукларын үтәүне бәяләү максатыннан Вәкаләтле вәкил даими рәвештә һөнәри белем бирү оешмаларына чыкты.

«Алабуга политехник көллияте» һәм «Алабуга медицина училищесы» студентларын укыту оештырылган Алабуга «Аерым икътисадый зонасы» АЖгә бару кысаларында, хезмәттәшлек турындагы килешүгә ярашлы рәвештә, Вәкаләтле вәкил уку йөкләнешен бүлү мәсьәләләренә аерым игътибар бирде.

Уку һәм практик дәресләр расписаниесе, беренче чиратта, укучыларның ял итү хокукларын үтәүне, уку йөкләнешен һәм мөстәкыйль эшне тигез бүлүне, шулай ук дәрестән тыш чаралар үткәрү мөмкинлеген, уку процессын оештыруның санитар-гигиена таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

Шул ук вакытта без, «Алабуга политехник көллияте», «Алабуга медицина училищесы» студентларының уку йөкләнешен арттыру фактын ачыкладык.

Вәкаләтле вәкил шулай ук игътибарны «Алабуга «Аерым икътисадый зонасы» АЖдә студентларны тукландыруны оештыруга юнәлтте. Студентларга икенче ризык (аерым контейнерларда), салат һәм икмәк-булка гына тәкъдим ителгән. Шул ук вакытта тәкъдим ителгән ассортимент балаларның яшь һәм физиологик үзенчәлекләренә җавап бирә алмаган.

Балигъ булмаган укучылар күпчелек вакытларын «Алабуга «Аерым икътисадый зона» АЖ территориясендә үткәргән шартларда, аларны физиологик, яшь ихтыяҗларына җавап бирүче тулы баланслы туклану белән тәэмин итү өстенлекле бурыч булырга тиеш. Бу шулай ук аларның психик һәм физик сәламәтлеге, демографик процесслар, димәк, илнең социаль-икътисадый үсеше белән тыгыз бәйләнгән.

Без шулай ук «Алабуга» «Аерым икътисадый зонасы» җәмгыяте хостелында яшәүче «Алабуга медицина училищесы» студентлары белән тәрбия эшен оештыруга формаль якын килүне билгеләп үттек.

«Алабуга «Аерым икътисадый зонасы» АЖ генераль директоры адресына, шулай ук «Алабуга медицина училищесы» оештыручысы булган республика Сәламәтлек саклау министрлыгы адресына, яшь һәм психологик үзенчәлекләрдән чыгып, студентларга уку, укудан тыш йөкләнешне билгеләү, шулай ук студентларны кайнар ризык белән тәэмин итү, хостелда яшәүче студентлар белән тәрбия эшен оештыру буенча чаралар күрү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Вәкаләтле вәкилнең игътибары, узган елда, шулай ук һөнәри белем алуга укучыларның хокукларын тәэмин итү өлкәсендә студентларны белем бирү оешмаларының тулай торакларында торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә актуаль мәсьәләгә юнәлтелде.

Татарстан Республикасында 100 дәүләт һөнәри белем бирү оешмасының 54ендә студентлар тулай торагы бар. Аларның карамагында 69 тулай торак бинасы бар.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан 45 югары белем бирү оешмасының 23е студентлар тулай торакларының оператив идарәсендә тора.

2023 елда Иннополис университетының 1 мең урынга исәпләнгән өч яңа торак корпусы ачылды. Яңа биналар төзү хисабына университетның торак кампусы 1 меңнән 2 мең урынга кадәр киңәйтелә, ә студентлар корпусларының гомуми мәйданы 35,3 меңнән 63,6 мең квадрат метрга кадәр арта. Кампус территориясендә бушлай Wi-Fi бар, студентлар өчен клининг-сервис һәм кер юу бүлмәсе эшли, 200 урынлы ике ашханә һәм уку һәм ял итү бүлмәләре бар. Кампус биналары «Уңайлы мохит» программасы буенча җиһазландырылган. Биналарга хезмәт күрсәтү мәгълүмати модельләштерү технологияләрен кулланып башкарылачак.

Татарстанда агымдагы елда студентлар өчен Казан милли тикшеренү техник университетының җиде катлы, 620 кешегә исәпләнгән яңа тулай торагы үз ишекләрен ачты.

Кабул ителгән чараларга карамастан, студентларның хокукларын тулай торакларда урын белән тәэмин итү өлкәсендә берничә проблемалы мәсьәлә кала.

2023 елның июлендә без югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары тулай торакларында студентларның яшәү шартлары турында социаль челтәрләрдә урнаштырылган мәгълүматны анализладык, анда без әлеге хокукны гамәлгә ашыруның аерым проблемалы мәсьәләләрен ачыкладык.

Шуңа бәйле рәвештә, хисап елында без, Вәкаләтле вәкил каршындагы Яшьләр советы (алга таба – Яшьләр советы) белән берлектә, белем бирү оешмаларының укучыларның хокукларын үтәвенә мониторинг үткәрдек, ул студентларны торак урыннары белән тәэмин итү өлкәсендә законнар белән җайга салу һәм хокукны куллану практикасы проблемаларын комплекслы өйрәнүгә, шулай ук күрсәтелгән мөнәсәбәтләр өлкәсендә тәкъдимнәр эшләүгә юнәлдерелгән.

Без 5 югары белем бирү оешмасының 9 тулай торагына: Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетына; Казан милли тикшеренү технология университетына; Казан (Идел буе) федераль университетына; Россия дәүләт хокук университетына; А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ тулай торакларына баруны оештырдык.

Мониторинг барышында биналарны, тулай торак биналарын закон таләпләренә туры китереп тиешле хәлдә тотуга аерым игътибар бирелде. Вәкаләтле вәкил билгеләп үткәнчә, Татарстанның югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан тулай торак биналарына капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрү буенча планлы эш оештырылган.

Мәсәлән, Казан (Идел буе) федераль университеты 2023 елда ике тулай торак бинасын капиталь ремонтлауга 220 миллион сумнан артык акча бүлеп биргән. Ремонтланган торак биналарында студентлар өчен уку һәм яшәү өчен тиешле шартлар тудырылган: барлык торак бүлмәләрдә сыйфатлы, заманча ремонт ясалган, яңа җиһазлар һәм йомшак инвентарь сатып алынган. Моннан тыш, тулай торак «Уңайлы мохит» программасы таләпләренә тулысынча җавап бирә: ул пандуслар белән җиһазландырылган, беренче катта инвалидлар өчен киңәйтелгән керү урыны булган бүлмәләр урнашкан.

Шул ук вакытта мониторинг барышында Татарстанда студентлар тулай торагының 25 бинасы капиталь ремонт таләп итүе ачыкланды. Хәзерге вакытта аларны заман таләпләренә яраклаштыру өчен финанс чаралары җитәрлек түгел.

2021 елда Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин 2021–2030 елларда федераль югары уку йортлары тулай торакларында капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итәргә йөкләмә бирде.

Әлбәттә, әлеге мәсьәләне хәл итү комплекслы якын килүне һәм федераль бюджеттан тиешле финанслауны бүлеп бирүне таләп итә.

Күрсәтелгән мөнәсәбәтләр өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, торак фонды булган югары белем бирү оешмаларына, билгеләнгән санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә тулай торак урыннарын тиешле хәлдә тоту, анда яшәүче гражданнарның гигиена кагыйдәләрен үтәү буенча чараларны көчәйтергә, шулай ук тулай торак биналарына студентлар өчен куркынычсыз һәм уңайлы яшәү шартлары булдыру максатыннан, агымдагы һәм капиталь ремонтны вакытында үткәрү буенча эшне дәвам итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советының чираттагы утырышында студентларны тулай торакларда урыннар белән тәэмин итү, аларның яшәү шартларын яхшырту мәсьәләләрен карау максатка ярашлы, дип саныйбыз.

Әлеге бүлектә, күргәнегезчә, гражданнарның белемгә хокукларын тәэмин итү өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләр, аларның масштабы һәм кискенлеге буенча аерыла, әмма аларның һәркайсы белем бирү процессында катнашучыларның үзләреннән дә, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан да игътибар таләп итә.

3.5. ТОРАККА ХОКУК

Россия Федерациясе Конституциясе торакка хокукны кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре исәбенә кертә. Бу конституцион хокук кеше тормышының нигезенә кагыла, социаль иминлек, икътисадый үсеш һәм җәмгыятьнең тотрыклылыгының төп күрсәткечләренең берсе булып тора.

Торак һәм торак-коммуналь тармакта дәүләт сәясәтенең төп өстенлекләре булып, барлык гражданнар өчен торакның уңайлылыгын тәэмин итү, шулай ук торак фондының уңайлылык күләменең халык ихтыяҗларына туры килүе тора.

Дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешен тормышка ашыру максатыннан Татарстан Республикасында торак төзелеше темплары соңгы елларда кимеми. Безнең республика бу күрсәткеч буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында лидерларның берсе булып кала.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 21 декабренә булган мәгълүматларына караганда, республикада 3 336,1 мең кв. метр торак файдалануга тапшырылган, бу узган елга караганда 7,8 процентка артыграк.

Торак төзелешенең югары темплары республикада гамәлдә булган социаль ипотека программасы хисабына да саклана, аның кысаларында 2023 елда 160,7 мең кв. метр мәйданлы 64 күпфатирлы йорт файдалануга тапшырылган.

Татарстан Республикасы шулай ук ташламага ия гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча йөкләмәләрне үтәү чараларын күрә. Хисап елында 34 күп балалы гаилә, 81 яшь гаилә, 3 чернобыльче һәм 1 мәҗбүри күченүченең торак шартлары яхшыртылган.

Кабул ителгән чараларга карамастан, торак хокук мөнәсәбәтләре халыкның барлык катлауларына кагылганга күрә, соңгы елларда әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр саны кимеми.

2023 елда Вәкаләтле вәкил адресына гражданнарның торак хокукларына кагылышлы 570 мөрәҗәгать килгән (2022 елда – 529 мөрәҗәгать). Социаль якланмаган категория гражданнарны торак белән тәэмин итү, күпфатирлы йортларны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану, торак йортларда агымдагы һәм капиталь ремонт үткәрү, коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору тәртибен бозу, идарәче һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның эшләре республика халкының хисап елында Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләре темасы булып хезмәт итте.

Гражданнарның бу өлкәдәге проблемаларын хәл итүдә берничә ел дәвамында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтә. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм идарәче оешмалар тарафыннан 2023 елда торак-коммуналь хуҗалык тармагындагы проблемалар турында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнардан кергән 6 853 шикаять уңай хәл ителде.

2023 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Торак-коммуналь хуҗалык» юнәлеше буенча 7 639 хәбәрнамә басылып чыкты, шулардан «Йортны тоту» буенча – 3 646 хәбәрнамә, «Коммуналь хезмәтләр» – 2 940 хәбәрнамә һәм «Йортны агымдагы ремонтлау» – 935 хәбәрнамә. Иң күп мөрәҗәгатьләр Казан, Чаллы шәһәрләре, шулай ук Татарстан Республикасының Әлмәт, Түбән Кама, Бөгелмә муниципаль районнарыннан килде.

2023 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның һәм алар арасыннан булган яшь кешеләрнең торак хокукларын яклауга аерым игътибар бирелде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2023 елда ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан 762 граждан торак белән тәэмин ителгән, бу 2022 ел белән чагыштырганда 27%ка күбрәк.

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар безгә төрле сораулар буенча мөрәҗәгать итәләр. Әмма әлеге категория гражданнардан ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм аларның арасыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле затларны исемлеккә кертүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләр аеруча борчый, чөнки законлы вәкилләр һәм опека һәм попечительлек органнары тарафыннан аларның торак хокукларын яклау буенча чаралар балигъ булганчыга кадәр кабул ителми.

2019 елның 1 гыйнварыннан опека һәм попечительлек органнарына законлы вәкилләрнең ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны исемлеккә кертү турында гаризаларны вакытында тапшыруын һәм, мондый гаризалар бирелмәгән очракта, әлеге балаларны исемлеккә кертү буенча чаралар күрүне контрольдә тоту бурычы йөкләнгән.

Шуңа да карамастан, еш кына ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, вакытында ярдәм күрсәтелмәгән яшь кешеләр үз хокукларын судта якларга мәҗбүр.

2023 елда гына да, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдим иткән мәгълүматларга караганда, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм прокуратура органнары аларның мәнфәгатьләрендә торак урыннары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча судка 179 дәгъва гаризасы биргән.

Әлеге проблеманың актуальлеген күрсәтүче мисалларның берсе – Казан шәһәрендә яшәүче А.ның 2023 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкилгә аны исемлеккә кертүдә ярдәм күрсәтү турындагы мөрәҗәгате. Аны караганда законлы вәкилләре һәм опека һәм попечительлек органы тарафыннан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында тәрбиягә бала алган гаиләдә яшәгәндә, мөрәҗәгать итүченең торак хокукларын яклау чараларын күрмәүләренә игътибар бирелде.

Әлеге мөрәҗәгатьне объектив һәм һәрьяклап карау максатыннан күчмә тикшерү оештыру турында карар кабул ителде, аның барышында Әлки муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органының һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мөрәҗәгать авторын исемлеккә кертү буенча тиешле чаралар күрмәве ачыкланды.

Әлеге категория гражданнарның социаль зәгыйфьлеген исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренең исемлеккә кертү турында вәкаләтле органга гаризаларны вакытында тапшыруларын контрольдә тоту эшен оештыру зарурлыгы турында тәкъдимнәр җибәрелде.

2023 елның июненнән ноябрьгә кадәр ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калганнарның законлы вәкилләре һәм опека һәм попечительлек органнарының җаваплы җитәкчеләренең эшләп җиткермәве фактлары буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне тикшерү өчен Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре, республиканың тугыз муниципаль районына (Әлки, Апас, Арча, Буа, Биектау, Лаеш, Минзәлә, Питрәч, Балык Бистәсе муниципаль районнары) барды, алар барышында опека һәм попечительлек бүлекләре алып барган эш өйрәнелде.

Опека һәм попечительлек органнары эше белән танышу барышында балигъ булмаганнарга караган торак урыннардан файдалануны һәм саклауны тиешенчә контрольдә тоту, әлеге категория гражданнарның тораклары булмаганда балигъ булмаганнарның законлы вәкилләренең аларны вакытында исемлеккә кертү буенча гаризалар бирүен контрольдә тотуы тикшерелде.

Балигъ булмаганнарга тиешле торакны тиешенчә кулланмау һәм сакламау, вакытында тикшерүләр үткәрмәү, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга тиешле торакка Бердәм күчемсез милек дәүләт реестрында актуаль мәгълүматлар булмау, балигъ булмаганнарның коммуналь хезмәтләр өчен бурычларын киметү буенча чаралар күрмәү фактлары ачыкланды.

Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасының Әлки, Апас, Биектау һәм Лаеш муниципаль районнары башкарма комитетлары җитәкчеләре адресына опека һәм попечительлек органнары эшенә карата хатлар җибәрде.

Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мөлкәт хокукларын яклауны гамәлгә ашырганда опека һәм попечительлек органнары эшендә ачыкланган проблемаларның системалы характерына бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил 2023 елның декабрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан муниципаль районнар һәм шәһәр җирле үзидарә органнары, министрлыклар вәкилләре катнашында оештырылган киңәшмә барышында опека һәм попечительлек бүлекләре вазыйфаи затларының игътибарын әлеге кимчелекләргә юнәлтте.

Проблемалы мәсьәләләргә күзәтүне исәпкә алып, Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саныйбыз:

– торак урыннардан файдалануны һәм саклауны контрольдә тоту максатында, социаль наем шартнамәләре буенча торак алучылар яисә аларның гаилә әгъзалары яисә ятим балалар һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә, опекада яки ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар карамагында булган, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар милекчеләре булып торган торакның санитар һәм техник торышын тиешле контрольдә тоту буенча Татарстан Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендә чыккан 374 нче карары белән расланган, социаль наем шартнамәләре буенча торак алучылар яки аларның гаиләләре әгъзалары яисә милекчеләре ятим балалар яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар булган торак биналардан файдалануны һәм аларның саклануын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру Тәртибенең 2.7.1 пунктында билгеләнгән вакыт аралыгында планлы тикшерүләр үткәрергә;

– социаль наем шартнамәләре буенча торак алучылар яисә ятим балалар һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә, опекада (попечительлектә) яисә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балалар өчен оешмалардагы ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар милекчеләре булган торак урыннарыннан файдалануны һәм саклауга кагылышлы планлы тикшерүләр үткәргәндә, Тәртипнең 2.11 пунктында каралган чараларны үтәүне тәэмин итәргә;

– ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренә шәхси счетларны бүлү һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен балигъ булмаганнарның бурычы күләмен киметү өчен суд карары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне билгеләү турында дәгъва гаризалары әзерләүдә ярдәм күрсәтергә.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнары эшен мониторинглау нәтиҗәләре буенча, без, опека һәм попечительлек органнары тарафыннан ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренең әлеге балаларны исемлеккә кертү турында гаризаларны үз вакытында тапшыруын контрольдә тотуның регламентлы механизмы булмавын билгеләп үттек.

Хәзерге вакытта опека һәм попечительлек органнары ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү процессында катнашмыйлар, шуңа күрә ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренең исемлеккә кертү турында гариза белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүләре, шулай ук аларның вәкаләтле органга керүләре очрагында әлеге гаризаларны карау нәтиҗәләре турында мәгълүматлары юк.

Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торакка хокукларын бозуга юл куймау

максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итүне максатчан дип саныйбыз:

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнары арасында мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибен, соңгыларның Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына әлеге муниципаль берәмлекләрдә яшәүче ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренең гаризалар белән мөрәҗәгать итүләре турында мәгълүмат алуын тәэмин итү өчен балигъ булмаганнар исемлегенә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле балаларны кертү, шулай ук әлеге гаризаларны карау нәтиҗәләре турында хәбәрләр алуын тәэмин итү тәртибен эшләргә;

– хокукый агарту максатларында опека һәм попечительлек органнары вазыйфаи затлары һәм ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре белән ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын яклау һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча укыту семинарлары үткәрергә.

Ятим балалардан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалардан, шулай ук аларның законлы вәкилләреннән килгән мөрәҗәгатьләрне анализлауны дәвам итеп, Вәкаләтле вәкил шуны билгели, 2023 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан әлеге категория гражданнарның хокукларын бозу очраклары ачыкланды.

2023 елның августында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ятим баланы исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карары белән риза булмау турында Лениногорск шәһәрендә яшәүче гражданка Г. – ятим баланың законлы вәкиленең мөрәҗәгате ачык мисал булып тора. Вәкаләтле орган карарының күчермәсеннән күренгәнчә, опекунныкы булган торакта яшәү мөмкинлеге булмау факты ачыкланмаганлыктан ятим баланы исемлеккә кертүдән баш тартканнар.

Шул ук вакытта, «Опека һәм попечительлек турында» 24.04.2008 елгы 48-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсенә ярашлы рәвештә, тәрбияләнүчеләрнең опекуннар яки попечительләр милкенә милек хокукы юк, ә опекуннар яки попечительләрнең тәрбияләнүчеләрнең милкенә милек хокукы юк.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Вәкаләтле вәкил соравы буенча тәкъдим ителгән документларда мөрәҗәгать авторының исемлеккә кертелүенә комачаулаучы башка нигезләр булу турында мәгълүмат булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Вәкаләтле вәкил ятим баланы исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карарны гамәлдән чыгару, мөрәҗәгать авторының гаризасын кабат карау турында тәкъдимнәр җибәрде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы аларны карап, исемлеккә кертмәү турындагы карарны юкка чыгарды, кабат карау нәтиҗәсендә балигъ булмаган баланы исемлеккә кертү турында карар кабул ителде.

Ачыкланган хокук бозуларны анализлаудан чыгып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 11 мартындагы 369/20 номерлы боерыгы белән расланган, махсуслаштырылган торак фондыннан торак биналар белән тәэмин ителергә тиешле 23 яшькә җиткән ятимнәр категориясенә кергән затларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентының 2.8 пунктында каралган нигезләр булганда гына исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул итәргә киңәш итәбез.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил торак йорт сатып алу өчен торак субсидиясе алу хокукына бәйле торак хокукларын бозуларны ачыклады.

2023 елның августында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшәүче гражданка В. Вәкаләтле вәкилгә торак сертификаты рәвешендә торак субсидиясе алу өчен кирәкмәгән документлар таләп итүгә кагылышлы шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Гариза бирүче тәкъдим иткән документлардан мөрәҗәгать авторының ерак төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирлекләрдән чыгып киткән һәм торак бина сатып алу өчен торак субсидиясе алу хокукына ия булган гражданнар категориясенә каравы күренә.

Үз чиратында, гаиләнең барлык әгъзаларына торак урыны алу өчен дәүләт торак сертификатын рәсмиләштерү өчен, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының җавабыннан күренгәнчә, мөрәҗәгать итүченең улының ерак төньяк районнарында аның белән бергә китүен расларга кирәк булган.

Шул ук вакытта әлеге социаль яклау чарасын алу өчен гариза бирүчеләр тарафыннан бирелә торган документлар исемлегендә ерак төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирлекләрдән мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының бергәләп китүен раслый торган документлар кирәклеге турында таләп юк.

Гамәлдәге законнар нормаларына ярашлы рәвештә, гаилә әгъзалары белән ерак төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирлекләрдә бергә яшәүне раслау өчен, социаль ярдәм чарасы күрсәтүгә дәгъва кылучы гражданнар вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүченең ерак төньяк районнарында һәм аларга тиңләштерелгән җирлекләрдә даими яшәүне раслаучы соңгы яшәү урыныннан йорт китабыннан (фатир карточкасыннан күчермә) өземтә бирәләр. Үз чиратында, гариза бирүченең тормыш иптәше яки хатыны, балалары, ата-аналары, уллыкка алучылары белән бергә яшәвен раслаучы башка документлар, шуңа күрә әлеге документларны гаиләнең әлеге әгъзаларына тапшыру таләп ителми.

Мөрәҗәгать итүчегә социаль ярдәм чарасын алу өчен артык таләпләр куелу сәбәпле, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы адресына мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу фактларын бетерү өчен мөмкин булган һәм кирәкле чаралар күрү турында тәкъдимнәр җибәрелде, алар ведомство тарафыннан исәпкә алынды.

Баян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына гражданнарның торак урыны алу өчен торак субсидиясе бирү турындагы гаризаларын караганда, күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын алу тәртибен һәм нигезләрен регламентлаштыручы норматив хокукый актларда каралмаган артык таләпләрне билгеләү очракларын булдырмаска тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыруның бер аспекты булып, гражданнарның сәламәтлеген һәм тормышын саклау максатыннан торак биналарның билгеле бер таләпләргә туры килүен тәэмин итү тора. Вакыт узу белән торак биналар эксплуатациядән узлекләрен югалтырга мөмкин, бу яшәү уңайлылыгы дәрәҗәсен киметүгә генә түгел, ә анда яшәүче гражданнарның сәламәтлеген һәм кайвакыт, тормышын да куркыныч астына куя.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, әлеге докладны язганда Татарстан Республикасында 154 күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган. 2023 елда гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы программа кысаларында 30 күпфатирлы йорттан кешеләр күчерелде (мәгълүматлар 2023 елның 21 декабренә).

2022 ел йомгаклары буенча еллык докладында Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына һәм торакны, торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану буенча ведомствоара комиссияләргә, бина хуҗасының, хокук иясенең яки гражданның (торак алучының) гаризаларын караганда (кабул иткәндә), гамәлдәге законнар белән регламентланган, аларны карау өчен өстәмә таләп кую фактларын булдырмау һәм гаризаларны карау вакытын үтәү өлешендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.01.2006 елгы 47 нче карары белән расланган торакны, торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәдә каралган гаризаларны карау таләпләрен үтәүне тәкъдим итте.

Вәкаләтле вәкил узган ел гражданнарның имин яшәү шартларына хокукларын яклауга контрольлек итү эшен дәвам итте.

Мәсәлән, 2023 елның гыйнварында Алабуга шәһәрендә яшәүче гражданка җирле үзидарә органы тарафыннан күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, дип тану тәртибен бозу мәсьәләсе буенча Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органы мөрәҗәгатькә биргән җаваплардан күренгәнчә, күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану турындагы гаризаны караудан баш тарту өчен нигез булып, торак биналарны алып торучыларның һәм милекчеләренең коллектив гаризасы, шулай ук торак йортның барлык милекчеләренең йортны авария хәлендә дип тануга ризалык бирүче беркетмәнең булмавы тора.

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган торак бинаны, торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәнең 42 пункты нигезендә, күпфатирлы йортны яшәү өчен яраксыз, авария хәлендә һәм сүтелергә яки төзекләндерелергә тиеш дип тануны бәяләү һәм тикшерү өчен күрсәтелгән күпфатирлы йорттагы торак милекчесенең берсенең гаризасы җитә.

Җирле үзидарә органы эшчәнлегендә торак законнары нормаларын бозуларны ачыклау һәм мөрәҗәгать итүчегә үз хокукларын гамәлгә ашырганда таләпләрне арттыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына кисәтүләр, шулай ук әлеге күпфатирлы йорт милкендә булган җирле үзидарә органына күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында ведомствоара комиссиягә гариза бирү тәкъдиме җибәрелде.

Безнең кисәтүләрне һәм килеп туган хәлне хәл итү буенча тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствоара комиссиягә гариза белән мөрәҗәгать итте, аны карау нәтиҗәләре буенча күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле, дип танылды.

2023 елның августында әлеге мөрәҗәгать авторы Вәкаләтле вәкилгә, күпфатирлы йорт авария хәлендә, сүтелергә тиешле дип танылу сәбәпле, аны социаль наем килешүе буенча торак белән тәэмин итүне сорап мөрәҗәгать итте.

Күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану турындагы муниципаль актны анализлау күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган торак бинаны, торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәнең 49 пунктында билгеләнгән таләпләр бозылган, җирле үзидарә карарында авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йорттан физик һәм юридик затларның күчерелү вакыты турында мәгълүмат юк.

Ачыкланган хокук бозуларны бетерү максатыннан Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органы җитәкчесе адресына муниципаль актны гамәлдәге законнар нормаларына туры китерү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрде.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органы Вәкаләтле вәкил тәкъдимнәрен үтәү йөзеннән муниципаль актка авария хәлендәге дип танылган күпфатирлы йорттан күчеп китү вакытын билгеләүче үзгәрешләр кертте. Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Торак кодексының 85 маддәсе нигезендә мөрәҗәгать авторына тәкъдим ителә торган фатир санитар-техник таләпләргә туры килмәү сәбәпле, Вәкаләтле вәкил Алабуга шәһәре прокуратурасына прокурор чараларын күрү мәсьәләсен карау өчен мөрәҗәгать итте.

Безнең дәлилләрне карап чыгып, Алабуга шәһәр прокуратурасы җирле үзидарә органы җитәкчесе адресына тәкъдимнәр бирде.

Күпфатирлы йортларны авария хәлендә дип тану мәсьәләләрен караганда җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының эшендә хокук бозулар күп тапкыр ачыклануга бәйле рәвештә. Вәкаләтле вәкил ачыкланган кимчелекләрне алга таба кабатламас өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башкарма органнары җитәкчеләренә хатлар җибәрде.

Гражданнарның торак хокукларын гамәлгә ашыруның мөһим өлеше булып гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсе тора.

2023 елда Вәкаләтле вәкил адресына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гражданнарның хокукларын тәэмин итү мәсьәләләре буенча 331 мөрәҗәгать килде.

«Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү» сервисы мәгълүматларын анализлау, (анда гражданнар торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләргә биш баллы шкала буенча бәя бирә ала), торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге проблемаларның безнең республика халкы өчен актуаль булып калуын күрсәтте, моның турында әлеге юнәлеш буенча 124 меңнән артык сыйфат бәяләмәсе уртача 3,86 балл белән шаһитлык бирә. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын түбәнәйтүнең төп сәбәпләре булып, «Йортны тиешенчә тотмау (чисталык)» – 26% (32 526 бәя), «Йортны ремонтлау» – 21% (26 607 бәя), «Коммуналь хезмәтләр күрсәтү» – 18% (22 120 бәя) һәм «Йорт белән идарә итү» – 18% (21 815 бәя) тора.

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гражданнарның торак хокукларын яклау торышы, шул исәптән контроль (күзәтчелек) дәүләт органнары, шулай ук җәмәгатьчелек торак контролен гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча бәяләнә.

2023 елның 19 декабренә Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе тарафыннан контроль чаралар нәтиҗәләре буенча торак законнары таләпләрен бозуга юл куймау турында 1694 кисәтү һәм 464 күрсәтмә бирелгән, шулай ук административ җаваплылык турында 293 беркетмә төзелгән.

Гражданнар күтәргән мәсьәләләрнең актуальлеге прокуратура органнарының күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре белән раслана. Татарстан Республикасы Прокуратурасы мәгълүматларына караганда, 2023 елның 11 аенда торак-коммуналь хуҗалык тармагында 3 567 закон бозу очрагы ачыкланган, аларны бетерү өчен 38 протест белдерелгән, 1867 күрсәтмә һәм 579 закон таләпләрен бозуга юл куймау турында кисәтү кертелгән.

Үз чиратында, җәмәгатьчелек торак контроле кысаларында «Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» берлеге 2023 елда торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә 1466 мөрәҗәгать карады, аларның күбесе торак законнары нормаларына аңлатмалар бирү (650 мөрәҗәгать), торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүне исәпләү тәртибен бозу (350), коммуналь хезмәтләрне сыйфатсыз күрсәтү (98), бина милекчеләренең гомуми җыелышларын үткәргәндә хокук бозулар, күпфатирлы йортларда (95) һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешенчә тотмау (85) мәсьәләләренә кагылды. Мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча түләүне исәпләгәндә һәм торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә торак законнары нормаларын бозу фактлары ачыкланды.

2023 елда әлеге өлкәдә проблемалы мәсьәләләрне хәл итү буенча күзәтчелек органнары белән уртак системалы эшне тәэмин итү өчен Вәкаләтле вәкил идарәчеләр вәкилләрен һәм мөрәҗәгать итүчеләрне чакырып эш киңәшмәләре үткәрде.

Мәсәлән, 2023 елның февралендә Вәкаләтле вәкил Казан шәһәрендә яшәүче гражданка А.ның торак бинада һава температурасы түбән булу сәбәпле канәгатьләнерлек булмаган яшәү шартлары турында мөрәҗәгате буенча эшлекле киңәшмә үткәрде.

Киңәшмә барышында «Уютный дом Групп идарәче компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан мөрәҗәгать авторының торак бинасында җылыту һәм вентиляция системасын урынга чыгып тикшерү, шулай ук күпфатирлы йорт фасадын җылыту буенча эшләр үткәрү турында карар кабул ителде.

Киңәшмә беркетмәсен үтәү өчен идарәче оешма фасадны җылыту буенча эшләр башкарды, шуның нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүче безгә рәхмәт белдерде.

2023 елның май аенда күпфатирлы йортта җылылык белән тәэмин итү системасының төзексезлеге мәсьәләсе буенча Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе, Казан шәһәре Идел буе районы прокуратурасы, «УютСервис Групп» ҖЧҖ вәкилләрен һәм мөрәҗәгать итүчеләрне чакырып эшлекле киңәшмә оештырылды.

Очрашу нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил тәкъдимнәрен үтәп, булган кимчелекләр бетерелде.

Узган ел дәвамында Вәкаләтле вәкил күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләренә зур игътибар бирде.

Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау программасы тузган торакны бетерү һәм торак йортларны эксплуатацияләү срогын озайту, уңайлы һәм куркынычсыз яшәү шартлары булдыру буенча бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән. 2023 елда, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, 730 күпфатирлы йортта капиталь ремонт үткәрелгән.

Хисап чорында әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкилгә 14 граждан мөрәҗәгать итте. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауны оештыруда һәм үткәрүдә проблемалы мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнар шулай ук «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына мөрәҗәгать иттеләр, анда 2023 елда әлеге тематика буенча 118 хәбәрнамә урнаштырылган иде. Гражданнар хәбәрләрен анализлау нәтиҗәләре күрсәткәнчә, белдерүләрнең 75%тан артыгы күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь төзекләндерү кысаларында эшләрнең сыйфатсыз башкарылуына кагыла. Кайбер очракларда гражданнарның уңайлы торакка хокукларын яклау максатыннан Вәкаләтле вәкилгә дә катнашырга туры килде.

Мәсәлән, 2023 елның сентябрендә Вәкаләтле вәкилгә Алабуга шәһәрендә яшәүче гражданка А. дәлилләрен раслаучы фотоматериаллар кушып, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау кысаларында эшләрнең сыйфатсыз башкарылуы турында мөрәҗәгать җибәрде.

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе тарафыннан Вәкаләтле вәкил инициативасы буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать авторының дәлилләре расланды, подрядчы оешма тарафыннан барлык кимчелекләр дә юкка чыгарылды.

Тагын бер мисал – Бөгелмә шәһәрендә яшәүче гражданка Ф. ның 2021 елда капиталь ремонт кысаларында күпфатирлы йортның фасадын ремонтлау буенча сыйфатсыз эшләүләре турындагы мөрәҗәгате.

Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү максатыннан Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә һәм «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы фонды» на эшләрне башкарганда хокук бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрү үтенече белән мөрәҗәгать итте.

Бергәләп эшләү нәтиҗәсендә мөрәҗәгать авторының дәлилләре расланды, подрядчы оешма тарафыннан, ачыкланган бозуларны бетерү буенча эшләр 2024 елның июленә кадәр планлаштырылган. Мөрәҗәгать безнең контрольдә кала.

Әлеге мөрәҗәгатьләр күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне оештыру буенча төбәк операторының хезмәт күрсәтү сыйфатын тиешенчә контрольдә тотуын һәм (яисә) җәлеп ителгән подрядчы оешмаларның, шул исәптән гарантия срогы чорында да, эшләрне башкаруын тормышка ашыру зарурлыгын күрсәтә. Шуның белән берргә, күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәргәндә хокук бозуларны бетерү буенча күрелә торган чараларның оперативлыгын һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итү максатыннан, дәүләт органнарына контроль (күзәтчелек) функцияләрен гамәлгә ашыру кысаларында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Капиталь ремонт» төре буенча урнаштырылган гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча чаралар күрүне һәм кабул итүне тәэмин итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил адресына идарәче һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору һәм чикләү тәртибе һәм шартлары турындагы закон таләпләрен бозуы турындагы мәгълүматны үз эченә алган күпсанлы мөрәҗәгатьләр килде, алар кайбер очракларда расланды.

Мәсәлән, 2023 елның июнендә Казан шәһәрендә яшәүче гражданка Ф. бурычы аркасында үз фатирында электр утын сүндерү белән риза булмау турында мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгатьне карау барышында без, «электр белән тәэмин итү» хезмәте өчен мөрәҗәгать авторының бурычы коммуналь хезмәт өчен түләүнең ике айлык күләменнән артмавына игътибар иттек.

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 06.05.2011ел елгы 354 нче карары белән расланган, күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 117 нче пункты нигезендә, коммуналь хезмәтләр күрсәтүче кулланучы коммуналь хезмәтләр өчен тулысынча түләү булмаганда, бу хакта кулланучыга алдан хәбәр итеп, коммуналь хезмәт күрсәтүне чикли яки бөтенләй туктата.

Шушы уңайдан Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә хат җибәрде, тикшерү нәтиҗәләре безнең дәлилләрне раслады.

Күзәтчелек органы тарафыннан «УК Приволжанин» ҖЧҖ идарәче оешмасына карата административ хокук бозу эше буенча беркетмә төзелде, шулай ук хокук бозуларны бетерү һәм коммуналь хезмәт күрсәтүне яңадан башлау турында күрсәтмә бирелде.

Тагын бер мисал булып, Түбән Кама шәһәрендә яшәүче гражданка Б.ның «ПЖКХ 17» идарәче компаниясе ҖЧҖнең торак бинада электр энергиясен законсыз сүндерүе турындагы мөрәҗәгате хезмәт итә.

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе тарафыннан Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатеннән соң үткәрелгән документаль тикшерү нәтиҗәләре буенча, «электр белән тәэмин итү» хезмәте өчен мөрәҗәгать авторының бурычы коммуналь хезмәт өчен ике айлык түләү күләменнән артмаганлыгы ачыкланган, шуңа бәйле рәвештә коммуналь хезмәтне туктату өчен нигезләр булмаган.

Күзәтчелек органы тарафыннан ачыкланган бозулар буенча идарәче оешма административ җаваплылыкка тартылган, шулай ук вәкаләтле орган тарафыннан кертелгән кисәтүне үтәү өчен мөрәҗәгать авторының фатирында электр белән тәэмин итү торгызылган.

Идарәчеләр һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешма тарафыннан гражданнарның хокуклары бозылуга юл куймау максатыннан, коммуналь хезмәтләр күрсәтүне чикләгәндә, Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда әлеге проблемага зур игътибар бирергә тәкъдим итүне максатка ярашлы, дип саныйбыз.

Гражданнарның торак хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге проблемаларының социаль әһәмиятен исәпкә алып, гражданнарның торак хокукларын яклауга һәм торгызуга юнәлдерелгән тәкъдимнәр дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнары, шулай ук идарәче һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан хупланыр, дип өметләнәбез.

4 НЧЕ БҮЛЕК. УҢАЙЛЫ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТКӘ ХОКУК

Татарстан Республикасы Конституциясе һәр гражданның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә, аның торышы турында ышанычлы мәгълүматка хокукын ныгыта. Күрсәтелгән конституцион хокук кешенең фундаменталь хокукларының берсе булып тора, ул аның тормыш эшчәнлеге нигезләренә кагыла.

Республика халкының иминлеге һәм уңайлы әйләнә-тирә мохит дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук әлеге хокукларны гамәлгә ашыру һәм яклау өчен кирәкле шартлар тудыручы иҗтимагый оешмалар эшенең өстенлекле юнәлешләре булып тора.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау ул – гражданнарыбызның тормыш сыйфаты да. Безгә әйләнә-тирә мохитне саклауга аеруча игътибарлы булырга кирәк», – дип билгеләп үтте Татарстан Республикасы Рәисе 2023 елның февралендә Росприроднадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсенең киңәйтелгән киңәшмәсе барышында.

Тулаем республикада табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыруның, әйләнә-тирә мохит компонентларының сыйфатын контрольдә тотуның, дәүләт экологик күзәтчелек һәм экологик агарту өлкәсендәге эшчәнлекнең нәтиҗәле механизмы булдырылган. Барлык проектлар, яңалыклар һәм үзгәрешләр фәнни җәмәгатьчелек белән килешү буенча һәм максималь ачыклык һәм гражданнар белән диалог вакытында гына кабул ителә. Экологик иминлек мәсьәләләренә игътибар республикабызда яшәүчеләрнең экологик тәрбия дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә.

Узган ел Татарстанда Самосырово микрорайонында 14,1 гектар мәйданда чүп полигонын рекультивацияләү мәсьәләсен хәл итү мөмкин булды, ул 2021 елдан «Экология» илкүләм проектының «Чиста ил» федераль программасы кысаларында дәвам итте. Проектны гамәлгә ашыруга 872,2 млн сум акча бүлеп бирелгән.

2019 елдан 2023 елга кадәр «Экология» илкүләм проекты кысаларында 1 125 табигать саклау чарасы үткәрелгән һәм 17,6 млрд сум җәлеп ителгән.

Табигатьне саклау чараларына карамастан, экология мәсьәләләре халкыбызны борчый. 2022 елның декабрендә Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырылган, халык арасында социологик сораштыру мәгълүматлары буенча, республикада яшәүчеләр экологик хәлне 5тән уртача 3,11 (шәһәрләрдә – 2,97, авылларда – 3,32) дип бәяли.

Гражданнар фикеренчә, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясыйлар:

сәнәгать предприятиеләре (68%),
кешеләр һәм халык (60%),
автомобильләр һәм транспорт (54%),
чүплекләр, чүп-чар, калдыклар (52%),
шулай ук авыл хуҗалыгы ашламалары (27%).

2023 елда Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан табигатьне саклау законнарын бозуның 3 680 очрагы ачыкланган, административ штрафларның түләтелгән суммасы 1,6 млн сум тәшкил иткән.

Теманың актуальлеге турында шулай ук, гражданнарның «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында басылган мөрәҗәгатьләре дә дәлилли.

Шуларның иң күбе гражданнарның мондый категорияләрдәге мөрәҗәгатьләре:

«Чүплекләр» – 766 хәбәрнамә,
«Һава» – 658 хәбәрнамә,
«Су» – 183 хәбәрнамә.

Мәгълүмат системасында санкцияләнмәгән чүплекләр проблемасы буенча иң күп мөрәҗәгатьләр Казан (347), Чаллы (51), Яшел Үзән (39), Лаеш (38), Тукай (33), Биектау (31) муниципаль районнары буенча бастырылган.

Гомумән алганда, экологик законнарны үтәү һәм санкцияләнмәгән чүплекләргә каршы көрәш мәсьәләләре хисап елы дәвамында муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында эшче киңәшмәләрдә фикер алышу предметы булды.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән берлектә эшләү нәтиҗәсендә Казан шәһәре, Әлмәт, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Биектау, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Лаеш, Лениногорск, Түбән Кама, Спас һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә санкцияләнмәгән чүплекләр бетерелде.

Мәсәлән, 2023 елның апрелендә Вәкаләтле вәкил адресына гражданин С. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Совет районы хакимияте тарафыннан Казан шәһәре Скрябин урамындагы санкцияләнмәгән чүплекне бетерү турында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына хәбәрнамәне карау буенча чаралар күрелмәве турында мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгатьне карау барышында Вәкаләтле вәкил тарафыннан хакимиятнең җаваплы башкаручылары тарафыннан, системада берничә тапкыр «Гариза хәл ителгән» статусы бирелгәнлеге, калдыкларны аларның туплану урынын тиешле хәлгә китермичә чыгару турында җаваплар белән чикләнгәнлеге ачыкланды. Шуңа бәйле рәвештә безгә район хакимияте башлыгы адресына Скрябин урамындагы калдыклар туплану урынын тиешле хәлгә китерү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрдек.

Төзелеш калдыкларының законсыз чүплеген бетерү мәсьәләсенең тагын бер уңай чишелеше – Казан шәһәренең Олы Дәрвишләр бистәсендә яшәүчеләрнең мөрәҗәгатен карау.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру максатыннан, безнең ярдәм белән Казан шәһәре Думасы карары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына 58 млн сум акча бүлеп бирелде. 2023 елның ноябренә законсыз чүплекне бетерү буенча эшләр тәмамланган.

2019 елдан башлап Казан шәһәренең Фурманов урамындагы күпфатирлы авария хәлендәге йортларны сүткәннән соң барлыкка килгән законсыз төзелеш калдыклары чүплекләрен бетерү мәсьәләләре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнарның хәбәр итүләре чишелешен тапмады.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, әлеге чүплекне бетерү һәм төзелеш калдыкларын утильләштерү өчен 4 млн сумга якын акча тапты.

Хисап елы дәвамында даими рәвештә социаль челтәрләр мониторингы үткәрелде. Гражданнарның интернет-ресурсларда урнаштырылган мөрәҗәгатьләре күбесенчә һаваның (424, 77,2%), сулыкларның (61, 11,1%) пычрануы һәм балыклар үлүе мәсьәләләренә кагылган.

Мәсәлән, социаль челтәрләрдә Чаллы шәһәре халкы төнлә яман ис турында хәбәр иткән, Минзәлә муниципаль районы халкы Коноваловка авылы янында яңа ферма ачылуга бәйле булган ачы ис һәм төтенгә игътибар иткән. Алабуга шәһәрендә яшәүчеләр кичке вакытта (ягъни «Алабуга» аерым икътисадый зонасы предприятиеләреннән) начар химик ис килү турында хәбәр иттеләр, ә Ютазы муниципаль районында яшәүчеләр Башкортстан Республикасы ягыннан килгән һавадагы ачы химик ис турында хәбәр иттеләр. Әлеге проблема нефть эшкәртүче Түбән Кама шәһәрендә яшәүчеләр өчен дә актуаль булган.

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына Казан шәһәренең төньяк өлешендә һәм Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Осиново бистәсендә яшәүчеләрдән атмосфераны пычрату мәсьәләләре буенча 300дән артык хәбәр килгән, аларга 1100 кеше теләктәшлек белдергән.

Мәгълүмат системаларында гражданнарның хәбәрләрен һәм мөрәҗәгатьләрен күзәтү нәтиҗәләре буенча ачыкланган проблемалы мәсьәләләр 2023 елның июлендә, рәисе Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил булган, Татарстан Республикасында «Регион белән идарә итү үзәге» проектын тормышка ашыру буенча Проект офисы утырышын үткәрүгә сәбәп булды.

Утырыш нәтиҗәләре буенча башкарма хакимиятнең федераль органнарына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, каты коммуналь калдыклар белән эшләүче төбәк операторларына гражданнарның экологик хокукларын яклауга юнәлтелгән тәкъдимнәр эшләнде.

Үз чиратында, табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсенә (Росприроднадзор) һәм Казан районара табигатьне саклау прокуратурасына «Казаноргсинтез» ААҖ, «Этилен үткәргечләр идарәсе – Түбән Кама Нефтехим» ҖЧҖ карата тикшерүләр үткәрергә һәм Казан шәһәренең төньяк өлешендә, Яшел Үзән муниципаль районының Осиново бистәсендә һәм Түбән Кама муниципаль районында һаваны пычрату сәбәбен ачыкларга кушылды.

Контроль-күзәтчелек органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр һәм ачыкланган бозулар нәтиҗәләре буенча аларны бетерү турында тәкъдимнәр бирелгән, аларның бер өлеше үтәлгән. Вәкаләтле вәкил аның үтәлешен 2024 елда да күзәтеп торачак.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрне үтәү максатыннан, 2023 елның октябрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты та-

рафыннан Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы адресына каты коммуналь калдыкларны коммерцияле исәпкә алу ысулын үзгәртү турында хат җибәрү инициативасы куелды (доклад язылган вакытта карала). Әлеге инициатива кабул ителгән очракта, каты калдыклар белән эш итү буенча хезмәт өчен түләүләрне, билгеләнгән чүп савытыннан чыгып исәпләү мөмкинлеге чыгарылачак, шул ук вакытта калдык чыгару конкрет саннан һәм савытлар күләменнән чыгып башкарыла.

Безнең тәкъдимнәр нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан каты көнкүреш калдыклары туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын актуальләштерү буенча эш алып барыла, ә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендәге законнарга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләнгән, бу калдыклар белән эш итү буенча вазгыятьне яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Гомумән алганда, 2023 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән белдерүләрне һәм «Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» кире элемтә платформасыннан хәбәрләрне мониторинглау нәтиҗәләре буенча, уңайлы әйләнә-тирә мохиткә гражданнарның хокукларын яклау максатларында, Вәкаләтле вәкил җаваплы башкаручылар адресына 30дан артык тәкъдим җибәрде.

Республика халкы хисап елында каты коммуналь калдыклар белән эш итү мәсьәләләре буенча да активлык күрсәтте. 2023 елда «Каты коммуналь калдыклар» юнәлеше буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына хәбәр итүләр саны 3 847 тәшкил итте, бу 2022 ел белән чагыштырганда 60%ка күбрәк (2 411 хәбәрнамә).

2023 елда без Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының каты көнкүреш калдыклар белән эш итү өлкәсендәге төбәк операторлары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре катнашында, төбәк операторлары эшчәнлеген карау буенча эш штабының 9 утырышында катнаштык, алар барышында аерым муниципаль берәмлекләр һәм шәһәр округлары территорияләреннән чүпне вакытында чыгармау буенча 130дан артык хәбәрнамә каралды.

2023 ел башында гражданнар мөрәҗәгатьләре статистикасы күрсәткәнчә, «ПЖКХ «ИК» ЖЧҖ төбәк операторы эшчәнлеге өлкәсенә караган муниципаль берәмлекләрдә каты көнкүреш калдыклары чыгару белән кискен проблема билгеләнгән: болар – Казан шәһәре, Яшел Үзән, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары. Әлеге төбәк операторының чүпне вакытында чыгармавы турында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына 2023 елның гыйнварында гына да 170 хәбәр килде.

Ярдәм күрсәтү максатыннан Вәкаләтле вәкил, 2023 елның гыйнварында Татарстан Республикасы Прокуроры адресына мөрәҗәгать итте. Хатны карау нәтиҗәсендә төбәк операторы административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.23 нче маддәсе (халыкны коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү нормативларын бозу) буенча җаваплылыкка тартылды.

Хисап елында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнарның күпсанлы мөрәҗәгатьләре каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәтү өчен түләүне законсыз исәпләү мәсьәләләре буенча килгән.

2023 елның июнендә килгән гражданин Ш. мөрәҗәгате буенча Вәкаләтле вәкил ярдәме белән Яшел Үзән муниципаль районының Бритвино авылында «ПЖКХ «ИК» ЖЧҖ төбәк операторы тарафыннан чүп өчен түләүне законсыз исәпләү турында Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (алга таба – идарә) тарафыннан тикшерү оештырылды. Нәтиҗәдә идарә тарафыннан гражданның дәлилләре законлы дип танылды. Төбәк операторына карата әлеге авылда яшәүчеләргә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 30 маена кадәр чүп чыгаруга түләүне тиешенчә куймаган өчен «Конкуренциягне яклау турында» 26.07.2006 елгы 135 нче федераль законның 10 нчы маддәсе 1 өлешендәге хокук бозулар билгеләре буенча административ эш кузгатылды.

2022 елның декабрь ахырында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Зимняя Горка авылында милек хокукында торак биналары булган гражданнар В.һәм Г.дан Вәкаләтле вәкил адресына «ПЖКХ «ИК» ЖЧҖ тарафыннан каты көнкүреш калдыклары чыгарган өчен артык түләнгән түләү күләме белән килешмәү турында мөрәҗәгатьләр килде.

Мөрәҗәгатьләрне карау барышында мөрәҗәгать итүчеләргә биш һәм ике кешене исәпкә алып, түләү исәпләнгәнлеге ачыкланды. Шул ук вакытта алар үзләренең торак биналарының бердәнбер хуҗалары булганнар, ә даими һәм вакытлыча яшәүче гражданнар аларның торак биналарында булмаган.

Безнең катнашудан соң, узган елның гыйнварында, төбәк операторы мөрәҗәгать итүчеләргә коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен артык исәпләнгән сумманы – 17 мең һәм 4 мең сумнан артык күләмдә яңадан исәпләп чыгарган.

Безнең республикада яшәүчеләрдән аерым шикаятьләр торак йортларда һәм фатирларда каты көнкүреш калдыкларын җыю белән эш итү буенча хезмәтләр өчен түләүне исәпләү мәсьәләсенә кагылды.

Вәкаләтле вәкил төбәк операторлары адресына әлеге мәсьәлә буенча безнең позициябезне белдергән хатлар җибәрде. Шуңа бәйле рәвештә, мондый торак биналарның милекчеләренә, шул исәптән пенсионерларга һәм аз тәэмин ителгән гражданнарга каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен түләүне туктату турындагы фикеребез уңай чагылыш табар, дип өметләнәбез.

Әлеге сегментта «Гринта» ЖЧҖ һәм «ПЖКХ» «ИК» ЖЧҖ төбәк операторларының тиешле гаризалар бирү нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен түләүне исәпләүне туктату турындагы карарын уңай билгеләп үтәргә мөмкин.

Шул ук вакытта, республиканың кайбер муниципаль берәмлекләрендә яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының барысы да төбәк операторларына тиешле гаризалар бирү кирәклеге турында мәгълүматка ия була алмавын билгеләп, Вәкаләтле вәкил республика муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре адресына муниципаль берәмлекләрдә теркәлгән махсус хәрби операциядә катнашучылар турында төбәк операторлары адресына мәгълүмат җибәрүне сорап мөрәҗәгать итте. Нәтиҗәдә, меңнән артык хәрбинең каты көнкүреш калдыкларын чыгару өчен тиешле түләүләре туктатылды.

Шуңа бәйле рәвештә җирле үзидарә органнарына әлеге өстенлек турында махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына мәгълүмат бирү буенча даими рәвештә эш алып барырга тәкъдим итәбез.

Үз чиратында, Вәкаләтле вәкил төбәк операторларының каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча җирле үзидарә органнары белән тыгыз хезмәттәшлеге бергәләп эшләвенә өмет белдерә, бу республикада яшәүчеләрнең мөрәҗәгатьләренә оператив җавап бирергә булышачак.

Тирә-як мохитне саклау өлкәсендә дәүләт өстенлекләренең берсе – суларны саклау һәм аларны пычраннан саклау.

Татарстан Республикасы Идел буе федераль округының иң күп сулы төбәкләренең берсе булып тора: республиканың барлык территориясенең 6,4 проценты су белән капланган: бу – 36 384 су объекты. Республикабызның яр буе сызыгының гомуми озынлыгы 42 мең км тәшкил итә.

2023 елда республикада яр буе линиясенең гомуми озынлыгы 734,22 км булган 39 су объектында су саклау зоналарын билгеләү буенча эшләр башкарылган.

«Иделне сәламәтләндерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2023 елда Куйбышев сусаклагычының су саклау зонасында урнашкан экологик зыянлы эре объектны бетерү буенча проектны гамәлгә ашыру дәвам итте – Казан шәһәренең Отар бистәсе янындагы, Идел елгасы буендагы 100 гектар тирәсе мәйданлы биологик чистарту корылмаларының ләм кырлары аның пычрану куркынычын тудыра. Проектны гамәлгә ашыру 2021 елда ук башланды, аны 2024 елда төгәлләү планлаштырыла.

Уртак мәдәни мирасыбызның бер өлеше булган су объектларын саклау максатларында, 2023 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына кергән «Су» категориясе буенча гражданнарның хәбәрнамәләренең вакытында һәм сыйфатлы үтәлешен контрольдә тоту буенча максатчан эш алып барылды.

Мәгълүмат системасында әлеге тематика буенча иң күп хәбәрнамәләр Казан (67), Биектау (15), Лаеш (12), Чаллы (11), Яшел Үзән (10) муниципаль районнары буенча бастырылган.

Гомумән алганда, әлеге категория буенча башкаручылар һәм модераторлар системадагы шикаятьләрнең үтәлешенә тиешле җавап биргәннәр. Шул ук вакытта хисап елында без проблемалы урыннарны, хәбәрнамәләрне карау срокларын озайту һәм аларны тиешенчә карамау фактларын ачыкладык.

Әйтик, Казан шәһәре Голубятников урамындагы Коры елга һәм күл акваториясен чистарту мәсьәләсе буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимиятенең җаваплы башкаручылары тарафыннан 2023 елның язында әлеге мәсьәләне хәл итү өчен акча булмау турындагы җавап урнаштырылган.

Мондый карар белән килешмичә, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына әлеге мәсьәләләрне хәл итү буенча оператив чаралар күрү турында мөрәҗәгать итте, һәм бер айдан да кимрәк вакыт эчендә сулыкларны чистарту буенча эшләр үтәлде.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына табигатьне саклау чараларын алдагы план чорына планлаштырганда һәм шул исәптән экологик түләүләрдән алынган акчаларга, шулай ук «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» кире элемтә платформасы һәм «Халык контроле» системасы аша республикабызда яшәүчеләрдән килгән мөрәҗәгатьләрне дә исәпкә алырга тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Хәбәрләрне мониторинглау барышында 2023 елның сентябрендә Чаллы шәһәрендә яшәүче, Николай Иванцов урамындагы сулыкның пычрануы турында хәбәр урнаштырылган, ул система кулланучыларыннан 28 комментарий һәм теләктәшлек алган. Безнең тәкъдимнәр белән бәйле рәвештә, Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан сулыкны пычратуда гаепле булган зат адресына мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү җибәрелде, аны карау нәтиҗәләре буенча сулык территориясен чүп-чардан чистарту һәм локаль чистарту корылмаларын ремонтлау эшләре башкарылды.

Хисап елында мөрәҗәгать итүчеләрнең уңайлы әйләнә-тирәлеккә хокукларны бозу турындагы дәлилләрен тикшерү максатларында, Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре контроль-күзәтчелек органнары һәм җирле үзидарә органнары актив катнашында күчмә тикшерүләрдә катнаштылар.

2023 елның июлендә табигатьне саклау законнарын бозу турындагы мәгълүматны тикшерү кысаларында, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы һәм Росприроднадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсе вәкилләре белән берлектә, Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районында Куйбышев сусаклагычының (Идел елгасы) яр буе полосасына урынга чыгып тикшерү үткәрелде. «Инновация» ЖЧҖ һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты адресына урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча Росприроднадзор идарәсе тарафыннан Россия Федерациясе Су кодексының 65 нче маддәсе таләпләрен бозуга юл куймау турында кисәтү кертелде. Бу мөрәҗәгать безнең контрольдә кала.

Кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукын гамәлгә ашыруда халыкны кирәкле күләмдә сыйфатлы эчәр су белән тәэмин итми мөмкин түгел.

2023 елда Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районында «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Чиста су» федераль программасы кысаларында бәясе 1 млрд сумга якын булган су алу үзәге белән су белән тәэмин итү системасы файдалануга тапшырылды. Шулай ук узган ел дәвамында Татарстан Республикасының Алексеевский муниципаль районында яңа су әзерләү станциясе файдалануга тапшырылды. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Суровка һәм Белоус авылларында су белән тәэмин итү челтәрләре төзелде.

Кабул ителгән чараларга карамастан, су белән тәэмин итү проблемалары республика халкын борчый. 2023 елның җәендә республикада һаваның югары температурасы торак пунктларда су белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгатьләр һәм гражданнарның хәбәрнамәләре санының артуына китергән (1 232 хәбәрнамә, 2 050 тапкыр татарстанлылар бу мәсьәлә белән «ГЛОНАСС+112» ЕГИС аша мөрәҗәгать иткәннәр). Бу тема буенча мөрәҗәгатьләрне хәл итүне Вәкаләтле вәкил даими күзәтеп тора.

2023 елның июлендә Вәкаләтле вәкилгә су булмау турында Бөгелмәдә яшәүче гражданин Г. мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгатьтән күренгәнчә, билгесез кешеләр су бүлү колонкаларын һәм су алу коеларын сүткәннән соң, Бөгелмә халкы эчәргә яраклы сусыз калган. Мөрәҗәгать бирүченең җирле үзидарә органы вазифаи затларына күп тапкыр мөрәҗәгать итүе бу мәсьәләне хәл итүгә китермәгән. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты Россия Эчке эшләр министрлыгының Бөгелмә районы бүлегенә гаепле затларны ачыклау һәм аларны җаваплылыкка тарту турында гариза белән мөрәҗәгать итте. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәләре буенча су белән тәэмин итү объектлары эше торгызылган.

Узган ел дәвамында әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү мәсьәләләрен хәл итү җирле үзидарә органнары белән берлектә эшләү нәтиҗәсендә мөмкин булды.

Хисап елында җирле үзидарә органнары җитәкчеләре адресына су булмау проблемаларын хәл итүгә һәм торак пунктларны су белән тәэмин итүдә өзеклекләр булдырмауга кагылышлы 20дән артык тәкъдимнәр бирелде.

Әйтик, 2023 елның октябрендә «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарның хәбәрнамәләрен мониторинглау вакытында без Казан шәһәрендә яшәүче гражданин М.ның Гагарин урамындагы үзәк суүткәргечнең сафтан чыгуы проблемасы буенча мөрәҗәгатен ачыкладык, нәтиҗәдә күрсәтелгән урамдагы йортларда суның аз басымы аркасында су җылыту һәм җылыту приборлары эшләмәде.

Мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, коммуналь хезмәтләр хезмәткәрләре 40тан артык торак йортка кагылган авария нәтиҗәләрен бетерү срокларын озайта.

Вәкаләтле вәкилнең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына, өч көн эчендә су белән һәм җылылык белән тәэмин итү системасының өзлексез эшләвен тәэмин итү буенча кичекмәстән эшләр башкару турындагы мөрәҗәгатеннән соң, су белән тәэмин итү челтәрләрендәге өзеклек бетерелде.

5 НЧЕ БҮЛЕК. МӘҖБҮРИ ТОТУ УРЫННАРЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

5.1. ҖИНАЯТЬ-БАШКАРУ СИСТЕМАСЫ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Хисап елында пенитенциар система учреждениеләре эшчәнлеген контрольдә тоту субъекты буларак, Вәкаләтле вәкил җинаять кылуда шикләнелүчеләрнең һәм гаепләнүчеләрнең, сак астына алынган, хөкем ителгән, ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә яки мәҗбүри эш рәвешендә җәза үтәүче, җинаять эше тәртибендә медицина характерындагы мәҗбүри чаралар кулланылган гражданнарның хокукларын үтәүне контрольдә тоту эшен дәвам итте.

Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2023 елның 1 декабренә булган мәгълүматларына караганда, махсус контингентның гомуми саны 17 137 кеше тәшкил итә, шуларның 4 678е – төзәтү учреждениеләрендә, 2 235е – тикшерү изоляторларында тотыла.

Чикләүләрнең зур масштаблары бу урыннарда булган кешеләрнең хокукларын тәэмин итүнең аерата актуальлеген билгели.

2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына шикләнелүчеләрнең, гаепләнүчеләрнең һәм хөкем ителүчеләрнең хокукларын яклау мәсьәләләре буенча 410 мөрәҗәгать керде.

Җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә кеше хокуклары бозылуга карата безгә килгән шикаятьләр ел саен кимеми һәм барлык мөрәҗәгатьләрнең 10% ка кадәрге өлешен тәшкил итә.

Мөрәҗәгатьләр алдан тикшерү, тикшерү һәм суд органнары тарафыннан гражданнарның хокукларын үтәү мәсьәләләренә кагылган. Тикшерү һәм тикшерү органнарының гамәлләренә һәм карарларына карата шикаятьләрдә тикшерүнең объективлыгы һәм тулылыгы, судка кадәрге стадиядә булган срокларны үтәү, гаепләнүче буларак кулга алынуның нигезлелеге, сак астына алу һәм башкалар проблемасы күтәрелә.

Безгә җинаять процессында катнашучылардан килгән шикаятьләрне прокуратура һәм тикшерү органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә карадык.

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, прокуратура органнары, Россия Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре белән берлектә, проблемалы участокларны ачыклау һәм гражданнар белән актив хезмәттәшлек итү максатларында, хөкем ителгәннәрне видео-конференц-элемтә режимында хокукый ярдәм көннәре кысаларында кабул итү эшен дәвам иттек.

Хөкем ителгәннәрне, хокукый ярдәм көннәре кысаларында, Нотариаль, Адвокатлар палаталары, Россия Федерациясе Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү, социаль яклау министрлыгы вәкилләрен җәлеп итеп, төзәтү учреждениеләренә чыгып кабул итү эше яңартылды.

Хокукый ярдәм көннәре кысаларында 161 тоткынны җәлеп итеп, барлыгы 10 уртак кабул итү үткәрелде.

Хисап елында җәмәгатьчелек ярдәмчеләренең төзәтү учреждениеләре комиссияләре эшендә җәза чараларын куллану мәсьәләләрен, шулай ук хөкем ителгәннәрне шартлы рәвештә вакытыннан алда җәзаны үтәүдән азат итү, җәзаның үтәлмәгән өлешен җәзаның йомшаграк төре белән алыштыру, төзәтү учреждениесе төрен үзгәртү турындагы үтенечләрен карау буенча катнашу практикасы кертелде.

Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе комиссия эшендә дүрт тапкыр өч төзәтү учреждениесендә (Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2 нче, 10 нчы, 19 нчы төзәтү колонияләре) катнашты. Квартал саен җәмәгатьчелек ярдәмчесе Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә үткәрелә торган туры телефон элемтәләре эшендә катнашты.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләрен тикшерү максатыннан һәм планлы тикшерүләр үткәрү кысаларында, Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан турыдан-туры һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә, 6 төзәтү учреждениесе, 2 тикшерү изоляторы, 1 төзәтү үзәге, җинаять-башкару системасы төзәтү үзәге режимында эшләүче 1 участок, төзәтү үзәгендәге 7 участокны тикшерү максатыннан 16 урынга бару оештырылды.

Гражданнар еш кына канәгатьләнерлек булмаган шартлардан (азык-төлек, эчәр су, кайнар су, гигиена чаралары, биналарның җитәрлек җылләтелмәвенә кагылышлы), аларга карата суд тарафыннан сайланган сак чарасы белән килешмәүгә һәм учреждениеләр персоналының гамәлләренә зарланалар.

Традицион рәвештә күп санлы мөрәҗәгатьләр җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә медицина тәэмин ителеше мәсьәләләре, шулай ук әлеге учреждениеләрдә тоту шартларына шикаятьләр белән бәйле. Узган елдагы кебек үк, җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә медицина тәэмин ителеше мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең шактый зур төркемен тәшкил итә.

Әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкил адресына барлыгы 65 мөрәҗәгать килгән.

Мөрәҗәгать бирүчеләр дәвалау тактикасы, инвалидлык төркемен билгеләү, аларны кирәкле дару препаратлары белән тәэмин итмәү белән килешмәүләрен белдерделәр, шулай ук даруларны бирмәүләрен белдерделәр, ведомстводан тыш сәламәтлек саклау учреждениеләрендә өстәмә тикшерү һәм дәвалану узуда, махсуслаштырылган медицина ярдәме алуда һәм тар профильле белгечләргә консультация алуда ярдәм күрсәтүне сорадылар.

Хөкем ителгәннәрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау – Россия Федерациясе җинаять-башкару законнарының бер бурычы, әлеге категория кешеләрдән безгә килә торган мәсьәләләрне без, прокуратура органнары, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең 16 нчы номерлы «Медик-санитар часть» учреждениесе белән тыгыз хезмәттәшлектә, шул исәптән пенитенциар учреждениеләргә чыгып хәл иттек.

Мөрәҗәгать итүчеләр мәсьәләсендә үз позициябезне белдереп, Без Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең 16 нчы номерлы «Медик-санитар часть»ка, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Прокуратурасына һәм төзәтү учреждениеләрендә законнарның үтәлешен күзәтү буенча прокурорга мөрәҗәгать иттек. Мәсьәләнең мөһимлеген исәпкә алып, мондый мөрәҗәгатьләрне тулысынча хәл ителгәнче контрольгә алабыз.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең 16 нчы «Медик-санитар часть» белгечләрен җәлеп итеп, мөрәҗәгатьләрне тикшерү барышында дәвалауның дөрес булмаган тактикасы турында шикаятьләр буенча хокук бозулар ачыкланмады.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкилне Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең СИЗО-5 учреждениесендә да тотылган затларның туганнарыннан килгән, учреждение администрациясе тарафыннан посылкаларда җибәрелгән һәм тапшырылган медикаментлар алудан баш тарту мәсьәләләренә кагылышлы дәгъвалар борчый.

Җинаять-башкару законнары нигезендә, беренче яки икенче төркем инвалид булган авыру хөкем ителгәннәр, хөкем ителгәннәр, әлеге посылкаларны Россия Федерациясе Җинаять-башкару кодексында билгеләнгән посылкалар һәм тапшырулар санына кертмичә, медицина нәтиҗәсе нигезендә билгеләнә торган санда һәм ассортиментта өстәмә посылкалар һәм тапшырулар итеп ала ала. Дарулар һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән посылкалар мәҗбүри тикшерү процедурасына дучар ителә.

Әлеге посылкалар тиешле авыруларны дәвалау өчен учреждениенең медицина частенә җибәрелә, учреждениенең медицина оешмасында саклана һәм медицина оешмасының дәвалаучы табибы (фельдшеры) тарафыннан расланган медицина күрсәтмәләре булганда авыруларга бирелә.

Шундый ук нигезләмәләр җинаять-башкару системасының тикшерү изоляторларында булган кешеләргә карата кулланыла.

Посылкаларда җибәрелгән һәм тапшырылган даруларны алуга кагылышлы гамәлдәге законнарны анализлаганда, без аның медицина өлешендә аналоглары булуы турында һәм тапшырылган (җибәрелгән) билгеләнү белән бәйле рәвештә медицина персоналына дәгъва юк, дигән мәҗбүри билге белән авыруларга туганнары җибәргән (тапшырган) конкрет препаратларны кабул итүгә гариза язу мәҗбүрилеген күрмибез.

Гамәлдәге закон нигезләмәләрен исәпкә алып, без Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы адресына әлеге мәсьәлә буенча үз позициябезне бәян итеп хат җибәрдек.

Хәзерге дөньяда аерым кешенең тормышына һәм сәламәтлегенә бөтен җәмгыять өчен куркыныч авырулар белән берррәттән, наркотикларны системалы куллану аркасында барлыкка килгән һәм алардан психик һәм физик бәйлелектә чагылган наркомания дә куркыныч тудыра.

Дәүләт үз чиратында наркомания белән авыручыларга наркологик ярдәм күрсәтүне һәм социаль реабилитацияне гарантияли.

Гомуми эшкә җәмәгать оешмаларының төзәтү колонияләрендә җәзасын үтәүче һәм төрмәдән азат ителгән, психик наркотикларга бәйлелеккә эләккән гражданнарга ярдәм итүгә юнәлдерелгән проектларны үстерү буенча мөһим хезмәте үз өлешен кертә.

2023 елда берничә иҗтимагый оешмалар белән бергә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең 16 нчы номерлы «Медик-санитар часть» учреждениесе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 19 нчы төзәтү колониясендә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 2 нче төзәтү колониясендә, Вәкаләтле вәкил белән хезмәттәшлектә, республиканың төзәтү учреждениеләрендә махсус төзелгән «реабилитация отрядлары» базасында психоактив матдәләргә бәйле булган хөкем ителгәннәрне психокоррекцияләү проектын гамәлгә ашыру дәвам итә.

Хисап елы нәтиҗәләре буенча әлеге төзәтү учреждениеләре тоткыннары белән төзелгән «реабилитация отрядларында» 768 кече психотерапия төркеме, 192 лекция, 96 тренинг һәм 1440тан артык шәхси консультация үткәрелгән. 100 хөкем ителгән кеше «отрядларда» реабилитация программасын үтә. Хисап елы ахырына 100 дән артык кеше реабилитация яки реабилитациядән соң курслар узган.

Тикшерү изоляторы тулу сәбәпле, камерада бер кешегә туры килгән санитар мәйданның күләмен үтәмәү, Вәкаләтле вәкилгә адресланган мөрәҗәгатьләрдәге сорауларның бер өлеше шуңа бәйле.

Бу хәлнең бер сәбәбе – алдан тикшерү алып баруның, шулай ук җинаять эшләрен судларда карауның озакка сузылуы.

Шулай итеп, хисап елының октябрендә Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең СИЗО-2 нче изоляторында кеше саны тиешледән артуына шикаять белән гражданка Б. мөрәҗәгат итте.

Безнең инициатива буенча Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм прокуратура органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү уздырылды.

Ул шикаять бирүче тотылган хатын-кызлар бүлеге камерасында ремонт белән бәйле рәвештә башка камерадан кешеләр күчерү сәбәпле, лимит санын арттыру фактын раслады. Шуңа бәйле рәвештә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгына федераль закон таләпләрен бозуны бетерү турында тәкъдимнәр кертелде.

Якын киләчәктә әлеге проблеманы хәл итүгә «Җинаять-башкару системасын үстерү (2018–2030 еллар)» федераль максатчан программасын тормышка ашыру ярдәм итәр, дип уйлыйбыз.

Татарстан Республикасы җинаять-башкару системасының тикшерү изоляторларының югары үткәрү сәләте тотылган махсус контингентның иминлегенә дә битараф карарга мөмкинлек бирми.

Әйтик, 2023 елның сентябрендә гражданин Х.ның тоту шартларының тиешенчә булмавы турында дәлилләрен карау максатларында, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Чистай шәһәрендә урнашкан «Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 5 нче тикшерү изоляторы» федераль казна учреждениесендә булдылар.

Сәфәр барышында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 04.07.2022 елгы 110 нчы боерыгы белән расланган, җинаять-башкару системасының тикшерү изоляторларының эчке тәртибе кагыйдәләренең 30 пункты нигезендә тиешле таләпләргә туры килүне тәэмин итү өчен 56 нчы камерадагы изоляцияләнгән санитар узелның махсус контингентның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсыз булмаган җиһазлары фактлары билгеләнде.

Душ бүлмәләрен сайлап тикшергәндә, аларда калайдан өлешчә сүтелгән түшәм, шулай ук стенадагы зарарланган тышлык – махсус контингентның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч, дип билгеләнгән. Шулай ук билгеләп үтелгәнчә, учреждениенең икенче корпусының аерым душ бүлмәләрендәге стеналар һәм идән косметик ремонт үткәрүне таләп итә.

Безнең мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан, ачыкланган кимчелекләр бетерелде һәм учреждениенең режимлы корпусларының душ һәм камера биналарында ремонт эшләре үткәрү өчен кирәкле акчаларга исәп-хисап ясалды (2024 елга планлаштырылган финанслау кысаларында).

Соңыннан югарыда күрсәтелгән мәсьәлә буенча Вәкаләтле вәкил «Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 5 нче тикшерү изоляторы»нда тиешенчә тотылмау шартларына гражданин Х.ның административ дәгъвасы буенча кызыксынган зат буларак җәлеп ителде.

Омбудсменнарның Азия Ассоциациясе составына Азиянең 26 иленнән 46 әгъза керә. Мәсәлән: Пакьстан, Азәрбайҗан, Кытай, Япония, Малайзия, Индонезия, Россия (Татарстан Республикасы, Дагыстан Республикасы), Көньяк Корея, Таиланд, Һиндстан, Шри-Ланка, Вьетнам, Үзбәкстан, Ямән, Кыргыз Республикасы, Көнчыгыш Тимор, Әрмәнстан, Грузия, Казахстан. Казахстанны Ассоциация составына кертү турында карар нәкъ менә Татарстанда Ассоциациянең соңгы утырышында кабул ителде. Монда ук Ассоциациянең Директорлар советы составына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайлау турында карар кабул ителде (Директорлар советына Төркия, Кытай, Япония, Иран, Көньяк Корея, Пакьстан, Азәрбайҗан, Татарстан (Россия) кебек илләрдән 9 омбудсмен керә).

2023 елның 4–5 ноябрендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Дубай шәһәрендә Европа омбудсменнар институты оештырган халыкара конференциядә катнашты. Конференция Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең дискриминациядән саклանудагы роленә, дини хокукларга аерым игътибарына багышланган иде. Чарада Болгария, Германия, Джибути, Кипр, Россия, Сербия, Төркия, Швейцария омбудсменнары катнашты. Россия делегациясен Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова, Дагыстан, Ингушетия, Кабарда-Балкар, Татарстан, Свердловск һәм Ярославль өлкәләрендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр тәкъдим итте.

Татарстан омбудсменына этник һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү өлкәсендә Татарстан Республикасы тәҗрибәсе турында доклад өчен сүз бирелде. Коллегаларга дәүләт максатчан программалары турында; эшчәнлеге милләтара һәм мәдәниятара диалогка юнәлтелгән оешмалар турында (аерым алганда, Татарстан халыклары Ассамблеясы турында); дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек турында, шул исәптән гыйбадәт объектларын торгызу турында; хакимият һәм дини берләшмәләр диалогын гамәлгә ашыру өчен республикада төрле мәйданчыкларның эшчәнлеге турында, шул исәптән, 2023 елда республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында уздырыла торган чаралар турында мәгълүмат җиткерелде. Татарстан Республикасының җәмгыятьтә толерантлы мөнәсәбәтләр формалаштыру, милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм татулык урнаштыру тәҗрибәсе хезмәттәшләрне бик кызыксындырды.

Конференциядә барлык катнашучыларны республика җитәкчелегенең күпмилләтле Татарстан халкының тарихи-мәдәни мирасына булган игътибары гаҗәпләндерде.

Хисап елында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил шулай ук башка мөһим халыкара һәм төбәкара чараларда катнашты. Болар:

11 гыйнвар – «Цифрлаштыру һәм кеше хокуклары: Гомуми тенденцияләр һәм төбәк тәҗрибәсе» темасына чыгыш ясап, Төркиядә (Әнкара шәһәре) «21 гасырда кеше хокукларының киләчәге» халыкара конференциясендә катнашу;

4 июль – Түбән Новгород шәһәрендә «БМОның качаклар эшләре буенча Югары комиссары идарәсе эшчәнлеге, качаклар һәм күчерелгән кешеләр белән эшләү принциплары һәм стандартлары» семинарында катнашу;

28 август – II Казан Глобаль яшьләр саммитында катнашып, яшьләрнең тормышына һәм абруена багышланган сессия барышында чыгыш ясау;

7 сентябрь – «РостКИ: Россия һәм Кытай үзара файдалы хезмәттәшлеге» халыкара форумы кысаларында «Намуслы бизнес: ришвәтләргә юк» секциясендә катнашу һәм чыгыш ясау;

28 сентябрь – II Казан халыкара юридик форумында катнашу һәм «Челтәрдә көч куллану: яңа чакырулар һәм квалификация проблемалары» дигән фәнни-гамәли дискуссиядә чыгыш ясау;

18 октябрь – Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан оештырылган «Кеше хокукларын яклау проблемалары: Омбудсменнарның иң яхшы практикалары белән алмашу» VII Халыкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашу;

26 октябрь – Мәскәү шәһәрендә «Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә хокукларны яклауга һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән комплекслы социаль яклауның һәм реабилитация ярдәменең заманча алымнары» төбәкара конференциясендә катнашу.

Коллегалар – Вәкаләтле вәкилләр белән уртак эш, шулай ук Россия Федерациясе Идел буе федераль округы субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация советы, Бөтенроссия Координация советы утырышлары форматында алып барылды, коллегалар оештырган чараларда катнаштык. Мәсәлән, 2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Санкт-Петербургта Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләренә багышланган Бөтенроссия Координация советы утырышында, шулай ук Мәскәүдә яшьләр хокукларына багышланган утырышта катнашты. Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация советы утырышы видеоконференция форматында 2023 елның май аенда узды.

Халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтын ныгытуда, коллега-омбудсменнар белән элемтәләрне киңәйтүдә, шулай ук кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау буенча уртак эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыруда һичшиксез зур роль уйный.

7 НЧЕ БҮЛЕК. ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ГРАЖДАННАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ ӨЛКӘСЕНДӘ ЗАКОН ЧЫГАРУ ҺӘМ ХОКУК КУЛЛАНУ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ КАТНАШУЫ ТУРЫНДА

2023 елда Вәкаләтле вәкил законнарны камилләштерүдә традицион форматларда катнашуын дәвам итте.

Эш дәверендә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон проектлары эшләүче Законлылык һәм хокук тәртибе, Социаль сәясәт комитетлары белән тыгыз хезмәттәшлек итә, депутатлар белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләүне, шул исәптән җибәрелгән закон проектлары буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр әзерләүне дә гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелгәнче үк кайбер актуаль мәсьәләләр буенча хокукый карарларга үз карашын Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышларында белдерде. Комитетның 17 утырышында катнашты, аларда 82 мәсьәлә, 14 контроль мәсьәлә каралды, 74 карар һәм 9 заключение кабул ителде.

Аерым закон проектлары һәм кеше хокукларын яклау проблемаларына кагылышлы кайбер контроль мәсьәләләр буенча үз позициясен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышларында катнашканда белдерде. Комитетның 13 утырышында (шул исәптән күчмә) 40 мәсьәлә каралды, шул исәптән, 10 контроль һәм 15 Татарстан Республикасы законнары проектларына кагылышлы.

Аппарат хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты каршындагы эксперт советлары составына керә.

Торак-коммуналь хуҗалык, инфраструктура үсеше, мәгариф өлкәсендәге мәсьәләләрнең социаль әһәмиятенә бәйле рәвештә, аеруча гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын яклау өлешендә, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, 2024 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше, Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте, Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитетлар утырышларында катнашу, шулай ук әлеге комитетлар каршындагы эксперт советлары составына Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләрен кертү буенча тәкъдимнәр кертте.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон проектларына «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.8 нче маддәсенә һәм «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына; Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына – 828560-7 нче «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» федераль законның 18 нче маддәсенә үзгәреш кертү хакында»; «Россия Федерациясендә хәрби бурычлыларның һәм хәрби хезмәткәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 211189-8 федераль закон проектына карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына; Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарәләр комитетына – «Татарстан Республикасының аерым законы актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына; «Россия Федерациясендә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында һәм Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 299053-8 нче федераль закон проектына – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына – 5 нәтиҗә җибәрелде; «Ветераннар турында» федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектына – Чувашстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары закон проектларына нәтиҗәләр җибәрелде.

Шул ук вакытта гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү – төп мәгълүмат чыганагы, аннан Вәкаләтле вәкил гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен норматив җайга салуда булган проблемалар турында белә. Аларның анализы хокук яклау законнарын камилләштерү инициативасын формалаштырырга һәм чыгыш ясарга мөмкинлек бирә.

Гражданнарның килгән мөрәҗәгатьләрен өйрәнү һәм анализлау нәтиҗәләре буенча, законнарның һәм башка норматив хокукый актларның гамәлдә булуына мониторинг үткәрү, федераль законнарны үзгәртү һәм тулыландыру буенча тәкъдимнәр федераль омбудсмен адресына, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы комитетларына һәм турыдан-туры Дәүләт Думасы депутатларына җибәрелде.

2023 елда балаларны аларның сәламәтлегенә, әхлакый һәм рухи үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан, пропагандадан, агитациядән яклау кирәклеге мәсьәләсе үсеш ала.

Сәүдә челтәрләрендә киң таралу алу һәм һәр бала өчен төрле агрессив персонажлар уенчыклары, компьютер һәм башка көч куллану күренешләре белән бәйле уеннар булу сәбәпле, гражданнарның борчылуларын исәпкә алып, 2022 елның декабрендә үк баланың тормыш иминлеген, сәламәтлеген, әхлагын саклау, аны тискәре йогынтыдан саклау максатыннан, федераль омбудсмен адресына «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләрендә каралган санитар, башка экспертизалар (социаль, психологик, педагогик) үткәрү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил тарафыннан «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы федераль законның әлеге нормасын үтәү һәм үтәүне контрольдә тоту механизмының булмавына игътибар ителде.

Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан безнең тәкъдимнәр өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән эшләнде, шул исәптән медицина һәм мәгариф өлкәсендәге галимнәрне җәлеп итеп.

«О.Е. Кутафин исемендәге Мәскәү дәүләт юридик университеты»ның Кеше хокуклары буенча фәнни белем бирү үзәгенең уңай нәтиҗәсе алынган, анда балалар уенчыкларына социаль – психологик-педагогик экспертиза кертү балаларның иминлеге турында дәүләт кайгыртуының вакытында һәм кирәкле чарасы булып тора, әмма аны алып бару әлеге экспертиза төре өчен теоретик нигезләр эшләнгәннән соң мөмкин, диелә.

Әлеге мәсьәләнең мөһимлеген исәпкә алып, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, узган ел, Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисенә, Евразия икътисадый комиссиясе Советы рәисе адресына «Уенчыклар куркынычсызлыгы турында» 23.09.2011 елгы 798 нче таможня берлегенең Техник регламентына без билгеләгән үзгәрешләрне кертү мөмкинлеген карау үтенече белән хатлар җибәрде.

Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның хокукларын яклау өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча эш дәвам итә.

Россия Федерациясе Президентының 26.02.2013 елгы 175 нче «Инвалид балаларны һәм I төркем инвалид балаларны караучы затларга айлык түләүләр турында»гы Указына ярашлы рәвештә, эшләмәүче ата-анага (уллыкка алучыга) яки опекунга (попечительгә) 10 000 сум күләмендә, башка затларга 1 200 сум күләмендә айлык түләүләр билгеләнгән.

Шул ук вакытта закон буенча, әгәр I төркем инвалид яки инвалид баланың ата-анасы яки опекуны рәсми рәвештә эшкә урнаштырылган булса, ул күрсәтелгән түләүне ала алмый.

Пособие күләме барлыкка килгән барлык чыгымнарны каплау өчен җитәрлек түгеллеген исәпкә алып, шул ук вакытта дистанцион хезмәт актив үсеш алган шартларда, инвалидның ата-анасы яки опекуны дистанцион рәвештә

берничә сәгать эшләргә һәм бер үк вакытта кайгыртуны гамәлгә ашырырга мөмкин, 2023 елның июлендә инвалидның ата-анасы яки опекуны тулы булмаган эш вакыты шартларында яки өйдә эшләп, инвалид баланы карауны дәвам иткән очракта, инвалидның ата-анасына яки опекунына айлык түләүләргә хокукын беркетүне сорап, шулай ук I төркем инвалидларга, дәвалау учреждениесе нәтиҗәсе буенча даими карауга мохтаҗ булган өлкәннәргә, яисә 80 яшькә җиткәннәргә айлык компенсация түләү күләмен арттыру һәм индексацияләүне дәвам итүне сорап (хәзерге вакытта 10 000 һәм 1200 сум 2008 елдан бирле үзгәрми), Вәкаләтле вәкил Дәүләт Думасының гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе адресына тәкъдимнәр җибәрде.

2023 елның сентябрендә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының безнең адреска тапшырылган мәгълүматларына ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 февралендәге 175 нче Указына үзгәрешләр кертү турында «Инвалид балаларны һәм I төркем балачактан инвалидларны карауны гамәлгә ашыручы затларга айлык түләүләр турында» Указы проекты әзерләнде, анда 1 төркем балачактан инвалидларны һәм инвалид балаларны караучы ата-анага (уллыкка алучыга) яки опекунга (попечительгә) бераз эшләгән очракта, айлык түләүләрен сакларга мөмкинлек бирүче нормалар билгеләнгән.

2023 елның 1 декабрендә Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 26 февралендәге 175 нче Указына үзгәрешләр кертү турында «Инвалид балаларны һәм I төркем балачактан инвалидларны карауны гамәлгә ашыручы затларга айлык түләүләр турында» Россия Президентының 912 нче Указы кабул ителде.

Шул ук вакытта I төркем инвалидларга, дәвалау учреждениесе нәтиҗәсе буенча даими карауга мохтаҗ булган яки 80 яшькә җиткән өлкәннәргә айлык компенсация түләү күләмен арттыру һәм индексацияләү турындагы икенче мәсьәләне карау өчен, гадәттәге яшәү шартларында тулы күләмдә карауны тәэмин итү максатыннан, агымдагы елның октябрендә Вәкаләтле вәкил Дәүләт Думасының гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе адресына кабат мөрәҗәгать итте.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Россия Федерациясе Президентының 2023 елны федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә Педагоглар һәм остазлар елы дип игълан итүенә бәйле рәвештә, узган ел җәмгыятьтә укытучы статусын ныгытуга юнәлдерелгән масштаблы чаралар үткәрелде.

Мәсәлән, республикада Казан (Идел буе) федераль университеты территориясендә «Белем» мәгариф музее булдырылган, «Татарстан мәгарифе: 100 ел төзү һәм үстерү» истәлек китабы басылып чыккан, укытучылар скверы ачылачак һәм укытучыга һәйкәл куелачак.

Шул ук вакытта бүгенге көн чынбарлыгы педагогик хезмәткәрләрнең даими һөнәри үсешен, талантлы яшьләрне белем бирү өлкәсенә җәлеп итүне таләп итә, бу укытучы һөнәренең социаль җәлеп итүчәнлеген арттырмыйча һич мөмкин түгел.

Татарстанда 2023 елда 77,3 мең педагог үз эшчәнлеген башкарган (өстәмә һәм мәктәпкәчә белем бирү бүлекчәләре педагогларын исәпкә алып), шулардан:
36,6 мең – гомуми белем бирү оешмалары педагогы,
4,7 мең – урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәре һәм 7,1 мең – югары белем бирү оешмалары укытучылары.

2023 елның 3 кварталында республикада гомуми белем бирү өлкәсендә педагогларның уртача хезмәт хакы артты һәм 43 800 сум тәшкил итте, бу Россия Федерациясе Президентының 2012 елгы Указы белән билгеләнгән күрсәткечләргә туры килә.

Үз чиратында, Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан Россия Федерациясе төбәкләрендә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр турында мәгълүмат анализланды.

Педагогик хезмәткәрләрнең төп хокуклары һәм ирекләре, аларны гамәлгә ашыру гарантияләре 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон белән беркетелгән. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» әлеге федераль Законның 47 нче маддәсендәге 5 өлешендәге 6 пунктта педагогик хезмәткәрләрнең торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә тору, аларга махсуслаштырылган торак фонды торак урыннары бирү хокукы беркетелгән.

Әмма Россия Федерациясенең Торак кодексында педагогик хезмәткәрләргә социаль наем шартнамәләре буенча чираттан тыш торак урыннары бирү турында нигезләмәләр юк.

Моннан тыш, нинди дәүләт яки муниципаль торак фондларыннан, нинди субъектлардан һәм нинди тәртиптә торак урыннары бирелүен билгеләүче норматив нигезләмәләр беркетелмәгән.

Әлеге шартларны исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил федераль омбудсмен адресына закон чыгару инициативасы хокукы булган субъектларга мондый тәртипне билгеләүче норматив нигезләмәләр эшләү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итүне сорап тәкъдим җибәрде.

Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы рәисенә шундый ук тәкъдим белән мөрәҗәгать итү мәсьәләсен карау үтенече белән, Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе адресына мөрәҗәгать итте. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Вәкаләтле вәкил тәкъдимен хуплады: Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы Рәисе адресына педагогик хезмәткәрләрнең социаль наем шартнамәләре буенча торак бирү хокукын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче закон актларын кабул итү мөмкинлеген карау турында тәкъдим җибәрелде.

Билгеләнгән теманы дәвам итеп, узган ел без, 2022 елның сентябреннән Россиянең 45 төбәгендә Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда кертелгән вазыйфаны – җәмгыятьтә тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе статусын ныгытуга юнәлдерелгән эшне анализладык.

Бу вазыйфа педагогик хезмәткәрләр категориясенә карый. 978 мәктәптә тәрбия буенча директор киңәшчесе штат вазыйфасы кертелә.

Хезмәт килешүе нигезендә тәрбия буенча директор киңәшчеләре белем бирү оешмасында һәм аннан читтә тәрбия эшен оештырып, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның төрле социаль институтлар (профилактика советлары, сыйныф җитәкчеләренең методик берләшмәләре, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, ата-аналар комитетлары) белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итеп, белем алучылар һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) белән индивидуаль эш алып баралар.

Шул ук вакытта әлеге вазыйфа «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» федераль законның 27 маддәсе нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 29 октябрендәге 781 номерлы карары белән расланган «Картлык буенча хезмәт пенсиясе вакытыннан алда билгеләнә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлеге турында»гы исемлектә һәм «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» федераль законның 27 нче маддәсенә ярашлы рәвештә картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукын бирә торган исемлектә каралмаган, бу «Россия Федерациясендә иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән белем бирү оешмаларында 25 елдан да ким булмаган педагогик стажы булганда картлык буенча тиешле иминият пенсиясенә хокукны кире кага.

Чынлыкта педагогик эшчәнлек алып барганда, тәрбия буенча директор киңәшчеләре «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы федераль закон белән каралган вакытыннан алда пенсиягә чыгуга үз хокукларын тормышка ашыра алмаячаклар, чөнки әлеге вазыйфа 781 номерлы карардагы исемлектә юк.

Билгеләнгән мәсьәләләрнең әһәмиятен исәпкә алып, без федераль омбудсмен адресына тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесен вазыйфалар исемлегенә кертү тәкъдиме белән закон чыгару субъектларына мөрәҗәгать итү мөмкинлеген карау үтенече белән тиешле тәкъдимнәр җибәрдек, бу, үз чиратында, билгеләнгән категория хезмәткәрләрнең вакытыннан алда пенсия белән тәэмин итүгә хокукын тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Кызганычка, безнең инициатива Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгында һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгында хуплау тапмады, шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе хезмәт һәм социаль яклау министры адресына кабат мөрәҗәгать җибәрде.

Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау практикасының конкрет мәсьәләләренә багышланган чараларда даими катнашуы, фикер алышу барышында гамәлдәге законнардагы җитешсезлекләрне һәм аны куллану практикасын, шулай ук аны үстерү буенча тиешле тәкъдимнәр кертү мөмкинлеген ачыклауга ярдәм итә.

Узган елның ноябрендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Бөтенроссия координация советында «Яшьләр хокукларын яклау» темасына Вәкаләтле вәкилнең чыгышы яшьләрнең белем алу хокукын гамәлгә ашыруга бәйле берничә мәсьәләгә багышланган иде.

Үз чыгышында билгеләп үткәнчә, уку чорында күбрәк студентлар эшкә урнашырга һәм хезмәт хакы алырга омтыла, шул ук вакытта 2022 елдан гамәлгә ашырыла торган «Профессионалитет» федераль проекты, Россия Федерациясенең 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеше инициативаларының берсе буларак, икътисадның реаль секторы предприятиеләре белән тыгыз партнерлыкта, урта һөнәри белем бирү белән идарә итүнең яңа системасын төзүгә юнәлдерелгән.

Үз чиратында, федераль норматив база тарафыннан, бүленгән контроль саннар кысаларында урта һөнәри белем бирү программалары буенча максатчан укыту өчен аерым квоталар буенча кабул итү билгеләнмәгән. Әлеге шартларны исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил тарафыннан мәгариф турында гамәлдәге законнарга тиешле үзгәрешләр кертү юлы белән урта һөнәри белем бирү программалары буенча максатчан укыту өчен аерым бәйге булдырырга тәкъдим ителде.

Яшьләрнең хезмәт эшчәнлеге темасын дәвам итеп, Координация советында Вәкаләтле вәкил, шулай ук инвалидлык буенча пенсия алучы яки туендыручысын югалткан студентларның хезмәт эшчәнлеге чорында пенсиягә өстәмә түләү хокукын саклау өлешендә законнарны камилләштерү мәсьәләләрен дә билгеләп үтте.

2022 елның апрелендә кабул ителгән «Дәүләт социаль ярдәме турында»гы федераль законның 12.1 маддәсенә үзгәреш кертү хакында» 16.04.2022 елгы 113-ФЗ федераль законы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда төп белем бирү программалары буенча көндезге уку формасында белем алучы инвалид балаларга пенсиягә өстәмә түләүне саклап калырга мөмкинлек бирде (әмма алар 23 яшькә җиткәнче генә), шулай ук 18 яшькә җиткән, туендыручысын югалту уңаеннан пенсия алучы һәм белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмаларда төп белем бирү программалары буенча көндез белем алучы балаларга (әмма алар 23 яшькә җиткәнче генә), аларның дәүләт мәшгульлек хезмәте юнәлеше буенча иҗтимагый эшләрдә (укудан буш вакытта) вакытлыча эшкә урнашу яки катнашу чорында.

Әмма өстәмә түләү студентлар көндезге уку формасында укыганда гына саклана.

Заман чынбарлыгын истә тотып, яшьләр актив рәвештә көндезге-читтән торып, читтән торып уку формаларын сайлаганда, шулай ук яшьләргә матди ярдәм күрсәтү максатларында, Вәкаләтле вәкил туендыручысын югалту уңаеннан пенсия алучы һәм белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларда төп белем бирү программалары буенча көндезге-читтән торып һәм читтән торып уку формалары буенча белем алучы студентларның «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендә чыккан федераль законга тиешле үзгәрешләр кертү юлы белән, хокукларын беркетергә тәкъдим ителде (алар 23 яшькә җиткәнче).

Вәкаләтле вәкилнең махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының хокукларын гарантияләүгә бәйле закон чыгару эшчәнлегендә катнашуы дәвам итә.

Хәбәрсез югалган яки әсирлеккә эләккән хәрбиләрнең гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтү буенча Вәкаләтле вәкилнең актив эше аларны кичекмәстән хәл итүне таләп итүче аерым проблемалы мәсьәләләрне ачыклады.

Мәсәлән, 27.05.1998 елгы 76-ФЗ номерлы «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында»гы федераль законның 2 нче маддәсенә ярашлы рәвештә, хәрби хезмәткәр әсирлеккә алынган очракта, шулай ук аның хәбәрсез югалуы очрагында, ул закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган яки һәлак булган, дип игълан ителгәнче, хәрби хезмәткәр статусы саклана.

Күрсәтелгән хәрбиләр өчен матди һәм башка төр чаралар саклана, алар әсирлеккә алу яки азат итү шартлары тулысынча ачыкланганчы яки алар закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган яки һәлак булган дип игълан ителгәнче, алар белән бергә яшәүче хәрбиләрнең хатыннарына яки гаиләләренең башка әгъзаларына түләнә (бирелә).

Хатынына яки гаиләнең башка әгъзаларына мондый түләүләр кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.07.2000 елгы 524 нче карары белән каралган.

Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау, кызганычка, аларны алуда кыенлыклар тууын күрсәтте.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына хәрбиләрнең әсирлектә булуы, хәбәрсез югалуы турындагы мәгълүматларны хәбәр итү срокларын, шулай ук акчалата түләүләрне билгеләү вакытын норматив-хокукый җайга салуда булышлык күрсәтү максатыннан, узган елның июнендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы комитетының гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре буенча «түгәрәк өстәл» утырышында, Вәкаләтле вәкил, тиешле норматив хокукый актны эшләү мәсьәләсен карарга тәкъдим итте.

Бу мәсьәлә буенча өстәмә рәвештә узган елның июлендә Вәкаләтле вәкил Дәүләт Думасының гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе һәм федераль омбудсмен адресына мөрәҗәгать итте.

Безнең мөрәҗәгатькә бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил адресына килгән мәгълүматка караганда, әлеге юнәлештә эш дәвам итә.

2022 елның ноябрендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына җибәрелгән, өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган затларның һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы затларның балаларына белем бирүдә өстенлекләр билгеләү турында Вәкаләтле вәкилнең тәкъдимнәре дә уңай чагылыш тапты.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» «федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июнендә чыккан 264-ФЗ федераль закон белән, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье һәм Херсон өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм аларның балаларының аерым квота чикләрендә, федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре хисабына бакалавриат программалары һәм белгечлек программалары буенча укырга хокукы билгеләнде.

Татарстан Республикасында 191 яшь кеше әлеге аерым квота кысаларында белем алу хокукын гамәлгә ашыра алды.

ЙОМГАК

Докладта әйтелгән проблемалардан чыгып, Вәкаләтле вәкил дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү, үтәү һәм яклау максатларында берничә чараны гамәлгә ашыру мөмкинлеген карарга тәкъдим итә.

1. Аерым категория гражданнарның торак хокукларын гамәлгә ашыру максатларында:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары арасында, әлеге муниципаль берәмлекләрдә яшәүче балигъ булмаганнарны наем шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлегенә кертү турында, ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренең гаризалар белән мөрәҗәгать итүләрен тәэмин итү өчен, шулай ук әлеге гаризаларны карау нәтиҗәләрен хәбәр итү өчен мәгълүмат алмашу хезмәттәшлеге тәртибен эшләргә;

– хокукый агарту максатларында опека һәм попечительлек органнары вазыйфаи затлары һәм ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре белән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын яклау һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча өйрәнү семинарлары үткәрергә;

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 11 мартында 369/20 нче боерыгы белән расланган, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм алар арасыннан 23 яшькә җиткән торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле затларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларны исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентының 2.8 пунктында каралган нигезләр булганда гына исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул итәргә.

Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә:

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендә чыккан 374 нче карары белән расланган, наем килешүләре буенча фатир алып торучылар яки аларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балалар булган торак биналарының тиешле санитар һәм техник торышын тәэмин итү, куллануга һәм саклауга контроль булдыру Тәртибенең 2.7.1 пунктында билгеләнгән аралык белән планлы тикшерүләр үткәрергә;

– социаль наем шартнамәләре буенча фатир алып торучылар яки аларның гаилә әгъзалары яки милекчеләре ятим балалар һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр, опекада (попечительлектә) яисә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләүчеләр булган торак урыннарыннан файдалануны һәм саклауны планлы тикшерүләр үткәргәндә, Тәртипнең 2.11 пунктында каралган чараларны үтәүне тәэмин итәргә;

– ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләренә шәхси счетларны бүлү һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен балигъ булмаганнарның бурычы күләмен киметү өчен, суд карары нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне билгеләү турында дәгъва гаризалары әзерләүдә ярдәм күрсәтергә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына:

– гражданнарның торак урыны алу өчен торак субсидиясе бирү турындагы гаризаларын караганда, күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын алу тәртибен һәм нигезләрен билгеләүче норматив хокукый актларда каралмаган артык таләпләрне билгеләү очракларын булдырмаска;

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясенә төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда идарәче һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмаларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату һәм чикләү тәртибе һәм шартлары турындагы закон таләпләрен бозу мәсьәләләренә зур игътибар бирергә.

2. Гражданнарның сәламәтлекне саклау хокукын үтәү максатыннан:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

– Татарстан Республикасының теге яки бу муниципаль районында бала тудыру йортларын (бүлекләрен) ябу турында карар кабул иткәндә муниципаль берәмлекләрдә халык саны арту һәм туучылар саны арту динамикасын, шулай ук әлеге муниципаль район халкының фикерен исәпкә алырга;

– квалификацияле һәм вакытында медицина ярдәме күрсәтү өчен ведомство карамагындагы медицина учреждениеләрендә кадрлар белән тәэмин ителешне анализларга һәм вакытында кадрлар мониторингы үткәрергә. Белгечләрне эзләү һәм эшкә кабул итү эшен, шул исәптән мәшгульлек хезмәте органнары белән закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә, шулай ук мәгълүматны медицина оешмаларының рәсми сайтларында һәм «Россия эше» порталында урнаштыру юлы белән оештырырга.

Муниципаль хакимият органнарына медицина кадрлары дефицитын киметүгә һәм табиблар һәм урта медицина хезмәткәрләре белән тулылануны арттыруга юнәлдерелгән медицина хезмәткәрләренә социаль ярдәм чараларын ныгыту мәсьәләсен карарга.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау учреждениеләренә гражданнарның сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау чаралары комплексын эшләү һәм медицина оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру белән бәйле үз шикаятьләрен һәм кисәтүләрен белдергән очракларга аерым игътибар бирергә. Медицина ярдәменең сыйфатын күтәрү, аның тиешле стандартларына ирешү сәламәтлек саклау идарәсе органнары эшчәнлегендә барлык дәрәҗәләрдә даими өстенлекле юнәлешләр булырга тиеш.

3. Балигъ булмаган балаларның мәгариф өлкәсендәге хокукларын үтәү максатыннан:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, торак фонды булган югары белем бирү оешмаларына билгеләнгән санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә тулай торак биналарын тиешле хәлдә тоту, анда яшәүче гражданнарның гигиена кагыйдәләрен үтәү буенча чараларны көчәйтергә, шулай ук яшәү өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар тудыру максатларында студентлар тулай торак биналарын агымдагы һәм капиталь ремонтлауны вакытында үткәрү буенча эшне дәвам итәргә.

4. Гражданнарның хезмәт хокукларын тормышка ашыру максатында:

Муниципаль районнарда яшәү дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча территориаль ведомствоара комиссияләргә, даими нигездә минималь хезмәт хакыннан һәм минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк хезмәт хакы түләүче эш бирүчеләрне утырышларда тыңлау эшен дәвам итәргә, аларны үтәү өчен конкрет тәкъдимнәр һәм сроклар эшләргә, ә үтәлмәгән очракта материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә кирәк.

Урыннарда хезмәтне саклау буенча координация советларына эш урыннарында куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү максатларында эш бирүчеләр катнашындагы һәр бәхетсезлек очрагын һәм һәр эпизод буенча адреслы чаралар күрүне предметлы карарга кирәк.

Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыкларына Татарстан Республикасы төзелеш мәйданчыкларында хезмәтне саклау нормаларын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә һәм төзелеш мәйданчыкларында җитештерү травматизмын булдырмауны контрольдә тотуны һәм профилактикалауны арттыру буенча тиешле чаралар үткәрүне оештырырга.

5. Инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнар хокукларын яклау максатыннан:

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә:

– реабилитация чаралары китерүгә дәүләт контрактлары төзү эшен оештыруны камилләштерү һәм реабилитациянең техник чараларын кирәкле сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен вакытында ачык сатулар үткәрергә;

– гражданнарның аерым ташламалы категорияләренә шифаханә-курорт дәвалануы күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүгә дәүләт контрактлары төзегәндә һәр очракта шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларны, ишетү һәм күрү сәләте бозылган, терәк-хәрәкәт аппараты чикләнгән затлар өчен гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, шифаханә-курорт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларның ачыклыгы дәрәҗәсе буенча тикшерүләр үткәрергә.

Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясенә:

үз эшчәнлеген оештырганда халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен шифаханә-курорт өлкәсе объектларына бару мәсьәләләренә игътибар итәргә;

Санатор-курорт хезмәтләре, санаторийларда яшәү хезмәтләре, медицина һәм башка хезмәтләр күрсәтүче оешмалар җитәкчеләренә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 30.12.2020 елгы 904/пр боерыгы белән расланган «СП 59.13330.2020. Кагыйдәләр җыентыгы. Биналар һәм корылмаларның халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен уңайлылыгы. СНиП 35-01-2001 кагыйдәләре»н исәпкә алып, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24.11.1995 елгы, 181-ФЗ федераль закон нигезләмәләре таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә;

«Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертиза Баш бюросы» учреждениесенә инвалидны тернәкләндерү һәм абилитацияләүнең индивидуаль программаларын эшләгәндә, Россия Хезмәт министрлыгының 26.06.2023 елгы 545н боерыгы белән расланган, медик-экспертиза федераль учреждениеләре бирә торган инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә аларны индивидуаль эшләүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарның яшь цензын киметү өлешендә йорт (фатир) буенча йөрүне оештыруны җайга салучы норматив актка үзгәрешләр кертү мөмкинлеген карарга, ә йорт (фатир) буенча йөргәндә өлкән яшьтәге гражданнарның сәламәтлек торышына, шулай ук яше буенча психик тайпылышлары булуга игътибар итәргә;

социаль мәсьәләләр буенча кураторлык итүче башкарма комитет җитәкчеләре урынбасарларына, район халкын социаль яклау һәм социаль тәэмин итү линиясе буенча тәэмин итү органнары эшчәнлеген оештырганда, ярдәмгә мохтаҗ өлкәннәргә карата адреслы карарлар кабул итеп, 80 яшьтәге һәм 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарны йорт буенча йөреп тикшерү нәтиҗәләренә аерым игътибар бирергә.

6. Гражданнарның әйләнә-тирә мохиткә хокукларын яклау максатыннан:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына табигатьне саклау чараларын планлаштырганда, алдагы план чорына «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» кире элемтә платформасы һәм «Халык контроле» аша республикабызда яшәүчеләрдән килгән хәбәрләрне исәпкә алырга.

Җирле үзидарә органнарына, даими нигездә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына «Гринта» ҖЧҖ һәм «ПЖКХ» ИК» ҖЧҖ төбәк операторларына каты көнкүреш калдыклары белән эш итү өчен түләүне исәпләүне туктату турында гаризалар бирү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү буенча эш алып барырга.

5. Гражданнарның кыска вакытлы мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын саклау һәм яклау максатларында,

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына махсус биналарны җыештыру буенча дәүләт контрактларында башкаручы үткәргән җыештыруны документаль теркәү кирәклеге турындагы нормалар белән пунктны чагылдырырга.

8. Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзаны үтәүче затларның хокукларын үтәү һәм яклау максатларында, төзәтү үзәге тарафыннан хөкем ителгәннәрне мәҗбүри эшләргә эшкә урнаштырырга әзерлеген белдергән оешмалар, мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәрнең хезмәтен куллану турында шартнамә төзегәндә, аларның Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында һәм Татарстан Республикасында яшәү минимумыннан ким булмаган күләмдә хезмәт хакы түләү турында Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координацион советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында әлеге чорда гамәлдә булган килешүгә кушылырга әзерлеген исәпкә алырга.

9. Республикада яшәүчеләрнең хокукый аң һәм белем дәрәҗәсен күтәрү максатларында:

– Татарстан Республикасы ачык хакимият органнарына, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы халкын хокукый агарту һәм түләүсез юридик ярдәм күрсәтү буенча Вәкаләтле вәкил белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә;

– гражданлык җәмгыяте институтларына һәм оешмаларына Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне, яклауны һәм торгызуны тәэмин итүгә юнәлдерелгән социаль мөһим проектларны гамәлгә ашыру буенча Вәкаләтле вәкил белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә;

«Бөтенроссия Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы сукырлар җәмгыяте» Бөтенроссия инвалидлар иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк оешмасына, «Бөтенроссия саңгыраулар җәмгыяте» Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан Республикасы бүлекчәсенә, «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан Республикасы оешмасына – Вәкаләтле вәкилнең сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен Хокукый белемнәр мәктәбе проектын тормышка ашыруда катнашырга;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Яшьләр эксперт советы, Татарстан халыклары ассамблеясының яшьләр бүлеге белән берлектә, чит ил студентлары белән, алар Россия Федерациясе территориясендә булганда хокуклары һәм бурычлары турында фикер алышу буенча очрашулар, «түгәрәк өстәл»ләр оештырырга, чит илләрнең генераль консуллыклары вәкилләрен чакырырга.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Россия Президенты Владимир Владимирович Путин игълан иткән 2024 елгы Гаилә елын исәпкә алып, гаиләләр белән эшне Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм башка кызыксынган ведомстволар белән берлектә яшьләр клублары һәм яшүсмерләр үзәкләре базасында, шул исәптән шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә яшь гаиләләр белән очрашулар оештыру, гаилә Хокукый ярдәм көннәре кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү, «түгәрәк өстәл»ләр, телефон «кайнар» элемтәләре һәм башка тематик чаралар үткәрү эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәгенә, 2023 елның май аенда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, кызыксынган министрлыклар һәм ведомстволар белән берлектә, «Гаилә һәм патриотизм: махсус хәрби операция чорында кеше хокукларын тәэмин итү ресурслары» Идел буе демография форумын оештырырга тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасында
Кеше хокуклары буенча
вәкаләтле вәкил
С.Х. Сабурская

САЛАНЫ ҮСТЕРӘСЕ

Лениногорск районында елга йомгак ясадылар

> 2

МАЛ ДА ГАЕПЛЕМЕ?

Хөкүмәт йортында табигатьне саклау турында сөйләштеләр

> 2

КЫЙММӘТЛЕ ТӘРТИП

Соңгы тугыз елда ишегалларын тәртипкә китерүгә 24 миллиард сум акча тотылган

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр биредә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 26 (29186) | Чәршәмбе | 28 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ: «РОССИЯНЕҢ ҮЗ ЮЛЫ БАР»

Татарстан үрнәге – ул нәрсә? Үсеш нигезе нәрсәгә корылырга тиеш? Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Россия Федерациясе Президенты вазыйфасына кандидат Владимир Путинның ышанычлы заты Минтимер ШӘЙМИЕВ «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат ӘМИНОВ белән әңгәмәсендә матди казанышлар һәм рухи байлык турында сөйләде. Әлеге әңгәмәне укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.

:: Хөрмәтле Минтимер Шәрипович! Россия Федерациясе һәм аның төбәкләренә каршы моңарчы күрелмәгән бихисап санкция кертелде. Әлеге шартларда республиканың социаль-икътисадый үсешен ничек бәяләр идегез?

– Россия икътисады әлеге санкцияләргә җайлашып кына калмыйча, чит ил товарларын алмаштыру механизмнарыннан файдаланып, яңа партнерлар табып, үсешкә ирешеп бара дияр идем. Татарстанның да уңышлары бар. Мәсәлән, 2023 елда төп капиталга инвестицияләр беренче тапкыр 1 триллион сумнан артып китте (үсеш – 111%). Мәгълүм ки, икътисад үсешен нәкъ менә инвестицияләр билгели.

Тулаем төбәк продукты күләме 4 триллион сумнан узды (үсеш – 103,6%). Ә бу исә республика үзенең социаль-икътисадый үсешенә: юллар, мәктәпләр, балалар бакчалары һәм башка социаль объектлар төзелешенә күбрәк акча бирә ала дигән сүз.

Юл төзелешенә килсәк, узган ел моңа 244 миллиард сум тирәсе акча тотылган. Узган ел ахырында без киң колачлы бер вакыйганы бөтен ил күләмендә билгеләп үттек: М12 югары тизлекле автомобиль юлы ачтык, бу юлда шулай ук Идел аркылы күпер дә төзелде. Бу, һичшиксез, Татарстан үсешенә, гомумән, Россия үсешенә зур этәргеч булачак, әлеге юлның киләчәктә Көнчыгышка таба дәвам итәчәген күздә тотсак, бигрәк тә.

Төзүчеләр өч ел рәттән рекордлы күләмдә: елга 3 миллион кв. метрдан артыграк торак төзеде.

Татарстан башка төбәкләр арасында күп кенә күрсәткечләр буенча алда бара. Без, әйтик, тулаем төбәк продукты күләме, сәнәгать җитештерүе, төп капиталга инвестицияләр, төзелеш, авыл хуҗалыгы һәм башкалар буенча иң яхшы ун төбәк исәбенә керәбез.

Республика илнең авыл хуҗалыгы җирләренең бары тик ике процентына гына ия булса да, үзен азык-төлекнең үзе җитештергән төп төрләре белән тулысынча тәэмин итеп тора. Татарстан – сөт җитештерү буенча Россия Федерациясендә беренче урында.

Республика әлеге казанышларга киң колачлы, илкүләм һәм инфраструктурага кагылышлы проектларны гамәлгә ашыруга федераль үзәкнең һәм Владимир Владимирович Путинның шәхсән ярдәме нәтиҗәсендә ирешә.

:: Минтимер Шәрипович, күптән түгел Россия Президентының федерация субъектларының муниципаль берәмлекләре башлыклары белән очрашуында, Владимир Владимирович, Чаллы шәһәре мэры белән сөйләшкәндә, Чаллы – чынлап та үзенчәлекле шәһәр һәм КАМАЗ да – үзенчәлекле предприятие, дип әйткән иде. Ул: «Беренче Президент Минтимер Шәрипович Шәймиев бик күп эшләде, без аның белән КАМАЗны коткаруга зур игътибар бирдек», – диде. Шул турыда сөйләсәгез иде.

– 2000 елның 21 мартында Владимир Владимирович Путин, ил Президенты вазыйфаларын башкаручы буларак, Татарстанга килде. Шул көнне үк ул Казанда Тузган торакны бетерү программасын гамәлгә ашыру барышы белән танышты, «Азино» микрорайонына барды, аннан соң Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү буенча дәүләт комиссиясе утырышында катнашты. Без аңа үзебезнең Ту-214 очкычын, «Аксай» һәм «Ансат» вертолетларын күрсәттек. Икенче көнне без аның белән Чаллыга киттек, КАМАЗда Бөтенроссия машина төзүчеләре киңәшмәсен үткәрдек. Анда әлеге тармак предприятиеләренең иң тәҗрибәле 200ләп җитәкчесе катнашты. Завод директорлары мәсьәләләрне бик белеп күтәрде. Мин шул вакытта Владимир Владимировичның тармак проблемаларын бик яхшы белүенә гаҗәпләнеп тә куйдым. Аның җаваплары вазгыятьне төгәл аңлавын дәлилләде, ул хәлиткеч үзенчәлекләрне тотып алып, аерып күрсәтә алды. Шунысы аңлашылды: аны КАМАЗның уңышлы үсеше бик кызыксындыра иде. 2000 елның мартында Президент итеп сайланган Путинның, ил башлыгы буларак иң беренче адымнарыннан берсе – Япония Хөкүмәтеннән КАМАЗда двигательләр җитештерү өчен күпмиллионлы кредит алуны тергезүгә шәхсән катнашуы булды. Двигательләр заводындагы янгыннан соң КАМАЗ моңа бик мохтаҗ иде.

2000 елның сентябрендә Россия делегациясе Путин җитәкчелегендә Япониягә барды. Делегациядә, Владимир Владимирович үтенече буенча, мин дә бар идем. КАМАЗ мәсьәләсе аның Япония Премьер-министры белән сөйләшү тәртибенә кертелде. Анда КАМАЗга җитештерү җиһазлары алыр өчен 200 миллионлык кредит турында шәхсән килешенде. Бу исә КАМАЗны – заманча йөк машиналары чыгара торган дөнья гигантын коткарып калды. Аңа йөк машиналары өчен двигательләр җитештерү буенча яңа баскычка күтәрелергә, Европа стандартына туры килә торган ЕВРО-2 моторлары эшләргә мөмкинлек бирде. ЕВРО-4 двигательләрен ясауны үзләштерү буенча эш башланды.

Ахыры 3 нче биттә >

Хәерле юл!

Татарстанда 2020 елдан бирле «Сыйфатлы һәм имин юллар» илкүләм проекты гамәлгә ашырылып килә. Аның кысасында Казан һәм Чаллыда «акыллы» светофорлар (юлдагы вазгыятькә карап, кызыл һәм яшел төсләрнең янып тору вакытын үзләре көйли), 213 видеокүзәтү камерасы урнаштырылган. Болар үлемгә китергән юл фаҗигаләре санын киметүгә ярдәм иткән. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзенең телеграм-каналында шул хакта язган.

«Соңгы елларда бу системалар ярдәмендә үлем белән тәмамланган юл-транспорт һәлакәтләре саны 58 процентка кимегән», – дип билгеләп үткән республика башлыгы.

Казан һәм Чаллыда «Акыллы транспорт системасы» гамәлгә кертелгәч, юл хәрәкәте белән идарә итү өчен диспетчерлык үзәге оештырылган, 78 светофор булдырылган яки яңартылган. Юлларга 15 метеостанция, 110 транспорт агымы детекторы (юлның ни дәрәҗәдә тулган булуы, билгеле бер вакыт аралыгында узган машиналар саны, аларның тизлеге турында мәгълүматлар җыя), 15 йөгерек мәгълүматлар таблосы (йөртүчеләр өчен файдалы мәгълүматлардан тора), шулай ук 200дән артыграк камера урнаштырылган.

Илкүләм проектны гамәлгә ашыру барышында Татарстанда һәлак булучылар саны 2019 елда 100 мең кешегә 9,45 күрсәткечен тәшкил итсә, 2023 елда – 6,97.

Бюллетеньнәр әзер

Идел буеның иң зур полиграфия оешмасы «Идел-пресс»та Россия Президенты сайлау өчен бюллетеньнәр бастыру эше төгәлләнде. Барлыгы 2,9 млн бюллетень бастырылган.

Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев әйтүенчә, бюллетеньнәрнең һәрберсенә яшел төстәге махсус саклагыч бастырыла. «Андый рәсем беркайда да юк, аны Татарстанда уйлап таптылар. Шулай ук бюллетеньнәрдә сайлау комиссиясе әгъзаларының имзалары һәм махсус голографик марка да булачак», – диде ул.

«Идел-пресс» полиграфия оешмасы генераль директоры Әнәс Әскәров әйтүенчә, бюллетень бастыру эше 5 тәүлек дәвам иткән. Барлыгы 120 тонна кәгазь, 200 кг буяу сарыф ителгән.

Мәгълүм булганча, быел Россия Президентын сайлау 15, 16 һәм 17 мартта узачак. Кандидатлар исемлегендә Владислав Даванков («Новые Люди»), Леонид Слуцкий (ЛДПР), Николай Харитонов (КПРФ) һәм үзен үзе тәкъдим иткән гамәлдәге дәүләт башлыгы Владимир Путин бар.

Койрыксыз бурыч

Махсус хәрби операциядә катнашучыларны куллану кредитлары буенча процент түләүдән азат итмәкчеләр. «Известия» хәбәренә караганда, Финанс министрлыгы әзерләгән әлеге тәкъдим Россия Хөкүмәтендә дә хупланган.

Кредит алган кеше законның гамәлгә кергән вакытта аның процент өлешен түләп бетергән булса, банк бу сумманы төп бурычны түләүгә юлларга тиеш булачак. Закон проектында банкларга процентлар буенча алынмыйча калган акчаны 50 процент күләмендә каплау күздә тотыла.

Яңалык

Март ае үзгәрешләре

ЯЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЕНДА НИНДИ ЗАКОННАР ҮЗ КӨЧЕНӘ КЕРӘ?

➤1 марттан күчемсез милек хуҗаларының шәхси мәгълүматларын саклау турында закон гамәлгә керә. Аның нигезендә, хәзер чит кешеләр бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан (ЕГРН) мөлкәт хуҗалары турында мәгълүмат ала алмаячак. Бу хокукка бары тик ир белән хатын, шулай ук кайбер дәүләт органнары хезмәткәрләре һәм нотариуслар гына ия булачак.

➤Электр самокатлары, гироскутер, сегвей, монокөпчәк кебек транспорт Юл хәрәкәте кагыйдәләренә кертелә. Аларда йөрүчеләргә тизлекне сәгатенә 25 чакрымнан арттыру рөхсәт ителмәячәк. Моннан тыш тротуарлардан, велосипедчы һәм җәяүлеләр юлларыннан йөреп булган транспортның авырлыгына чикләү кертелә: ул 35 килодан артмаска тиеш. Аның өчен махсус юл билгеләре урнаштырылачак.

➤Чүп чыгарган өчен түләүне яңадан исәпләү гамәлгә кертелә. Биш көн рәттән өеңдә яки фатирыңда яшәмәгән очракта чүп чыгарган өчен кимрәк түләү мөмкинлеге ачыла. Моның өчен өйдән чыгып киткәнче яки кайткач 30 көннән дә соңга калмыйча идарәче компаниягә гариза язып тапшырырга кирәк (туристлык юлламасы, самолет билеты кебек өйдә булмаганлыкны раслаган документлар белән).

➤Авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән кешеләргә таксида эшләү тыела. Биредә сүз үтерү, белә торып сәламәтлеккә авыр зыян салу, кеше урлау, талау, көчләү, шулай ук иҗтимагый иминлеккә, дәүләткә каршы статьялар буенча хөкем карары җәзасын үтәп бетермәгән кешеләр турында бара.

➤Коралга лицензия бирү кырыслана. Җинаять кылуда шикләнелүче яки гаепләнелүчеләргә, шулай ук эчке эшләр органнары уздырган тикшерү нәтиҗәсе буенча кешеләрнең хокукларын һәм ирекләрен бозарга, дәүләт иминлегенә янарга мөмкин, дип танылучыларга корал сатып алуга лицензия бирү тыела.

➤Рецептлы даруларны онлайн сату буенча эксперимент башлана. Ул өч төбәктә: Мәскәү, Белгород һәм Мәскәү өлкәләрендә 2026 елның 1 мартына кадәр үткәрeләчәк. Уңышлы килеп чыкса, башка төбәкләргә дә кертеләчәк.

➤31 мартка кадәр физик затлар, шәхси эшмәкәрләр, кече һәм урта эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче оешмалар 2022 елның 1 мартына хәтле төзелгән килешүләр буенча кредит каникулы алу өчен гариза тапшырырга мөмкин.

➤Биометрик мәгълүматлардан (бармак эзе, бит рәвеше, күзнең алгы тышчасы) файдалану мөмкинлеге пәйда булачак. Нинди очракларда? 1000 сумнан артмаган күләмдә акча түләгәндә (банк картасы белән), интернетта элемтә хезмәтләре күрсәтү турында килешүләр төзегәндә, Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлгәндә, студентларга бакалавриат, специалитет һәм магистратура программалары буенча имтихан тапшырганда.

➤Хөкүмәт йорт хайваннарын сату урыннарына карата таләпләрне раслаячак. Бу дүрт аяклы дусларыбызны зоокибетләр һәм кош-корт базарларындагы кырыс шартлардан коткарачак.

Сүзгә-сүз

Мария ЛЬВОВА-БЕЛОВА, Россия Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

– Гаилә шатлыкны арттыра: гел уртаклашыр һәм сөенер кешең бар. Бәйрәм арты бәйрәм – туган көннәр, юбилейлар, туйлар, мөһим вакыйгалар – бала туу, беренче сыйныфка бару, вузга укырга керү. Һәм сез боларның барысын да гаиләгез белән бергә билгеләп үтәсез.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – МӘДӘНИ ЯЛ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең театрга мөнәсәбәтен белешкән.

34% >> театрга йөрми

25% >> елына берничә тапкыр бара

21% >> беркайчан да театрда булганы юк

11% >> елына бер тапкыр бара



Ялган акча кимегән

Узган елда Россиядә ялган акча күләме башлыча ике тапкыр кимеп, 12,4 мең данә чамасы тәшкил иткән. Әйләнештәге һәр миллион акчаның икесе ялган (2022 елда – 4) булып чыккан. Узган ел 2284 – биш мең сумлык, 570 – бер мең сумлык, 140 ике мең сумлык ялган акча табылган. Чил ил банкнотларының да ясалмалары кимегән.

ru.pinterest.com



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЙӘМӘН КИСӘТҮЕ

Дөнья икътисадындагы проблемалар конфликтларның үсүенә һәм тирәнәюенә китерә. Европада фермерлар протесты тынмый. Шәһәр урамнарында печән төргәкләре, тирес өемнәре пейзажның аерылгысыз өлешенә әверелеп бара.

Поляк фермерлары, Украина ашлыгын Европага кертмәс өчен, гадәттән тыш адымга барды: тимер юл составын туктатып, ашлыкны җиргә бушаттылар. Моны эшләүчеләр кулга алынды, билгеле, һәм аларны 5 елга утыртырга җыеналар. Фермерларга каршы полиция көчен куллану, аларны кулга алу әлегә тиешле нәтиҗәне бирми. Халыкара валюта фонды (МВФ), протест Европада азык-төлек бәяләрен күтәрергә мөмкин, дигән белдерү ясады инде. Финанс чиновниклары фикеренчә, европалы лидерлар проблеманың чишелешен тапмаса, бәя күтәрелү кискен булырга да мөмкин.

Проблемалар бер авыл хуҗалыгында гына түгел. Кризис сәнәгать тармакларын да эчтән кимерә. Европадагы эре алюмин җитештерүче Norsk Hydro компаниясенең финанс директоры Пола Килдемо квартал табышының ике тапкыр кимүен әйтә һәм хәзерге вазгыятьне COVID чорындагыга тиңли. Арзанлы ресурслар булмаганлыктан, хәзерге бәяләр белән алюминга ихтыяҗ юк һәм аны җитештерү зыянга. Иң мөһиме: кыска сроклы перспективада уңай берни дә көтелми.

Без газетабызда һәрвакыт искәртеп килдек: кризисның үткен фазасы башланганчы ук аның чишелеше табылмаячагын әйттек. Чишелеш глобаль риба системасын җимереп, аның урынына гадел финанс вазгыяте урнаштырганда гына табылыр иде. Ләкин бу мөмкин түгел, чөнки барысы белән дә риба нәтиҗәсендә байлык туплаган катлау идарә итә. Алар үлгәнче каршылык күрсәтәчәк: планетаны зур сугышка тартып кертәчәк. Без күптән әйткән бу хакыйкать хәзер рәсми рәвештә һәр почмактан яңгырый. Бернинди сәбәпсез төбәк сугышлары маховигы әйләндерелә. Француз лидеры Макрон Париждагы конференциядә Украинага коры җир гаскәрләре җибәрү мәсьәләсе каралуын әйтте. Аның тел төбендә әлегә бу хакта рәсми килешү юк, әмма киләчәктә бу мөмкин эш дигән фикер ярылып ята. Бу уңайдан без үзебезнең бер фаразыбызны кабатлыйбыз: Якын Көнчыгышта вазгыять үзгәрмичә, Көнбатыш – Россия кораллы конфликты мөмкин түгел. Якын Көнчыгышта вазгыять исә үзгәрүгә таба. Дүшәмбе кичендә йәмәнлеләр үз кисәтүләренең беренче өлешен тормышка ашырды: Кызыл диңгез аша үтүче дүрт интернет кабельне өзделәр. Коммуникациягә шактый зыян килде, әмма әлегә куркыныч түгел, чөнки элемтәне тәэмин итүче башка кабельләр төзек. Алар да шул урыннан үтә. Барлык кабельләр дә өзелсә, Европада һәм Азиядә зур проблемалар туачак.

Россиядә

ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫ КИРЕГӘ ӘЙЛӘНДЕРҮ

Россия икътисадында проблемаларның үз йомгагы төенләнеп килә. 1 марттан чит илләргә бензин экспорты 6 айга туктатыла. Бу рәхәткә чыдый алмаганнан эшләнми. Биржада көн саен бензин бәясе үсә. Күп кенә нефть эшкәртү заводлары сизелерлек зыян күрде һәм экспорт болай да ярыйсы ук кимеде инде.

Алда язгы кыр эшләре тора һәм чәчүгә югары бәядәге ягулык белән килергә ярамый. Дефицит тудыру – бөтенләй рөхсәт ителмәслек хәл. Вице-премьер Александр Новак бу уңайдан Хөкүмәткә махсус хат язарга мәҗбүр булды һәм Премьер-министр Михаил Мишустин хаттагы дәлилләр белән килеште. Нефть продуктларын экспортлау – Россиянең иң табышлы сәүдә тармагы, аны туктату валюта керемнәрен киметәчәк. АКШта да нефть эшкәртү кимегән дигән хәбәрләр бар. Дөнья базарында ягулык бәяләре тагын да үсәчәк. Димәк, иң күп табыш вәгъдә ителгәндә, читкә сатуны туктатырга туры килә.

Сәнәгать предприятиеләре алдында торган проблемаларны Кремль кире Хөкүмәт карамагына тапшырып хәл итә башлады. Национализация, ягъни бизнесны хосусый хуҗалар кулыннан алып чиновниклар карамагына тапшыру башка илләрдә дә күзәтелгәли. Аның берничә схемасы бар. Иң уңышлысы – активларны элекке хуҗага бәясен түләп алу. Россия үз юлы белән бара. Хосусыйлаштыру, ягъни приватизация законсыз үткәрелде дигән тезис алга этелә. Мондый очракта элекке хуҗага әҗер түләп мәшәкатьләнәсе юк. Чиләбе электр металлургиясе комбинатын дәүләт карамагына тапшыру россиячә национализациянең нәкъ шул юл белән барачагын искәртә.

Генпрокуратура 32 ел элек хосусыйлаштыру дөрес үткәрелмәгән дигән дәлил игълан итте дә Владимир Путин карары белән мәсьәлә тиз хәл ителде. Тагын берничә шундый предприятие шул ысул белән хуҗа алыштыру алдында. Аларның инде цехлары җимерелеп, эшкә яраксыз хәлгә килгән, банкротлык хәлендә эшне туктатканнар. Хөкүмәт, күрәсең, югалган җитештерү мәйданнарын яңадан эшкә җигәргә җыена. ЧЭМК – илдәге ферроэретмәләрнең 90 процентын җитештерүче стратегик предприятие. Аның хуҗасын алыштыру бу юнәлештәге рәсми стратегиянең ни рәвешле буласын күрсәтә. Комбинатның элекке хуҗасы Юрий Антипов мошенниклыкта гаепләнеп кулга алынды дигән хәбәрләр Кремльнең олигархларны йон уңаена сыпырып торырга җыенмавын дәлилли. Бу хәлләр вазгыятьне ничек үзгәртер – анысын без фаразламыйбыз.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ГАДЕЛЛЕК ХАКЫНА

СУДЬЯЛАР УТЫРЫШЫНДА 2023 ЕЛГА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

Бәхәскә гадел нокта куючылар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республика судьяларының киңәшмәсендә катнашты. Җыелып, узган елга нәтиҗә ясадылар.



tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, судлар экстремизм, терроризм, җинаятьләргә каршы торуда әһәмиятле роль башкара. Аларның эшчәнлеген юк итү илдәге тотрыклылыкны саклауның мөһим өлеше икәненә басым ясады Рәис. Шулай ук Рөстәм Миңнеханов мигрантларга бәйле низагларны да игътибарсыз калдырмаска өндәде.

Татарстан Рәисе искәрткәнчә, җинаятьләргә карата хәерхаһлы булу җәза бирмәү белән янәшә тора алмый. Дәүләт иминлегенә куркыныч тудыра торган хәлләргә һәм җинаятьләр саны артуына да юл куярга ярамый. Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән судларның аңлату, профилактик чаралар алып бару бурычлары барлыгын да искә төшерде.

Хәзерге вакытта халыкның судка гозерләре күпфункцияле үзәкләр аша да кабул ителә. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, бу мөмкинлекне алга таба да үстерергә кирәк. «Гаделлек урнашсын өчен шартлар тудыру – безнең өстенлекле юнәлешебез. Күпфункцияле үзәкләр белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне җайга салырга кирәк», – диде Рәис.

Сүз уңаеннан, быелтыр судьялар саны арткан. Республика судларына тагын 23 федераль судның гомуми юрисдикция судьялары һәм 18 җәмәгать судьялары эшкә килгән. Рөстәм Миңнеханов судларны кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсенә дә игътибар итте. Бу эшкә балаларны мәктәп эскәмиясеннән үк әзерләргә кирәк.

Инде судьяларның узган ел нәтиҗәләренә күз салыйк. Санлы күрсәткечләр болайрак:

- Татарстан судлары тарафыннан **1** млн **119** мең эш һәм материал каралган (шуларның **765** меңен – җәмәгать судьялары, **320** меңен – район һәм шәһәр судьялары, **34** меңен Югары суд караган).
- Административ хокук бозуларга кагылышлы эшләр саны **25** процентка кимегән, гражданлык эшләренә бәйле каралган материаллар саны – **12**, җинаять эшләренә бәйлеләре **2,4** процентка арткан.
- Судьялар рәсми сайтларда **107** мең **519** суд актын урнаштырган.
- Республика судларына электрон рәвештә **200** меңнән артык документ килгән, шуларның **3,5** процентын кире борганнар.

* * *

Татарстан Рәисе катнашында тарихи торак пунктларында шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия утырышы үтте. Бу – беренче очрашу. Утырышта Казан, Буа, Мамадыштагы яңа төзелеш проектлары каралды.

Утырыш вакытында Рөстәм Миңнеханов яңа объектларның гомуми манзараны бозмаска һәм аларның мәдәни, табигый мирас корылмаларының төзеклеген сакларга тиешлеген искәртте. Казанга бәйле проектларны башкаланың төп архитекторы Илсөяр Төхвәтуллина күрсәтте. Барлыгы 19 проект каралды (Казан дәүләт яшь тамашачы театры бинасы, «Сувар Плаза» комплексы, Чехов базары һ.б.).

Буа районы башкарма комитетының архитектура бүлеге начальнигы Ринат Гыйльфанов Бакый Урманче музее проектын тәкъдим итте. Аны хупладылар.

Мамадышта Изге Троица православие гыйбадәтханәсен төзү проекты турында Мамадыш районы Башкарма комитетының баш архитекторы Гадел Сибгатуллин хәбәр итте. Бу проект та хупланды.

tatarstan.ru

Авылда эшлисе

Лениногорск районы узган елның IV квартады йомгаклары буенча Татарстанның социаль-икътисадый үсеш рейтингында 20 нче урында тора.

Ләкин районның авыл хуҗалыгында җитештерү буенча күрсәткечләре мактанырлык түгел. 2023 ел өчен төзелгән агросәнәгать комплексы рейтингында – 41 нче урында гына. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Лениногорскида район Советының хисап сессиясендә шул мәсьәләләргә игътибарын юнәлтте. Утырышта районның узган елдагы эшенә йомгак ясалып, быелга планнары каралды.

Парламент башлыгы хисап сессиясе алдыннан Лениногорск политехника көллиятендә педагоглар һәм укучылар белән аралашты, шулай ук яңа остаханәләр белән танышты. Әлеге уку йорты инде менә 70 елдан артыграк вакыт дәверендә машина төзү, нефтьүткәргечләр һәм электр җиһазларыннан файдалану, эретеп ябыштыру өлкәсендә эшчеләр, шулай ук пешекче һәм кондитерлар әзерли.

Утырышта Лениногорск районы хакимияте башлыгы Рәгат Хөсәенов хисап тотты. Ул үзенең чыгышын махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итүчеләргә рәхмәт сүзләреннән башлады. Предприятиеләр җитәкчеләре, эшмәкәрләр, гади кешеләр катнашында мобилизацияләнүчеләргә, аларның гаиләләренә, Донецк һәм Луганск халык республикаларында яшәүчеләргә ярдәм оештырылган. Барлыгы 125 тоннадан артык гуманитар йөк озатылган.

Район хакимияте башлыгы сүзләренә караганда, төп предприятиеләр планлаштырылган барлык проектларын тормышка ашыруны дәвам итә. Узган елда Лениногорск нефтьчеләре 3 миллион тоннадан күбрәк нефть чыгарган. Авыл хезмәтчәннәре 60 мең тонна ашлык җыйган. Барлыгы 3,9 мең тонна терлек һәм кош-корт ите җитештерелгән. 13,5 мең тонна сөт савып алынган.

«Кызганычка, 2023 елда Лениногорск кошчылык фабрикасында кош гриппы килеп чыкты. Шул сәбәпле кош-кортны тулысынча (250 мең баштан артык) юкка чыгарырга туры килде. 60 миллион сумга якын зыян килде, – дип сөйләп үтте район хакимияте башлыгы. – Хәзерге вакытта предприятиене яңа инвестор сатып алды. Ул күркәләр үстерергә ниятли».

Рәгат Хөсәенов районның төп проблемалары арасыннан кадрлар җитмәүне билгеләп үтте. Моннан тыш инженерлык челтәрләре, җылылык һәм су торбалары 80 процентка тузган. Район хакимияте башлыгы шәһәр транспорты мәсьәләсенә аерым тукталып үтте.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Лениногорск районы узган елның IV квартады йомгаклары буенча Татарстанның социаль-икътисадый үсеш рейтингында 20 нче урында тора. Районда федераль һәм республика программалары хисабына барлыгы 38 объект төзелгән һәм төзекләндерелгән (486 миллион сумга). Инвесторлар һәм «Татнефть»нең грантлары ярдәмендә инфраструктураны үстерүгә 431 миллион сум җәлеп ителгән. Парламент Рәисе нефтьчеләргә төрле яклап ярдәм итеп килүләре өчен рәхмәт белдерде.

Шул ук вакытта, Дәүләт Советы Рәисе сүзләренә караганда, районның республикада сөрүлек җирләрнең 2,29 процентына ия булуына карамастан, авыл хуҗалыгында җитештерү буенча күрсәткечләре мактанырлык түгел. Лениногорск районы 2023 ел өчен төзелгән агросәнәгать комплексы рейтингында – 41 нче урында гына. «Менә кайда үсәргә була! Бүген авылда шәхси ярдәмче хуҗалыкларга, бизнеска, авыл хуҗалыгы кооперативларына ярдәм итү буенча күп кенә чаралар гамәлдә булып килә. Мөмкинлекләрдән ныграк файдаланырга кирәк», – диде парламент башлыгы.

Фәрит Мөхәммәтшин алда торучы сайлауга аерым тукталып узды. «Лениногорскида яшәүчеләрнең сайлауда активрак булуларын телисе килә», – диде ул.

ЧҮПЛИБЕЗ ДӘ ҖЫЯБЫЗ

Әйләнә-тирә

Татарстанда «Экология» илкүләм проекты кысасында 2019 елдан бүгенгә кадәр 6 федераль проект тормышка ашырылган. Алар ярдәме белән 17,6 млрд сумлык табигатьне саклау чаралары уздырылган. Алдагы ике елда тагын 5,7 млрд сумлык 8 чара уздырылачак. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган матбугат очрашуында Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков сөйләде.

– Республикада соңгы 6 ел эчендә табигатьне саклау өчен 60,5 млрд сум акча тотылды. 65 млрд сумлык зыянны булдырмый калдык. Экологияне саклауга Татарстанда эшләүче сәнәгать оешмалары да үзеннән саллы өлеш кертә. Без бу яктан Идел буе федераль округында беренче, – ди министр.

Сер түгел, Татарстанда Россиядәге барлык пилот проектлар гамәлгә ашырыла. 2018 елдан бирле 92 су саклау-чистарту җиһазлары төзәтелгән, Чулманның Алабуга районындагы ярларын ныгытканнар, Лаеш районының Имәнкискә авылында ярлар ныгытылган. Тагын бер күп сөйләнелгән чара – Түбән Кама районындагы Прости авылы янындагы чүплек тә бетерелеп, инде хәзер бу урында җир астыннан чишмәләр бәреп чыккан. Минзәлә районындагы зур чүплектән дә котылганнар.

– Саба районының Шәмәрдән бистәсендә җиргә нефть түгелгән урын бар иде. Акрынлап андагы чистарту эшләре дә төгәлләнеп килә. «Иделне савыктыру» федераль программасы ярдәме белән Түбән Кама сусаклагычында тик яткан, искергән нефть торбалары судан чыгарылды, – ди министр, эшләгән эшләргә йомгак ясап.

Әле болар янында Казан халкының котын алып торган, урамга чыкса, сасы исе белән кәефен төшергән Самосырово чүплеге дә бар. Инде анда хәзер чүп калмавы, җыелган каты көнкүреш калдыкларыннан энергия алуны язган да идек. Казан халкы өчен тагын бер шатлыклы хәбәрне дә искә алыйк. Су чистарту корылмаларыннан чыккан ләм басуларын киптерә башлау. Быел бу эш тәмамланачак. Ул «Иделне савыктыру» федераль программасы ярдәме белән башкарыла.

Шунысын да әйтергә кирәк: быелдан «Иделне савыктыру» һәм «Уникаль суларны саклау» федераль программалары урынына «Россиянең су объектларын савыктыру» дигәне эшли башлый.

Министр республикада экологиянең елдан-ел яхшыруын әйтә. Моңа кешеләрдән килгән зарларның кимүе дәлил булып тора. 2018 ел белән чагыштырганда һава сыйфатына зарланып 583 мөрәҗәгать килгән булса, 2023 елда бары тик 60 хәбәр алынган.

Зар дигәннән, елга нәтиҗә ясап уздырылган еллык киңәйтелгән утырышта Александр Шадриков Казанның Авиатөзелеш районыннан зарлар еш килүен дә әйткән иде. Андагылар сасы искә зарланды. Хикмәт нидә соң? Бу сорауга Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама Төбәкара идарәсе җитәкчесе Фаяз Шакиров җавап бирде.

«Татар-информ»

– Әле дә һавага зыян салган оешмалар белән эшлибез. Максатыбыз аларны җаваплылыкка тарту гына түгел, һава чисталыгын да яхшырту, – ди ул.

Зыян турында Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Илнур Гобәйдулин да сөйләде. 2023 елда Самосырово бистәсендәге чүплектән табигатькә 14 миллион сумлык зарар килгән. Казанның Дәрвишләр бистәсендәге чүплекне юкка чыгарыр өчен Казан башкарма комитеты 58 миллион сум акча бүлеп биргән. Гудованцев урамындагы чүплек аркасында башланган эш судка барып җиткән. Инде өч ел буе гаепләне эзлиләр. Килгән зыян суммасы 88 миллион сум тәшкил итә. Журналистлар Илнур Гобәйдуллиннан: «Мал асраучылар һаваны бозмыймы?» – дип тә сорадылар. Ә ул исә бу сорауга бик гади итеп кенә җавап бирде.

– Без бит барыбыз да диярлек авылда үскән. Мал тотмыйча гына яшәп булмый. Элек мондый зарлар юк иде. Ә хәзер күршесенең каз-үрдәк асравы да ошамый, тавык тота, дип тә шалтыраталар. Без исә мондый очракта ниндидер чарлар күрү яклы түгел. Иң элек сөйләшәбез, аңлатабыз. Аннары гына, җирне дөрес файдаланамы, барысын да ачыклар өчен мөрәҗәгатьне тиешле органнарга җибәрәбез, – ди ул.

Александр Шадриковтан: «Быел Иделдә су булырмы?» – дип тә сораштык. Аның фикеренчә, бар да Россия гидрометеорология хезмәтенең дөрес фаразыннан тора.

– 2019 елда да кар күп яуды. Ул чакта да өметләр зур иде. Узган ел да Иделгә су төшәчәк дип көткән идек. Фаразлар чынга ашмады. Бүген Куйбышев сусаклагычында су биеклеге 50,68 см тәшкил итә. 1 апрельгә 51 метр булыр, диләр. Барысын да вакыт күрсәтер, – ди министр. – Су кимү безнең генә проблема түгел. Каспий диңгезе дә саега. Биш төбәк тәкъдимнәрен Россия Президенты Владимир Путинга да җиткердек.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ:
«РОССИЯНЕҢ ҮЗ ЮЛЫ БАР»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Шуннан бирле КАМАЗ буенча хәлиткеч карарлар барысы да Владимир Владимирович Путин катнашында кабул ителә. Ул Чаллыга, КАМАЗга күп тапкырлар килде. 2019 елда ул КАМАЗ эшчеләрен автогигантның юбилее белән котларга килгән иде. КАМАЗның 50 еллыгына багышланган митингта ул: «Әлеге предприятиегә нигез салган, аңа бөтен күңелен биреп эшләгән кешеләр алдында баш иябез», – диде. Ә мин, Владимир Владимирович үзе дә КАМАЗны тергезүгә һәм үсешенә бөтен күңелен бирде, дияр идем. Илебез һәм республикабыз тырышлыгы нәтиҗәсендә КАМАЗның җитештерү куәте артты, хәзерге вакытта ул елга 70 меңнән артык автомобиль чыгара. Владимир Владимирович әйткәнчә, КАМАЗ халыкара брендка әйләнде, шул исәптән «КАМАЗ-мастер» командасының югары дәрәҗәле халыкара ярышларда җиңү яулавы белән дә. Бүген, махсус хәрби операция шартларында, КАМАЗ безнең Кораллы Көчләрне хәрби техника белән тәэмин итү буенча барлык бурычларын үтәп килә.

:: Сез җитәкләгән Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу республика фонды 2010 елдан башлап федераль күләмдә әһәмияткә ия тарихи истәлекләрне саклау буенча уникаль проектларны гамәлгә ашырды. Мәсәлән, борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрен тергезү уңышлы төгәлләнде. Шулкадәр киң колачлы һәм әһәмиятле проектны оештыруга һәм башкарып чыгуга ничек ирешә алдыгыз?

– Болгарны һәм Зөяне тергезү тарихы бик кызыклы, белгәнемчә, ил буенча хәзергә андый проектлар күренгәне юк әле. 2010 елда, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасыннан киткәч, мин ике борынгы шәһәр – Болгарны (X–XIV гасырлар) һәм Зөяне (XVI гасыр) тергезү белән шөгыльләнергә булдым. Бу турыда күптәннән хыялланып йөрдем, ничегрәк эшләргә, дип шактый озак уйландым. Иң элек ул чакта илнең Премьер-министры Владимир Владимирович Путиннан кабул итүен сорадым. Очрашу Мәскәүдә, Ак йортта 2009 елның 30 декабренә билгеләнде. Мин, гадәттәгечә, иртәрәк килдем һәм анда Хөкүмәтнең бөтен әгъзаларын очраттым. Хөкүмәт Рәисенең Яңа ел котлавына җыелганнар икән болар. Шушы гаять уңайлы форсаттан файдаланып, финанс министры Алексей Кудрин һәм мәдәният министры Александр Авдеев белән шушы проект турында күзгә-күз сөйләшеп алырга өлгердем. Бу эшкә Хөкүмәт Рәисе ризалыгын алырга ниятләп килдем, дидем. Икесе дә әлеге башлангычны хуплады һәм ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

Владимир Владимирович белән очрашу барышында мин аңа үземнең республика башлыгы вазыйфасыннан киткәннән соң шөгыльләнәчәк проектымның асылын җиткердем. Башта сорадым: «Сезгә Казан Кремле ошыймы?» Путин аны берничә кат күрде, мәчет белән собор янәшә, һәркемнең күңеленә хуш килә, әлбәттә. «Татарстандагы динара татулыкның шушы күркәм образын бөек Идел киңлекләренә – борынгы Болгар һәм Зөя шәһәрләренә чыгару әйбәт булыр иде», – дип тә өстәдем.

«Язмыш ихтыяры белән, бер елга ярларында ике тиңсез тарихи истәлек – Болгар һәм Зөя урнашкан. Туристлык юллары кисешкән урында мондый уңышлы янәшәлек бик сирәк очрый. Алар һәрвакыт федераль әһәмияткә ия объектлар булып торды, аларны саклап тоту өчен елга нибары 15–20 миллион сум акча бүлеп бирелә. Бу сумма аларның акрынлап җимерелүен туктатырга да җитми

хәтта», – дип сөйләдем аңа. Владимир Путин идеяне хуплады. Аңа алдан әзерләнгән конкрет тәкъдимнәрне һәм төгәл исәп-хисапны күрсәттем. Бу эшне финанслауны тигез өлешләрдә башкарырга тәкъдим иттем: 50% акча – республика бюджетыннан, 50% – федераль бюджеттан, калганы – хәйриячеләр ярдәме. Владимир Путин риза булды һәм шундук тиешле министрларга бу тәкъдим буенча эшләргә боерды. Россиянең тиешле министрлыклары һәм ведомстволары белән сөйләшү нәтиҗәсендә проектка Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Россия Федерациясе бюджетыннан тигез өлешләрдә акча бирү турында килештек.

Шунысын аерым әйтәсем килә: бу килешү проект төгәлләнгәнче һәрвакыт өзлексез үтәлеп килде. Сүз уңаеннан, Владимир Владимирович 2012 елда Болгарга да, Зөягә дә үзе килде, тарихи истәлекләр белән танышты, берочтан торгызу эшләренең барышын да тикшерде. Безнең гамәлләргә бәя биреп: «Нәтиҗәсен күрү күңелле», – диде ул.

Шул рәвешчә, әлеге киң колачлы проектның уңышын ил һәм республика җитәкчелегенең, Россия Президенты Владимир Владимирович Путинның, Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның, республиканың күпмилләтле халкының, җәмәгатьчелегенең, эшмәкәрлек вәкилләренең һәм үз илебездән генә түгел, чит илләрдән дә катнашкан йөз меңләгән хәйрияче ярдәме тәэмин итте.

Бу бөтен халык эшенә әверелде. Миңа шунысы мөһим. Гамәлең иң кирәкле ноктага туры килгәндә һәм гомумхалык хуплавы алганда эшләү һәм иҗтиһат итү җиңелрәк. Форсаттан файдаланып, безгә ихлас күңелдән ярдәм итә торган кешеләргә тагын бер кат рәхмәтемне белдерәм.

Барыбыз бергә тотынып, борынгы Болгар шәһәрен торгызуыбыз Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүенең 1100 еллыгын 2022 елда дәүләти югарылыкта бәйрәм итү турында карар кабул ителүендә төп рольне уйнады. Мәгълүм булганча, әлеге зирәк карар илебез җитәкчелеге, Президент Владимир Путин тарафыннан кабул ителде. Бу күпмилләтле ил өчен бик дөрес адым иде. Аңлашыла ки, мондый бәйрәм тотрыклылык булган, төрле диннәр бер-берсен ихтирам итеп, дус-тату яшәгән, күпмилләтле халкыбыз хакына хезмәттәшлек иткән илдә генә мөмкин. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы бөтен ил өчен бәйрәм булды. Динара мөнәсәбәтләрнең шундый югарылыгына ирешә алуыбыз белән, һичшиксез, барыбызга да горурланырга кирәк.

:: Минтимер Шәрипович, соңгы елларда Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе, Россия Чит ил эшләре министрлыгы белән бик нәтиҗәле хезмәттәшлек итә. Әлеге юнәлеш Сезнең исемгә бәйле, чөнки Сез – бу комиссия әгъзасы һәм ЮНЕСКОның Игелекле ихтыяр илчесе. Әлеге өлкәдәге эшчәнлек нәтиҗәләреннән канәгатьме Сез?

– Татарстанның ЮНЕСКО белән эшчәнлеге узган гасырның 90 нчы елларында ук башланды, нәтиҗәдә 2000 елда Казан Кремле Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. Әлбәттә, «Яңарыш» Республика фонды оештырылу һәм Болгар белән Зөя буенча проектны башлап җибәрү дә әлеге юнәлешкә яңа этәргеч бирде. Чөнки Фонд үз эшчәнлегенең беренче көннәреннән үк Болгарны һәм Зөяне ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү буенча актив эш алып барды. Шунысын әйтим: Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе дә, Россиянең Чит ил эшләре министрлыгы җитәкчелеге дә безнең тәкъдимнәрне һәрчак хуплап килде, алар ярдәме белән без ЮНЕСКО җитәкчеләре, Бөтендөнья мирасы комитетының ИКОМОС, ИКРОМ шикелле киңәшләшү оешмалары белән эшлекле элемтәләр булдырдык. Без үзебезнең төп принципка туры булдык: бөтен нәрсә фәнни тикшеренүләр нигезендә һәм ЮНЕСКО таләпләренә туры китереп башкарылырга тиеш. Миңа калса, без нәкъ менә шуңа күрә үз максатларыбызга ирештек. 2014 елда – Болгар тарих-археология комплексы, 2017 елда Зөя утрау-шәһәренең Успенье соборы һәм монастыре ЮНЕСКО исемлегенә керде. Ә узган ел Казан университетының Астрономия обсерваторияләре дә Бөтендөнья мирасы дип танылды. Бу инде – Татарстан территориясендә Бөтендөнья мирасының дүртенче объекты. Хәзер республика ЮНЕСКО объектлары саны буенча илдә иң беренче урында тора. Кыскасы, нәтиҗәләр таң калдыра һәм алга таба да эшләргә рухландыра.

:: Статистика мәгълүматына караганда, безнең истәлекле урыннарыбызны һәм изге җирләребезне карарга килә торган туристлар һәм зиярәт кылучылар саны көннән-көн арта бара. Сез ничек уйлыйсыз, республикада ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы объектлары булу Татарстанның туристлык тармагы үсешенә йогынты ясыймы?

– Әлбәттә, Бөтендөнья мирасы исемлегенә керү – үзе үк бик зур казаныш, бу истәлекләр күпләрне үзенә җәлеп итә. Туристларның нигездә Бөтендөнья мирасы объектларын күрергә омтылуы сер түгел. Шуңа күрә ЮНЕСКО исемлегенә керү Казан Кремленә, Болгарга, Зөягә килүчеләр санын шактый арттырды.

Бу саннар барыбызны да шаккатыра. Мәсәлән, узган ел Кремльдә 4 миллион 500 меңнән артык кеше булган. Борынгы Болгарга 2010 елда 50 мең кеше килсә, 2023 елда туристлар саны 735 меңгә җиткән. Узган ел Зөя утрау-шәһәренең музейларын һәм храмнарын 1 миллион 740 мең кеше караган.

Шунысын әйтергә тиешмен: ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә керүнең мәгънәсе матди файдада түгел. Барыннан да элек, бу – халыкның мәдәни дәрәҗәсенең һәм җәмгыятьнең цивилизацияле үсешенең иң мөһим күрсәткечләреннән берсе булып тора. Бу күбрәк җәмгыятьнең һәм хакимиятнең әлеге күренекле универсаль хәзинә дип танылган истәлекләргә карата сакчыл карашны тәэмин итү өчен җаваплылыгы турында сөйли. Татарстан әлеге юнәлештә дә алдынгы булырга тиеш дип уйлыйм.

:: Минтимер Шәрипович, илебез үсешенең дәүләтебез җитәкчесе Владимир Путин билгеләгән илкүләм максатларыннан берсе – яшь буынның үсеше һәм тормышта үз урынын табуы өчен мөмкинлекләр тудыру. Шуңа күрә республика җитәкчелеге мәгариф системасын камилләштерүгә аерым игътибар бирә. 2020–2022 елларда Сезнең тәкъдим буенча «Адымнар» күптелле белем бирү комплекслары барлыкка килде. Аларның үзенчәлеге нидә?

– «Адымнар» – киләчәк мәктәпләре. Аларның вазыйфасы – балаларыбызны көндәшлеккә сәләтле итеп тәрбияләү. Бу – балаларның иҗади мөмкинлекләрен иртәрәк ачу һәм алга таба үстерү өчен шартлар тудыруның бер үрнәге. «Адымнар»да һәрбер бала үз күңеленә якын шөгыль сайлый ала.

Республикада 6 күптелле белем бирү комплексы төзелде, алар матур гына эшләп килә. Барысын да бер исем берләштерә: «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл». Биредә тәрбия ЮНЕСКО принциплары буенча алып барыла: «белер өчен өйрәнергә, булдырыр өчен өйрәнергә, яшәргә өйрәнергә һәм бергә яшәргә өйрәнергә». Бу исә Татарстан өчен аеруча көнүзәк, чөнки бездә 170тән артык милләт вәкилләре яши.

Хәзерге вакытта без күптелле белем бирүнең халыкара дәрәҗәдә көндәшлеккә һәм күпмилләтле, күпмәдәниятле тирәлектә актив эшләргә сәләтле моделен булдырабыз. Нәкъ менә шушы мәктәпләрдә тәрбия алган балалар аша республика глобаль дөньяда үз позициясен ныгыта алачак. Мондый проектларны гамәлгә ашыру республиканың сыйфат мөмкинлекләре арту һәм җәмгыятебезнең рухияткә ирешүе хакында сөйли.

Республиканың мәгариф системасы – Россиядә алдынгылардан берсе. 2018 елдан алып Татарстанда 212 объект: мәктәпләр, балалар бакчалары, өстәмә белем бирү учреждениеләре төзелде. 2400 объектта капиталь төзекләндерү үткәрелде.

Талантлы балаларга системалы төстә ярдәм итү үз нәтиҗәләрен бирә: республика мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадаларында җиңүчеләр саны буенча илдә беренче өчлеккә керә.

Шунысын да әйтим: илебез җитәкчелеге, мәгариф өлкәсендә илкүләм проектларны эзлекле гамәлгә ашырып, киләчәгебезне төзи. Владимир Владимирович Путин әйтүенчә: «Безнең барлык җиңүләребезгә мәктәптә нигез салына. Бу – ап-ачык нәрсә, бу – бөтен җәмгыять, бөтен ил, бөтен дәүләт төзелә торган фундамент».

:: Хөрмәтле Минтимер Шәрипович, безнең ил алып бара торган махсус хәрби операция башланганнан бирле күп тапкырлар инандык: халыкларыбыз дуслыгы – безне җиңүгә китерәчәк иң мөһим, иң куәтле көч. Әмма күмәк Көнбатыш дип атала торган чит бергәлек безнең җәмгыятьне гел таркатырга тырыша, иң беренче чиратта – милләтара һәм динара дошманлык тудыру юлы белән. Мондый хәлләрне булдырмас өчен ниләр эшләргә кирәк?

– Милләтара низагларны булдырмас һәм ят йогынтыларга бирелмәс өчен Татарстандагы кебек яшәргә кирәк, ягъни үсешнең нигезе итеп, аңлы рәвештә, халыклар арасындагы үзара ихтирамны һәм татулыкны сайларга. Янәшәдә яши торган милләтләрнең мәнфәгатьләренә һәм ниятләренә игътибарлы булырга. Ана телләрен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен саклауга кагылышлы проблемаларны күздән ычкындырмаска, яшереп калмаска, киресенчә, колак салырга һәм хәл итәргә. Милләтләр һәм мәдәниятләр арасында диалогны бертуктаусыз алып барырга. Берләштерә торган эшләргә тотынырга. Мисал өчен, безнең мөселман һәм православие истәлекләрен бер үк вакытта тергезү алымы вакыт сынавын узды. Без инде күптән моның хак юл икәненә төшендек, иң мөһиме, бу кешеләр күңеленә хуш килә. Республика җитәкчесенең бер указы нигезендә Кремльдә Кол Шәриф мәчетен төзү һәм Благовещение соборын реставрацияләү, аннары – Болгар белән Зөяне тергезү, соңрак – Болгар ислам академиясен төзү һәм Мәрьям ана Казан иконасы соборын торгызу турында карарлар кабул ителде. Бу проектларны гамәлгә ашыру динара һәм милләтара татулыкны ныгытуда уңай чагылыш тапты. Алар безне бергә туплады, дин буенча бүленмәдек, барысын да бергәләп эшләдек.

Сүз уңаеннан, илнең зур үзәкләштерелгән мөселман дини оешмалары Болгар ислам академиясен булдыру турында тәкъдим белән чыккач, аларны Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин хуплады. Болгарны Россиядә беренче ислам академиясен төзү урыны итеп нәкъ менә ул билгеләде. «Мөселман яшьләренең традицион ислам кыйммәтләрендә тәрбияләнүе, безгә дөньяны күзаллауның хак ислам белән берниндиі дә уртаклыгы булмаган чит-ят юнәлешләрне көчләп тагарга омтылышларны туктату мөһим», – дигән иде ул. Бу – күпмилләтле илдә дөрес эш итүнең тагын бер мисалы.

Әйе, без төрле-төрле, әмма безнең уртак хәзинәләребез бик күп. Ватаныбыз да уртак – Россия Федерациясе. Аның илебездә яшәүче һәрбер милләткә хас традицион хәзинәләребезгә, ватанпәрвәрлеккә, үзара ярдәмгә, үзара ихтирамга, мәхәббәткә һәм гаиләгә нигезләнгән үз уникаль юлы бар. Тышкы көчләр безне моннан мәхрүм итәргә, безнең җәмгыятькә ят карашлар тагарга тырыша. Без боларга уебызда да, сүзебездә дә, гамәлебездә дә бердәм булып кына каршы тора алабыз. Быел 17 мартта узачак Президент сайлауда катнашу – безнең бердәмлекне ныгытуның иң дөрес юлы.

:: Минтимер Шәрипович, әңгәмәгез өчен бик зур рәхмәт Сезгә!

ЭСКӘМИЯ ГЕНӘ ҖИТМИ

Яшәеш

24 миллиард сум. Соңгы тугыз елда Татарстанда иҗтимагый киңлекләр һәм ишегалларын тәртипкә китерүгә әнә шулкадәр акча тотылган. Әлеге эш алга таба дәвам итәчәк. Мәсәлән, быел республикада «Безнең ишегалды» программасы кысасында гына да 833 ишегалдын танымаслык булып үзгәртергә ниятлиләр. Татарстанда яшәүчеләр тирә-юньне төзекләндерүчеләрдән күбрәк нәрсә сорый икәне дә билгеле.

Түбән Камада яшәүче Гөлия һәм Алмаз Шәрәфиевләр тизрәк кар эреп беткәнне көтә: әле былтыр гына төзекләндерелгән ишегалларына куаклар утыртмакчы алар. Моның өчен интернет-кибеттән әллә ничә төп үсентегә заказ биргәннәр дә инде.

– Безнең ишегалдында балаларга уйнарга юньле-рәтле мәйданчык та юк иде. Былтыр «Безнең ишегалды» программасы кысасында аны танымаслык булып үзгәрттеләр, – ди Төзүчеләр проспектында яшәүче гаилә. – Өйгә кайту рәхәт. Хәзер ишегалдында тәртипне күз карасы кебек саклыйбыз.

Татарстанда иҗтимагый киңлекләрне яңарту эше 2015 елдан бирле алып барыла. 2017 елдан бирле исә парклар һәм скверларны «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты кысасында да төзекләндерәләр.

– Соңгы тугыз елда республикада 398 иҗтимагый киңлек рәткә китерелде. Әлеге максаттан 23,9 миллиард сум акча тотылды. Бу акчаның зур өлеше республика казнасына туры килә, – диде Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрының беренче урынбасары Алексей Фролов.

Былтыр гына да республикадагы 68 мәйданда 2,9 миллиард сумлык эш башкарганнар. Дөрес, төзедең дә бетте түгел. Министрның беренче урынбасары бу язда җиңне тагын да ныграк сызганырга туры киләчәген әйтте.

– Бу кышта ишеп яуган кар, иҗтимагый киңлекләрдә дә су басуга китерергә мөмкин. Шуңа күрә ачык һавада халык күпләп йөргән урыннарда тиешле чаралар күреләчәк. Кар эреп беткәч тә, тирә-юньне тагын бер кат тәртипкә китерергә туры киләчәк, – диде Алексей Фролов.

Быел 64 мәйданны яңартырга ниятлиләр. Моның өчен былтыргыга караганда азрак – 2,3 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Шул исәптән Чаллыдагы 1950 нче елларда ук төзелгән «Яр буе» паркын төзекләндереп бетермәкчеләр.

Әлмәт шәһәре һәм районы башлыгы Тимур Нагуманов фикеренчә, әлеге эш тирәлекне генә түгел, безне дә үзгәртә.

– Шул ук шәһәр урамнарын рәткә китергәндә дә, бу – яңа эскәмия куйдың да бетте дигән сүз түгел. Яңа иҗтимагый киңлекләр биредәге тормышны баштанаяк үзгәртә. Төзекләндерелгән урамнарыбыз көндез эш белән яшәсә, кичләрен һәм ял көннәрендә ял урынына әверелә, – дип сөйләде нефтьчеләр каласы җитәкчесе.

Татарстанда 2020 елдан бирле тормышка ашырылучы «Безнең ишегалды» программасы кысасында 2 мең чакрымнан да артык озынлыкта җәяүлеләр юлы салганнар инде. «Бу – Казаннан Калининградка кадәр юл дигән сүз», – диде проект кураторы Арина Петрова. Әлеге программа республикада яшәүчеләргә бигрәк тә якын, аның кысасында күпкатлы йортларның ишегалларын рәткә китерәләр. 2020 елдан бирле 34 миллиард сумлык эш башкарганнар. Республикадагы 4,4 меңгә якын ишегалды төзекләндерелгән. Татарстанның 13 районында бу эшне төгәлләргә дә өлгергәннәр.

– Без койма утырту яки шлагбаум урнаштыру белән шөгыльләнмибез. Ишегалдына яшеллек тә утыртмыйбыз, чөнки аны утыртып кына эш бетми, алга таба карап торырга да кирәк, – диде Арина Петрова.

Аның сүзләренә караганда, ишегалларында күбрәк зур чыгымнар таләп итә торган, күләмле эшләр башкарыла. Мәсәлән, барлык чыгымнарның 80 проценты юлларга таш түшәүгә туры килә икән.

Ишегалдын тәртипкә китерүчеләрдән халыкның күбрәк нәрсә сораганы да билгеле. Уйлап баш ватмагыз: һаман да шул машина кую урыннары җитми. Бу форсаттан Түбән Кама шәһәре районы башлыгы Рамил Муллин мәсьәләдән чыгу җаен да тәкъдим итте.

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– Илкүләм проектлар халык өчен бик тә мөһим. Алар илдә яшәүче гаиләләрнең иминлеген арттырырга, шәһәр мохитен, социаль өлкәне яхшыртуга хезмәт итәргә, бизнеска яңа мөмкинлекләр ачарга тиеш. Илкүләм проектларның максаты – нинди дә булса объектны төзү, кулланышка тапшыру яки ремонтлау гына түгел, алар ярдәмендә халыкны борчыган мәсьәләләр хәл ителергә тиеш.

– Түбән Камада ишегалларында вакытлыча машина кую урыннары төзи башларга телибез. Ягъни асфальт салмыйсың, җиргә бераз ком түшисең дә өстенә вак таш җәясең. Югыйсә халык машинаны кая куярга дип аптырый. Безгә барыбер җәмәгать транспортын үстерергә кирәк. Киләчәктә ишегалларында машина кую урыннарының кирәге калмаса, вак ташны җыеп алырга да мөмкин, – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Матбугатка күзәтү

Башисемең матур, кемнәр куйган?

Газетадагы язманың атамасын «башисем» диләр. Аны уйлап табу зур осталык таләп итә. Үзәк матбугатның кайбер зур редакцияләрендә бары тик башисем генә иҗат итүче хезмәткәрләр бар. Еш кына өйрәнчек журналистлар үз язмаларына исем куеп мәшәкатьләнми, редактор куяр әле, янәсе. Андый чакларда татар журналистларының остазы мәрхүм Илдар Низамов безгә болай дип әйтә иде: «Язма ул – журналист тудырган бала. Ничек инде бала исемсез була алсын?» Әмма башисем белән харап булырга да мөмкин. Совет заманында «Сталинград» сүзендә ялгыш «р» хәрефе төшеп калу сәбәпле, кешене эшеннән алган очракларны да ишеткән бар (җиңел котылган). Күпчелек очракта башисем укучының игътибарын җәлеп итү ролен үти. Шуңа да монда төрледән-төрле кораллар кулланыла: каламбур, киная, сарказм һ.б. Игътибарыгызга без кызыклы дип тапкан берничә башисем:

- Качкын кәҗә кире әйләнеп кайткан, әмма аңа инде алмаш тапканнар
- Быел талпаннар игелеклерәк, тешләүләр саны 14 процентка кимегән
- Тот ипотекаңны!
- Кибет киштәсендәге бозылган тауар янында «мыеклы инспекторлар» чабып йөри
- Татарлар, юрап китермәгез!
- Новосибирскида Ленинга охшаган чәчәк урлаучыны эзлиләр
- Финкыйраз? Юк, кәтелми: фин татарлары инкыйраз булмас дип ышана
- Омск халкы Шәһәр көнен бәйрәм итүдән туктый алмый
- Климакс ишек какса...
- Россиягә салкын Буш яный

Җәүдәт Гыйльманов тайгак юлга баскан

«Барс-Медиа» ширкәте элегрәк җырчыкүлән турында «Кәеф ничек?» дигән газета чыгара иде. Бу басмада шаярулы башисемнәр еш очрады. Продюсер **Җәүдәт Гыйльманов**ның эшләмәгән җире калмый. Зоопаркта да хезмәт куйды ул, аннан хайваннардан ничектер кисәк кенә җырчыларга күчте. Берзаман кыш көне Җәүдәт әфәндене Казанның бер шугалагына җитәкче итеп куялар. Шул ук атнаны газетада мондый башисем пәйда була: «Җәүдәт Гыйльманов тайгак юлга баскан». Әмма кызыгы соңрак. Бу язманы күргән бер кеше танылган продюсерның туганына шалтырата, ә ул – Җәүдәт абыйның хатынына. Кыскасы, сарафан радиосы буенча язманың асылы түгел, ә башисеме генә тарала. Берзаман өйдә Җәүдәт Гыйльмановны кырыс кына караш белән хатыны каршы ала: «Нинди хәл бу? Нинди тайгак юлга басуың турында яза анда газеталар?»

Башисемдә сүз уйнату «Кәеф ничек?»тә соңрак дәвам итә. Камал театры артистлары җылы яктан гастрольдән кайталар. Равил Шәрәфиев анда фейхоа дигән экзотик җимеш сатып алган. Хәзер аны Казанда да табарга мөмкин, ә ул елларда күргән-татыган нәрсә түгел иде. Тик бу татлы күчтәнәчне өйгә алып кайту җиңел түгел, сытылырга мөмкин. Шулай да актёр бик тырышкан, күчтәнәчне саклаган. Һәм шул турыда газетада язма дөнья күрә: «Равил Шәрәфиевнең самолётта фейхоасын сыта язганнар».



Хатирә

ЧЫН ДУСЛЫК

Җәй фасылының соңгы көннәре, август аенда була бу хәл. Менә шулай көзге эшләргә тотынып килгән Сөрде авылында, кинәт кенә ике сабый ир бала юкка чыга. Башта әниләре белән әбиләре эзли башлый: күрше-күләннән сорашып инде.

– Балаларны күрмәдегезме?

Күршеләр малайларның капка төбендә уйнап утырганнарын күргәннәр, тик кая киткәннәрен берсе дә белми. Инде йорт, каралты-кураны карап, авылдашлардан сорашып, алга таба китә олылар. Соңыннан балаларны эзләргә, кырык эшләрен кырык якка ташлап, барлык Сөрде авылы халкы күтәрелә.

Иң беренче булып, бер тезмәгә басып, авылга терәлеп торган уннарча дистә гектарлы булган кукуруз басуын сөзеп чыга авыл халкы. Балалар анда юк. Бүре, Җанбай, Наратлык, Каенлык посадкаларының барлык куак-агач төпләрен карап чыгалар. Күпер, Сапый, Дәү бияләрнең авыл ирләре төпләренә чумып актарып чыгалар. Яткулык, Бүтәкә, Салкын чишмә болыннары калмый. Балалар юк! Бар Сөрде авылы халкын кайгы баса.

Инде кичке сигез тула. Әниләре-әбиләре борчылудан урынга егыла. Алар арасында яңа гына укып кайткан фельдшер Ләлә ни кырырга белми бәргәләнә. Колхоз һәм авыл советы рәисе, участок инспекторы да күптән эшкә кушылган. Беркем берни белә алмый. Балалар юк.

Шулай авыл халкы ни эшләргә белми торганда кинәт кенә бу ике малай маллар асраган сарайдан килеп чыга. Бар халык «Ах!» итә. Үзен бик тиз кулына алган участок инспекторы малайларга сорау бирә:

– Сез шунда идегезмени?

– Әйе! – дип җавап бирә малайлар.

– Нишләдегез анда?

– Шпионнар булып уйнадык. Лар (ашлык саклый торган зур агач тартма) эченә кереп утырдык та дошманнарны күзәтә башладык.

– Шуннан?

– Аннары Алмаз йоклап китте. Мин аның уянганын көтеп утырдым.

– Һай, улым, без сезне кычкырып эзләгәнне ишетмәдеңмени?

– Ишеттем!

– Ишеткәч, нигә җавап бирмәдең?

– Мин кычкырып җавап биргән булсам, Алмаз уяна иде бит!

Әлеге малайлар күптәннән үз тормышларын булдырып, дүртенче дистәне тутырып киләләр. Һәм әле дә булса дуслар булып, бер-берсенә ярдәмләшеп яши бирәләр.

Чын дуслык шундый була ул!

Зиннур ТИМЕРГАЛИЕВ

Гаилә хәлләре

Хатыны юкның якыны юк

Хатының сиңа теләсә нәрсә эшлә дип әйтә икән, иң яхшысы берни эшләмәскә, гомумән, селкенмәскә дә.

♥

– Ишеттеңме, хатын-кызлар арасында ядрә ыргыту буенча дөнья чемпионыннан ире киткән.
– Ничек?
– 78 метр да 38 сантиметрга.

♥

Мәхәббәттән дәртләнеп, ул үзенең сөйгәнен караватка ташлады. Әмма төз туры китерә алмады.

♥

– Матурым, миңа берәр комплимент әйт әле.
– Синең күзләрең ял көннәре кебек.
– Ничек инде?
– Алар икәү.

♥

– Минем хатыным бул әле?
– Синең проблемаларың әз мәллә?

♥

Сине кулында йөртергә вәгъдә иткән кеше хакына гына булса да төнгә каршы ашама.

♥

– Хатыным миңа 23 февральгә бүләк әзерләгән. Түземлегем җитми, тизрәк беләсем килә: соры оекбаш микән, кара микән?

♥

5 нче катка 16 килолы коляскада 6 килолы баласы һәм кулындагы азык-төлек букчасы белән күтәрелгәндә үзен бәхетле хатын итеп хис итүе Гөлназга көч өсти иде.

♥

Яшьрәк чакта мин иремнең телефоны гел парольле булуына шикләнә идем. Хәзер пароле юк, әмма мин аның телефонына кермим, үземнең проблемаларым да җиткән.

Дөрес бит?

УЙНАШТАН ТУГАН УЙЛАР



✓ Яшьлек узу белән бүлмәдә кеше артыннан утны сүндереп йөрү гадәте килә.

✓ Йөзем ул шәраб була алмый шиңгән виноград.

✓ Тозның уртача яше – 500 ел. Шулай булгач, ни өчен аны кибеттә сатканда срогы 2 ел дип куялар?

✓ Ипотекасын түләп бетергән һәм бөтен тешләрен дәвалап бетергән кешеләр акчаларын нәрсәгә тота икән?

✓ Бу дөньяда иң авыр йөк – башыбыздагы кирәкмәгән уйлар.

✓ Телефон номерын скриншот белән җибәргән кешеләргә ничек түзәргә?

✓ Кичә кичке тугызда йокларга яттым да өч сәгать буе иртә ятканыма сөенеп туя алмадым.

✓ Телевизор пульты кем кулында – гаиләдә шул баш.

✓ Үземне тиктомалга мактамыйм. Менә шундый инде мин.

✓ Чәчәкләр шиңәчәк, ә социаль челтәрдәге лайк – гомерлеккә!

Елмай!

ЯЛКАУГА КӨН ДӘ БӘЙРӘМ

Ялкау кешеләрне ник шулай яратмыйсыз сез? Без берни эшләмәдек бит!

♥♥♥

Бу дөньяда акчаны шулкадәр эшләргә кирәк ки, синең эшсез хатының социаль челтәрдә башкаларны яшәргә өйрәтерлек булсын.

♥♥♥

Кар ул – ялкау су. Беренчедән, гел ята. Икенчедән, аны гел урыннан-урынга кузгатасы.

♥♥♥

– Иң яхшы сыйфатыгызны атагыз.
– Тәк. Беренчедән, миннән дә ялкаурак кешеләр бар.

♥♥♥

– Әйдә, танышабыз, матуркай! Нихәлләрең бар? Нишлисең?
– Утырам.
– Нәрсә өчен утырасың?

♥♥♥

Кичә эшкә барасым килмәде. Авырдым, дип алдадым. Бүген өч хезмәттәшем эшкә килмәгән. Миннән авыру ияртте дигәннәр.

♥♥♥

Кичә, ниһаять, тәрәзәләрне юдым. Бүген кояш иртәрәк чыкты.

♥♥♥

– Матурым, кил әле! Үлчәүгә баскан идем, авырлыкны күрсәтү урынына кемнеңдер телефонын күрсәтә!

♥♥♥

– Вакыт һәрнәрсәне үз урынына куячак.
– Фәлсәфәңне туктат һәм бүлмәңне җыештырып бетер.

♥♥♥

Өмә оештырып эшне башкару җиңелрәк. Чөнки хатаны башка кешегә сылтау мөмкинлеге бар.

♥♥♥

– Син ничәгә кадәр эшлисең?
– Рәсми рәвештә 17.00гә кадәр, ә күңелем белән 15.00гә кадәр.

Әз-мәз мәзәк

– Аквапарк, ресторан, квест – барысы да туйдырды. Улыбызның 10 яшьлеген кайда үткәрергә дә белмибез.
– Без үскәндә, туган көнне ике җирдә генә үткәреп була иде: залда яки кухняда.

* * *

Әтәч микродулкынлы мич эчендәге тавыкны күрә дә әйтеп куя: «Авылда күкәй салырга кеше юк, ә ул монда карусельдә әйләнә».

* * *

Балачакта өстемә телевизор төшкәч, берәүләр минем янга йөгерде, ә икенчеләр – телевизор янына. Чөнки совет заманында баланы 9 ай көтәсе иде, ә телевизор алуга чиратны – 14 ай.

* * *

Күз яшен сөртәм дип йөргән кызыңның кашын сөртсәң, нишләргә?

Мач әйткән!

Моника БЕЛЛУЧЧИ, итальян актрисасы:

– Ир-атның тәрбиясе талашканда күренә.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 223

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+